Мәдәни җомга

www.madanizhomga.ru

1995 елның июленнән башлап чыга

Татарстанда язылу индексы – П2355.

№ 21 (1386) 3 июнь 2022 ел

БЕЗ СОЦИАЛЬ ЧЕЛТӘРЛӘРДӘ:

madani_zhomga madanizhomga

madani_zhomga

8

Үз чикләренә бикләнгән тоталитар режимдагы илдә тормышның ничек баруын белергә теләсәгез, Төньяк Корея үрнәге белән танышыгыз...

15

Гармуннар ясаучы, тальяннар төзәтүче оста, бар җанын салып эшләүче Айрат Харисовның хезмәтен лаеклы дәвам итүче табылырмы?..



16

Алтын Урданы дәреслекләрдә караңгылык һәм кыргыйлык дип күрсәтергә маташсалар да, хакыйкать моның киресен раслый.



Табигатьне элпә канатында Җәйгә алып керде күбәләк!..

БЕР ҖӨМЛӘ БЕЛӘН...

● Казанның Чехов урамындагы 53нче йорт диварына Татарстанның беренче Премьер-министры Мөхәммәт Сабировка истәлек тактасы куелды.

● Татарстан Премьер-министры урынбасары, Милли Шура рәисе Васил Шәйхразиев Бурятиядә «Усть-Кяхта алмагачлары» татар халкы көнкүреше музей-утарының ачылу тантанасында катнашты.

● Уфа «Нур» татар театрында Россия Думасы депутаты, шагыйрь, меценат Дәрдемәнднең (Закир Рәмиев) тууына 160 ел тулуга багышланган «Аh, туган каумем газиз!» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә булды.

● Мамадышның Түбән Яке авылында яңа мәчет ачылды.

● Казанда узган халыкара Коръән уку конкурсы җиңүчесе Муса Гайтиевкә Чечня хакимияте автомобиль һәм республиканың иң югары бүләге – Кадыров ордены тапшырды.

● «Шаян ТВ» каналы Казанның мәдәният үзәкләрендә «Балачак җыры» дип аталган концертлар циклын башлады.

● Туймазыдан Германиягә күченеп киткән Разиф Хафизов Бурхгаузен шәһәрендә «Татар язы» бәйрәме оештырган.

● «Идел» яшьләр үзәгендә Татарстанның алдынгы предприятиеләрендә һәм оешмаларында эшләүче иҗади яшьләрнең IV слеты узды.

● Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты житәкчесе урынбасары Марс Тукаев конгрессның «Татар милләтенә күрсәткән олы хезмәтләре өчен» медале белән бүләкләнде.

ӘЙТКӘН СҮЗ – АТКАН УК

Илтөзәр МӨХӘММӘТГАЛИЕВ, Татарстанның атказанган артисты:

«Кадрлар белән шөгыльләнергә кирәк. Элек бит шөгыльләнгәннәр. Опера студияләренә укырга җибәргәннәр. Артистларны да Мәскәүдә укытканнар. Хәзер дә Мәскәүдә укытырга кирәк. Бар чагында! Анда дә мәңге булып тормаска мөмкин. Драматург булу өчен режиссер дәрәҗәсендәге театраль белем кирәк. Туфан абый, Илгиз ни өчен драматург? Чөнки театр белеме бар».

СЫНАМЫШЛАР

3 июньдә яңгыр яуса, көз яңгырлы килә ● 5 июнь – кыяр чәчә торган соңгы көн ● 7 июньдә күп чык төшсә, игеннәр уңа. Әгәр миләш һаман чәчәк атмаган булса, көз озакка сузылачак ● Җәй көне гел томан төшсә, гөмбә күп булыр.

КОЯШ СӘГАТЕ

Бүген кояш **3 сәгать 05 минутта** чыкты, һәм ул **20 сәгать 19 минутта** офык артына күмеләчәк. Көн озынлыгы – **17 сәгать 14 минут.** Алдагы җиде көн дәвамында тәүлекнең якты вакыты **13 минутка озынаячак** һәм киләсе җомгада, ягъни **10 июньдә 17 сәгать 27 минут** тәшкил итәчәк.

БЕЛЕП ТОРЫГЫЗ

3 июнь – актриса, Татарстанның халык артисты Гөлүсә Гомәр кызы Җамалиевага (Гайнетдинова) 70 яшь (1952).

4 июнь – шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Эльмира Мөхәммәт кызы Шәрифуллинага 75 яшь (1947).

6 июнь – актриса, Татарстанның атказанган артисты Әлфия Якуп кызы Хәсәновага 70 яшь (1952);

– Рус теле көне.

8 июнь – музыкант, дирижер, профессор, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе Ринат Арифулла улы Халитовка 65 яшь (1957).

СӘЛАМӘТЛЕК КӨН ДӘ КИРӘК

Июньнең магнитлы авыр көннәрендә хезмәттәшләрегез, якыннарыгыз сәламәтлегенә һәм, әлбәттә, үз-үзегезгә аеруча игътибарлы булыгыз. **Андый көннәрне исегезгә төшерәбез: 8, 9 июнь.**

* * *

Гадәттә, яңа айдан айның беренче чирегенә кадәр **(30 май-7 июнь)** организм кысылуга бара. Мондый көннәрдә үз-үзеңә физик йөкләмә бирү файдалы.

Шунысын да онытмагыз: **18 майдан 27 июльгә кадәр** йөрәк һәм нечкә эчәклек актив булучан. Шушы вакыт аралыгында аларны ныгыту һәм дәвалау уңай нәтиҗәләргә китерә.

ҺИҖРИ БУЕНЧА 1443 ЕЛ

Бүген зөлкагдә аеның 4 нче көне

ҖАН АВАЗЫ

Тәлгать ГАЛИУЛЛИН

Иртәгә соң булыр!

Туган телебезне саклау өчен бөтен көчен биреп, гомерен мәгърифәткә, милли мәнфәгатьләргә багышлаган академик Рүзәл Юсуповның «Педагогика университеты кирәк» (М.Җ.№10, 2022) исемле мәкаләсеннән соң аның фикерләрен хуплап һәм хисләремне туплап өлгергәнче, Татарстанның халык шагыйре Ренат Харисның шулай ук укытучылар, аеруча татар теле, әдәбияты, тарихы буенча белгечләр әзерләү ихтыяҗын калкытып куйган «Укытучы – кеше җанының баш инженеры» (М.Җ. №16, 2022) дигән тирән эчтәлекле язмасы басылып чыкты. Бәхәс киң масштаблы аренада күпләрне уятты, телебез һәм халкыбызның киләчәге турында уйланырга мәҗбүр итте.

Авторларның икесе дә укытучы һөнәренең җәмгыять, милләт яшәеше өчен ничаклы мөһим һәм көн үзәгендә торган мәсьәлә икәнен аңлый. Галим Р.Юсуповның Мәскәү белән Петербургтан кала өченче буларак ачылган факультетлар, белгечлекләр, талиб-талибәләр саны буенча элгәреләреннән калышмаган педагогика институтының (соңрак университетның) 20 елга якын ректор вазифаларын башкаруы – проблеманы йөрәгә аша уздырган зат булуына дәлил. 140 елга якын Идел-Урал, хәтта Себер киңлекләре өчен укытучылар әзерләгән КГПИ бер мизгелдә юкка чыгарылды.

«Безнең Казан педагогика институты татар теле укытучылары әзерләү буенча бөтен Идел буе өчен иң мөһим һәм хәлиткеч уку йорты булды», – дип яза шунда югары белем алган Айдар Гарипов «Без дә студент идек» (М.Җ.№13, 2022) исемле мәкаләсендә. «Безнең белән бергә Пензадан, Нижгар, Төмән, Чуашстан, Самара өлкәсеннән, Башкортстаннан газиз Ана телебезгә гашыйк укучылар җыелган иде». Мәкаләсен «ел саен йөзәрләгән егет һәм кызларны бәхетле итеп, зур тормышка, газиз телебез хакына көрәшкә чыгаручы ИНСТИТУТ кайда? Һәм олы бер милләтнең яшәү умыткасы, белем казаны,мактанычы булган Ана телебезне укытуны ник туктаттылар?» – дигән борчулы сораулар белән тәмамлый А.Гарипов. Бусы инде галимнәр «боламыгы» түгел, ә халык фикере.

«Укытучы – кеше җанының баш инженеры» мәкаләсе авторы Ренат Харис та бөтен булмышы, тирән тамырлары белән укытучылар нәселеннән. Әти-әнисе – мәктәп директорлары булып эшләгән шәхесләр. Аларның варисы Ренат та укытучы һөнәрен сайлап, Казан педагогика университетын тәмамлый һәм журналист эшенә күчеп, өч чакырылыш Дәүләт Советы депутаты, анда рәис урынбасары булып сайланганчы, хезмәт юлын Арча педагогика көллияте укытучысы сыйфатында башлый.

Мин 16 ел Алабуга пединститутының ректоры, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетының беренче деканы, фәнни дәрәҗәләр алу шурасы рәисе вазифасын 25 ел үтәгән үземне дә, халкыбызның телен, рухи тамырларын саклау таләбе белән «кузгалган» авторларга кушылырга лаеклы дип саныйм.

Милләтебезнең киләчәге белән бәйле сорауларны калкытып куйган чыгышлар туган телебезнең сагында торып, шул мәнфәгатьләргә хезмәт иткән укытучылар әзерләү мәсьәләсен калкыту белән сөендерсә, чыгу юлының томанлы, билгесез булуыннан гаҗизлекләре белән барыбызны да пошаманга сала.

Бердән, татар мәктәпләрендә милли компонентның елдан-ел кысыла килүе, татар теленә бирелгән сәгатьләрнең кимүе, шуның өстенә бердәм дәүләт имтиханын (ЕГЭ) үтү кыенлыклары укучыларга да, мөгаллимнәргә дә ничаклы баш авыртуы өстәве сер түгел.

Икенчедән, Казан (Идел буе) федераль университеты дигән ялтыравык исемгә, матур вәгъдәләргә алданып, милли мәгарифебезгә, аерым алганда, татар теле, әдәбияты һәм тарихы укытучыларын әзерләүгә төзәлмәслек зарар китерде. Молох (беркайчан туя белмәүче дәҗҗал) авызына Казан педагогика университетын, Гуманитар институтны, Бөек Ватан сугышы чорында Сталин әмере белән һәдия ителгән татар теле бүлеге нигезендә ачылган һәм ике дистә ел дәвамында милли кадрларны әзерләүгә, гомуми интеллектыбызны үстерүгә, фән кандидатларын, докторларны әзерләүгә зур өлеш керткән татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләр факультетын югалттык. Бу «корбаннар»ны әллә нинди байлыклар һәм грантлар исәбенә дә аклап, гафу итеп тә булмый. Шул исәптән атаклы Казан император университетын югалтуыбыз турында укучының сызлануын көчәйтеп, исенә төшереп тә тормыйм!

Әлбәттә, әлеге югалтуларга сукыр күздән яшь чыгарыр дәрәҗәдә елап утыруның файдасы булмас. Безгә бары тик үз көчебезгә, үҗәтлегебезгә һәм кыюлыгыбызга таяну гына ярдәм итәчәк. Бераз шаянрак күренсә дә, чынлыкта хакыйкатьне чагылдырган бер мәүзугны искә төшереп үтик. Үткән гасырның 60 нчы елларында (әле «Хрущев җепшеклеге» чоры) күренекле тел тарихы галиме, профессор Латыйф Җәләй студентларга лекция укыганда, милләтебезнең кайбер гамәлләренә төрттереп, «синең татарың» сүз берәмлеген төрле аһәң-мәгънәләр салып, еш куллана иде.

Латыйф абыебыз бакыйлыкка күчеп, инде без, аның талиблары да олыгаеп, милли телләрне кысулар соң чиккә җиткерелгәч, мөгаллимебез гыйбарәсенең асыл мәгънәсенә төшенә башладык. «Синең татарың»ның татардан башка берәүгә дә кирәге юк дию булган икән аның. Дөрес, Татарстанның табигый нигъмәтләренә, эшче көчләренә кемнәрнеңдер берни янамаган телләрен якларга гаярь егетләренә ихтыяҗ чыгып тора. Без гаҗәп күндәм һәм беркатлы халык шул.

Акмуллаларыбыз кул арбасы тартып әлифба-китаплар ташыган чакта азатлык турында хыяллана да алмаган һәм һич тә көтмәгәндә мөстәкыйль дәүләтле булып киткән төрки мәмләкәтләр, төрекләр белән күп санлы гарәп-фарсы илләре «синең татарыңа» ярдәм кулы сузарга ашыкмый! Ә бит соңгылары татарларны, Идел буе Болгарларын ислам динен кабул итүгә күндерергә килгәндә, Ибне Фадлан житәкчелегендәге делегация, башка димчеләр татлы сүзләрен дә, бүләкләрен дә кызганмаган. Милләтне, гореф-гадәтләрне, мәгарифне саклауда диннең әһәмияте кимегәч, аның белән көрәшүне, аңа аяк чалуны туктатып, телгә ябырылдылар! Халыкны кол хәлендә калдыруның иң туры юлы - аны телсез, белемсез калдыру.

«Мәдәни җомга» тәкъдим иткән мәкаләләрдә, телебез үсеш-яшәешенә бәйле башка чыгышларда методика мәсьәләләренә, аерым алганда, сөйләм теле белән әдәби тел арасындагы мөнәсәбәтләргә караган шактый төпле дә, табигый ки, бәхәсле фикерләр дә әйтелә. Мәсәлән, безгә Р.Харисның «Белгечнең максаты кешене үстерү, ә укытучыныкы – баланы белемле, тәрбияле кеше итеп, кешене шәхес итеп үстерү» җөмләсе бик якын.

Дөрестән дә, теләсә кайсы тел көндәлек аралашу чарасы булып хезмәт иткәндә генә яши алса, икенче тарафтан, аның сүз байлыгы үсеше, таралыш даирәсе киңәюе, фәннилеге белгечләрнең, галимнәрнең тырышлыгы, аны шивәләр, үзгә лөгатьләрдән кабул ителгән сүзләр, атамалар исәбенә даими баетылып торуы лазим. Теләсә нинди телне камилләштереп торучы, фәнни дәрәҗәсен саклаучылары булмаганда, сурәтлелек байлыгын югалта һәм бер җитди әсәр, фәнни хезмәт тудырмаган чегән теле дәрәҗәсенә төшә, гадәти аралашу өчен (хәтта әрләшү, вульгар сүзләрне дә кертеп), 50-60 сүз баштин ашкан, ди галимнәр (бигрәк тә татар фигыльләренең һәркайсы диярлек берничә мәгънә белдерүен истә тотсак).

Рус теленнән башка телләрне мәктәп программаларыннан алып ташлаткач, чыгу юлын эзләп, кайбер «акыллы башлар» тел язмышын әби-бабайларга «сылап» калдыру юлын тәкъдим итте (янәсе, оныкларын алар өйрәтергә тиеш, телнең башы гаиләдә, имеш). Нәтиҗәсе озак көттермәде: оныклары әбиләрен русчага күчерде (шынок, куды пошол, на, воду пей һ.б. гыйбарәләр өйләрдән урамга «чыкты»).

Туган телне ата-ана ярдәмендә өйрәтүдән баш тартмаган хәлдә дә әзерлекле фидакяр укытучы гына телебезне саклап кала алачак. Шул хакыйкатьне күз алдында тотып, Р.Юсупов педагогика институтын яшәүдән туктатуны зур җинаять дип саный һәм катгый рәвештә «Казан педагогика институтын торгызырга кирәк!» кебек нәтиҗәсен калкытып куя.

(Дәвамы 4 нче биттә).

Җидегән вакыйгалар хәбәрләр яңалыклар

«ЗУР ЕВРОПА» ХИКМӘТЛӘРЕ

Дөнья тотучыларның геосәяси максатлы интеграция планнарыннан янә берсе – «Зур Европа» проекты. Асылы белән ул, Европаның географик чикләреннән чыгып, тарихи, мәдәни һәм сәяси бәйләнешләре ягыннан аңа якын торган илләрне берләштерүне күздә тота (әлегә кадәр сүз күбрәк аның «Лиссабоннан Владивостокка кадәр» варианты, ягъни интеграция процессларына Россияне һәм элеккеге СССРның берләшмәгән башка республикаларын да җәлеп итү турында барды). Геосәяси конъюнктурадан чыгып, төрле чорда аны төрлечә шәрехләүләр дә (Шарль де Голльнең «Атлантикадан Уралга кадәр Европа»сыннан башлап, М.Эмерсонның «Зур Евразия»сенә кадәр) булды. Күрүебезчә, бүген ул өлешчә Азиягә дә кагыла. Гомумән алганда, «евразиячелек» идеясе яңа түгел (ул географ П.Савицкий, философлар Н.Трубецкой, Л.Карсавин, Г.Флоровский һ.б. чорыннан ук килә). Бүген инде Россиянең киләчәген кайгырткан социаль проектлар да бар (әйтик, А.Прохановның «Бишенче империя»се, С.Кургинянның «СССР-2» проекты, А.Дугинның «Проект Евразия» китабы, В.Сурковның «Долгое государство Путина» планы һ.б.). Әмма бөекдержавачыл шовинизм рухындагы аңга исәп тотып язылган андый «тәгълимат»лар, геосәяси чынбарлыктан ерак тору сәбәпле, үз-үзен хөрмәт иткән сәяси даирәдә генә түгел, гомумән, сәламәт рухлы теләсә кайсы җәмгыятьтә җитди кабул ителә алмый.

Бу язмабызда исә сәер сәясәтче (үзен ул «небополитик» дип атый, димәк, «күкләр сәясәтчесе» була инде) Андрей Девятовның «Зур Евразия» (Өченче Урда) атлы проектына тукталып үтәрбез. Анынча, «күкләр сәясәте») «Зур Евразия» дөньякүләм проектының гамәлгә ашырылуын Россия өчен Чыңгызхан империясе (Беренче Урда) һәм Сталин социалистик лагере (Икенче Урда) варислары булган «Өченче Урда» итеп күрә. Хикмәт шундадыр ки, географик урыны мәгълүм булса да, тарихи вә цивилизацион яктан бу илнең урыны әлегәчә бәхәсле булып кала. Шуңа күрә «евразиячелек» идеясе Россиянең көнчыгыш тамырларын ачыклауга (Урдамы ул, Византияме?) кайтып кала. Ә авторның үзенә килгәндә, ул – элеккеге ГРУ полковнигы, озак еллар Кытайда эшләгән һәм аның тарихын яхшы белә. Россиянең киләчәген Кытай белән бәйләп карый. Аның «Разведка будущего в условиях глобализма» дигән китабы да бар. Россиянең тамырларын А.Девятов Урдада күрә. Ул Чыңгызхан оныгы Хубилайның (ул аны «бөек монгол ханы» дип атый, гәрчә, «иго» саналганда «татар» сүзе беренче урынга куеп әйтелсә дә) Урда башкаласын Каракорымнан Ханбалыкка (Даду, Яньцзин, бүгенге Пекин) күчерүе, бу кала шулай ук Бөек Тартариянең (ул монда да «татар» сүзен кулланмый) башкаласы булуы турында әйтә, шуңа нигезләнеп, Урда тарихы Бөек Тартария тарихына керүе, ә «Зур Евразия» проекты тартар тарихи тамырларын алуын да дәлилли.

Хубилай исә төп дини юнәлешләр – буддизм, даосизм, конфуцийчылык, ислам, христиан дине буенча аерым министрлыклар булдырган, иудаизмны да таныган (игътибар итик, Девятов нигәдер тәңречелекне төшереп калдыра). Димәк, Урда (ул заманнарда ук!) күп конфессияле, бер аллалык белән мәҗүсилек тә янәшә яши ала торган империя булган. А.Девятов исә бөек ханнар хакында әйтелгән «мәңге уллар» төшенчәсен дә «сын неба» итеп бирә, аны христиан динендәге «сын отца небесного» белән бәйләп карый. Ә Россиядә хакимиятнең закон чыгару, башкарма һәм суд төрләренә бүленмәвен ул, юлбашчының анда дөреслек патшасы булуы белән, «это царь православный в одном лице соединяющий военную, светскую и духовную власть» дип аңлата. Күренә ки, А.Девятовның «Өченче Урда»сы Урталык җирләрендәге хәтәр хәлләрне сәяси конъюнктурага туры китереп һәм яңа тарихи тамырларга бәйләп аңлату, киләчәкне дә шул ук рухта фаразлау, моңарчы кара төсләрдә бирелгән Урда тарихын бераз ачып (әмма аның татар асылын күрәлтә йомып), православиегә корылган тоталитар режимның киләчәген, колагыннан тартып, шул шанлы тамырларга бәйләп куюга кайтып кала. Тик яшәеш Девятов фаразлаганча гына бармый. Бүгенге фаҗигале чынбарлык – шуның ачык мисалы. Узган атнада Евразия икътисади форумында ясаган чыгышында Россия президенты В.Путин да, зур Евразия күпләрне кызыксындыра торган үзәк булачак, дип белдерде. Әмма бу инде - бераз бүтәнрәк тема...

Фоат УРАЗАЙ.

ЯЗЫЛЫР ӨЧЕН ИҢ КУЛАЙ ВАКЫТ!

*Дуслар! 6-16 июнь көннәрендә **«Мәдәни җомга»** газетасына ташлама белән язылып була. Әбүнәче декадасы көннәрендә язылу бәясе **603 сум 30 тиен**. **«Мәдәни җомга»** газетасына Татарстанда язылу индексы – **П2355.***

Вакытында язылган ота!

Рухи кыйммәтләрнең бәһасе төшмәсен

Россия ислам институтында «Хәзерге яшьләр һәм Россия халыкларының рухи кыйммәтләре» дип исемләнгән VII Республикакүләм студентлар фәнни-гамәли конференциясе узды. Фәнни чара быел Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгына багышлап үткәрелде.

Конференциянең пленар утырышында Татарстан мөфтиенең мәгариф буенча урынбасары, РИИ ректоры Рәфикъ Мөхәммәтшин, Болгар ислам академиясе ректоры вазифаларын башкаручы Айнур Тимерханов, КФУның халыкара эшчәнлек һәм үсеш буенча директор урынбасары Эльзара Гафиятова, Татарстан Фәннәр академиясенең Ислам тикшеренүләре үзәге директоры Ринат Патеев һ.б. катнашты.

«Без еш кына хәзерге яшьләр алдыңгы, креатив булырга тиеш дигәнне ишетәбез, әмма моның өчен көн саен социаль челтәрләрдә, төрле чатларда утыру гына җитми. Шулай ук үз тарихыңны яхшы белергә, аны өйрәнергә, фикер йөртергә һәм нәтиҗәләр ясарга кирәк. Ахыр чиктә, бу үз тарихыбыз белән горурланурга китерәчәк», – диде Р. Мөхәммәтшин ачылыш тантанасында.

А.Тимерханов ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулуны бәйрәм итүнең мөһимлеген ассызыклады: «Һичшиксез, безнең ата-бабаларыбызның ислам динен кабул итүе гасырлар буена Россиядә, татар халкында һәм илебезнең башка күп кенә халыкларында ислам үсешенең барышын һәм характерын билгели торган вакыйга булды».

Ачылыштан соң конференция үз эшен Россиядә ислам теологиясе: үткәне һәм хәзергесе; яшь галимнәр күзлегеннән теологик белем бирү; туган тел һәм әдәбият; мультиконфессиональ киңлектә чит телләр һәм мәдәниятләр; хәзерге җәмгыятьтә медиа һәм реклама, аны өйрәнү алымнары, үсеше һәм киләчәге кебек темаларга багышланган секцияләр кысаларында дәвам итте.

Татар китабы – Мәскәүдә

Бу көннәрдә Татарстан китап нәшрияты Россия башкаласының үзәгендә сигезенче «Кызыл мәйдан» китап фестивалендә катнаша. Быел бәйрәм офлайн форматта уза һәм язучы, шагыйрь, китапханәче, актер, музыкантларны һәм дистәләрчә укучыларны берләштерә.

Фестивальнең төп вакыйгаларының онлайн-трансляциясен миллионлаган тамашачы популяр интернет-мәйданчыкларда күрә ала.

Программада Россиянең танылган сәнгать, фәнни-популяр һәм балалар әдәбияты авторлары, әйдәп баручы театрлар һәм музыкаль коллективлары катнашында 400дән артык вакыйга була.

«Россия төбәкләре» мәйданчыгында илнең 50 төбәгеннән китап чыгаручылар җыелды, Татарстан китап нәшрияты 300 дән артык төрдә 2 мең данәдән күбрәк китап тәкъдим итә.

16 нчы павильон чатырында балалар китаплары, фәнни-популяр һәм тарихи басма, туган якны өйрәнү һәм сәнгать турында китап, альбом сатып алырга мөмкин.

1 нче биттә - махаон күбәләге. Фото: pxhere.com

Халык бәйрәме

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов «Каравон-2022» рус халык бәйрәмендә катнашты. Бәйрәм гадәттәгечә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Никольское авылында узды. «Каравон» республикада 30нчы тапкыр үткәрелә.

Бәйрәмдә һәркем күңеленә хуш килерлек махсус иҗади һәм тематик мәйданчыклар – «Широкая ярмарка» (сәүдә рәтләре), «Петрушкин двор», рус халык әкиятләре мотивлары буенча театральләштерелгән тамашалар, «Мастеровые» – халык сәнгате һөнәрләре буенча осталык дәресләре, декоратив-гамәли сәнгать әйберләре күргәзмәсе оештырылган иде. Шулай ук «Каравон» тарихы музее буенча экскурсияләр, Никольское авылында яшәүчеләрнең һәм XIX-XX гасыр башларында «Каравон» ансамблендә катнашучыларның костюмлы комплекслары күргәзмәсе дә тәкъдим ителде. Р.Миңнеханов ярминкәгә декоратив-гамәли сәнгать эшләнмәләре алып килгән халык осталары белән аралашты. Президентка милли рус костюмнарын тегә торган проект тәкъдим ителде. Рөстәм Миңнеханов күргәзмә үрнәкләре белән танышты һәм махсуслаштырылган күргәзмәләр оештыру мөмкинлеген карарга тәкъдим итте. «Безнең Казан Кремлtotненең территориясендәге бинада мәйданнарыбыз бар, һәм мондый күргәзмәләрне шунда эшләргә кирәк. Бу – безнең байлыгыбыз, мондый күргәзмәләр күпләрне кызыксындыра ала», – диде ул.

Р.Миңнеханов бәйрәмдә катнашучыларны һәм кунакларны сәламләп «Каравон» бәйрәменең елдан-ел киңәя баруына басым ясады, илнең 20 дән артык төбәгеннән килгән, 170 иҗат коллективына, халык һөнәрчелеге вәкилләренә рәхмәт белдерде.

Бәйрәм кысаларында Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре һәм рус этномәдәни коллективларына сертификатлар тапшырылды.

Туган ягына һәйкәл булып кайтты

30 майда Башкортстан һәм Татарстанның халык артисты Хәния Фәрхи туган. Җырчының туган көнендә Башкортстанның Тәтешле районы үзәге Югары Тәтешледә һәйкәл ачылды.

Тантанада Хәния Фәрхинең туганнары, хезмәттәшләре, Башкортстанның һәм Татарстанның сәхнә осталары катнашты. Былтыр Тәтешледәге Балалар иҗаты үзәгендә җырчының музее ачылган иде. Һәйкәл шушы музей каршына куелды.

Хәния Фәрхи истәлегенә ике елга бер мәртәбә Югары Тәтешле авылында «Онытылыр димә» дип аталган фестиваль-бәйге уздырыла.

Риза казый истәлегенә

Уфа мөселман зиратында күренекле мәгърифәтче, дин эшлеклесе, тарихчы, педагог Ризаэтдин Фәхретдин истәлегенә мемориаль комплекс ачылды. Тантанада мөфти Тәлгать хәзрәт Таҗетдин, Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллин, Уфаның «Ихлас» мәчетенең мәхәллә җыены рәисе Мөхәммәт хәзрәт Галләмов һәм Бөтендөнья татар конгрессының Башкортстан Республикасындагы вәкиллеге җитәкчесе, «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы Альфред хәзрәт Дәүләтшин һәм башка хәзрәтләр, галимнәр, тарихчылар, журналистлар, дин галименең туганнары да катнашты. Ризаэтдин хәзрәт истәлегенә мемориаль комплекс ачу вакыйгасы Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүнең 1100 еллыгын үткәрү кысаларына туры китереп оештырылды.

Россиянең баш мөфтие тантананы ачып, катнашучыларны сәламләгәннән соң, Коръән уку өчен Татарстан мөфтие Камил хәзрәт Сәмигуллинга сүз бирде, аннары Тәлгать хәзрәт үзе Ризаэтдин хәзрәтнең рухына дога кылды.

Галимнең мирасын өйрәнү мәсьәләләре буенча тарихчылар, профессорлар сөйләп үтте. Алар Р.Фәхретдин истәлегенә төзелгән мемориаль комплексны, башкарылган төзекләндерү эшләрен югары бәяләде. Мемориаль комплекс торгызу Р.Фәхретдиннең кабер ташын яңартуны, аллеяга ташлар җәюне, кабергә илтүче юл күрсәткечләрен куюны үз эченә алды.

Хәзерге чорда Татарстан мөфтияте дә Р.Фәхретдин мирасына сакчыл караш тәрбияләү буенча эш алып бара. Нәзарәтнең «Хозур» нәшрияты тарафыннан Р.Фәхретдин мөхәррирлегендә Оренбургта дөнья күргән «Шура» журналы торгызылды. Ул 2013 елдан К.Сәмигуллин мөхәррирлегендә квартал саен имамнар өчен бастырыла. Журналда җомга һәм гает хөтбә-вәгазьләре, дини мәсьәләләргә аңлатмалар, көнүзәк сорауларга дини күзлектән чыгып җаваплар, тарихи һәм фәнни мәкаләләр дөнья күрә. Нәзарәт белгечләре тарафыннан шулай ук галимнең китаплары да әзерләп бастырыла.

Галимне котладылар

КФУның Габдулла Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбендә педагогика фәннәре докторы, татар теле белеме кафедрасы профессоры, татар теленнән дәреслекләр авторы Фираз Харисовның 70 яшьлек юбилеена багышланган очрашу узды.

«Фираз абыйның исемен әйтү белән сыйфат билгесе куз алдына килә. Ул иң нәтиҗәле, сыйфатлы эшләүче дусларыбызның берсе», – диде Филология һәм мәдәниятара багланышлар институты директоры Рәдиф Җамалетдинов һәм КФУ җитәкчелеге исеменнән Рәхмәт хатын тапшырды.

Татарстан мәгариф министры урынбасары Минзәлия Закирова барлык чыгарылыш укучылары, студентлар исеменнән Фираз Харисовка: «Бергәләп милли мәгариф, укытучылар әзерләү эшен алып барабыз. Сезнең куйган хезмәтегез бәяләп бетергесез. 30 елдан артык Сез татар теле һәм әдәбияты олимпиадасының жюри рәисе», – дип рәхмәтен әйтеп, юбилярны «Мактаулы остаз» билгесе белән бүләкләде.

Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе деканы Рамил Мирзаһитов Фираз Харисовның шәкерте булган. «Фираз Фахразович зачеттан «автомат» куйды. Билге куяр алдыннан, минем тарихчы булырга теләгәнне белеп алды. «Татар теле өлкәсенә дә егетләр кирәк», – дип, озак кына сөйләште, татар теле юнәлешеннән китәргә тәкъдим итте. Һәм шулай килеп чыкты да», – диде ул.

«Уңган кеше ул. Бик намуслы, укытучы һөнәренә фидакяр. Аңа Мәскәү университетының фәлсәфә факультетына укырга керергә юллама биргән булганнар. Ә ул Казан педагогика университетына керә, тугры кала», – диде үз чыгышында академик Рүзәл Юсупов. КФУ профессоры Хатыйп Миңнегулов аның «туган җанлы кеше» булуын әйтте.

Башкортстанның Яңавыл районы башлыгы рәисе Илдар Маликов сүзләренчә, Харисовлар гаиләсе Яңавыл районында аерым урын алып тора. «Нәсел агачларының тамырлары бик тирән, ботаклары югары үрелгән. Нәселләрендә тормыш юлын балаларны тәрбияләү, укытуга багышлаган кешеләр дә күп», – дип билгеләп үтте ул.

Фираз Харисовны тәбрикләргә бертуган энеләре – педагогика фәннәре кандидаты Хәмит Харисов, 1997–2004 елларда Татарстан мәгариф һәм фән министры булып эшләгән Фарис Харисов та килгән иде.

Зилә МӨБӘРӘКШИНА.

«Мәдәни җомга» газетасы, «Мәйдан» журналы редакцияләре үткен телле каләм иясе, радиожурналист, милләтпәрвәр, күп кенә татар басмаларының даими авторы

Гафиулла Сәгъди улы ГАЗИЗнең

вакытсыз вафат булуы сәбәпле, аның гаиләсенең, якыннарының, туганнарының авыр кайгысын уртаклаша.

Иртәгә соң булыр!

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Теләсә кайсы милли тел һәрдаим яклауга һәм ярдәмгә мохтаҗ. Аның халкы үзгә телгә күчтеме, ул милләт буларак, кайнар суга тарган боз кебек, эри дә юкка чыга. «Державниклар» моны яхшы аңлый. Әнә бит, Россия Федерациясе җитәкчелеге башка илдә яшәүче милләттәшләренең туган телләрен яклап, «махсус операция» башлады. Бәлки үз илебездәге хәлләргә дә хакимият тотучылар игътибар итәр, дигән сүнеп барган өмет барыбер күңелдә кабынып алгалый. Татарлар башка күп санлы халык уртасында калу сәбәпле, элеккеге пассионарлык дәртен югалтып, язмышы белән килешергә мәҗбүр булгандай күренсә дә, туган телләрен, мәгърифәтен, милли йөзен саклап калу өчен тартышудан туктамый.

1552 елда ук мөстәкыйль дәүләтчелеген югалтса да, халкыбыз дөнья әдәбияты үрнәкләре белән бил алышырлык сүз сәнгатен тудырырлык әдәби телен, менталитетын югалтмаган. Сәбәбе мәгълүм: гасырлар түрендә калыплашкан югары милли интеллект, камил әдәбият, нык үскән мәгърифәт һәм көчләп чукындыру чорларында бар авырлыкны үзенә алган динебез телебезне, димәк ки, халкыбызны саклап кала алды. Заманында татар-кыпчак-болгарларның, безнең бабаларыбызның көчле дәүләтләр тоткан булулары безгә өстәмә дәрт, ышаныч, өмет биреп тора, һәм РФ Президентының, 2022 елда ЕГЭны туктатып, сыналган белем бирү системасына күчәчәкбез дигән вәгъдәсен үтәр дип уйлыйм. «Ил агасы» (аны «Мәдәни җомга» шулай дип атады) М.Шәймиев тә телләрне болай кысуга түзеп тормас, В.Путинның җиңенә кагылып, «милләтләргә нисбәтән дилбегәне йомшартыйк, юкса бик киеренке халәттә яшибез», дияр кебек. Россия белән Татарстан арасындагы солых яңартылса, телләр үсешенә мәгълүм ирек бирелүне дә истә тотарга кирәк. Татарлар – уртак ватаныбыз Россиядә сан ягыннан икенче милләт. Башка азчылык халыкларның зыялылары бездән үрнәк алырга тора һәм «сез телләр ирегене мәсьәләсен кузгатсагыз, без дә кушылырбыз» ди. Халкыбызның башка милли телләр үсешенә дә үрнәк күрсәтеп, ярдәм итәрлек миссиясе дә барлыгын онытмау безнең җитәкчелеккә, зыялыларыбызга өстәмә көч бирүен дә истә тотарга тиешбез.

Безнең таләп бик гади: Россия Федерациясе составына кергән барча халыкларның, уку-укыту мәсьәләсендә хокуклары бертигез булырга тиеш, чөнки барыбыз да бер Аллаһ балалары.

● Россия Умартачылык фәнни-тикшерену институты мәгълүматлары буенча, илдә ун ел эчендә бал кортлары 40 процентка кимегән. АКШта кыргый умарталарның 90 проценты юкка чыккан. «Органик игенчелек берлеге» галимнәре фаразлавынча, алга таба да шулай дәвам итсә, 2035 елга бал кортлары бөтенләй үлеп бетәргә мөмкин. Бу очракта бүген игелә торган агрокультураларның өчтән берен үстерү тукталачак, чөнки үсемлекләрнең 75 процентын бал кортлары серкәләндерә. Альберт Эйнштейн: «Умарта кортлары юкка чыкса, кешелек дөньясы дүрт елдан артык яши алмаячак», – дип әйтеп калдырган.

Давыл булып яшәгән Зөлфәт

Камал театрында Г.Тукай премиясе лауреаты, күренекле шагыйрь Зөлфәт Маликовның туууна 75 ел тулу уңаеннан «Чытырманда былбыл сайрый» дип исемләнгән әдәби-музыкаль кичә узды. Шагыйрьнең «Тояк эзләрендә гөл үсә» дигән автобиографик әсәреннән үз укуындагы видеоистәлекләре, әсәрләре, аның сүзләренә язылган җырлар белән үрелеп барган кичә үзе бер шигъри әсәр, моңлы көй кебек хәтердә калды.



Мөслим районының гүзәл Коргылды инеше буенда урнашкан, урман-суларга бай Сәет авылында туган малай, мәктәпкә укырга кергәнче үк, әкият уйлап чыгарып, берничә дәфтәр язып тутыра. Әмма малай аларны югалта һәм гомере буе шуларны сагынып, тәүге иҗатыннан эпиграф китереп, шигырьләр язармын, дип хыялланып яши. Ләкин әкиятләр табылмый. Әткәе, авылның имамы Госман абзый белән Коргылды буенда, чират җитеп, авыл малларын көтүе дә сагышлы-моңлы хатирә булып хәтерендә саклана шагыйрьнең. Инешкәен, сыерлар таптап, тәмам кара сазлыкка әвереледергән ләбаса. Чишмә челтерәгән урынны исә чирләшкә җикән-камыш баскан. Инде шигырьләр язу белән ныклап мавыккан хисле егетнең хәтеренә уелган гүзәллек черегән, тәмам көл булган. Әткәе Госман абзый улының күңел халәтен аңлый һәм «Э-эх, менә шулайрак шул, улым, Коргылды инешебез авыр хәлдә, әйдә, бер шигырь әйт әле», – ди. Зөлфәт сөйли, әткәе аны бирелеп тыңлый. Шунда Госман абзыйның күңеленең яктыруы күзләренә үк бәреп чыга. «Улым, мин дә шушы инешебез турында бер мөнәҗәт чыгарган идем. Шуны сиңа әйтеп күрсәтермен, дип йөрдем, инде онытылган. Күңелдә йөргән уйларымны шул мөнәҗәттә әйтеп бетергән идем. Ашыйсын ашап, яшисен яшәгәнмен, күрәсең», – ди. Ул чакта әле Зөлфәт әткәе Госман абзыйның яман елларда җимерелгән авыл мәчетен яңадан тергезеп, манарага менеп, имам буларак, бердәнбер азанын әйтәсен дә, шуннан соң ук дөнья куясын да белми. Шуңа күрә: «Юк сүз сөйләмә әле, эткәй, әйтелмәгән сүз – яшәлмәгән гомер! Шигыреңне әйтми торып, Ходай сине үз катына чакырмас инде. Шигыреңне миңа мең кат укырсың әле» кебек сүзләр белән әткәенең фикерен кирегә бора.

Зөлфәтнең шигырьләренә беренче бәяне бирүчеләр дә аның әтисе һәм «шулкадәр нечкә, зәвыклы күңелгә ия» әнисе була. Зөлфәтнең бакчаларында корып куелган үз куышы бар. Аның барлык китаплары – шунда. Әнисе радиодан бер танылган шагыйрьнең шигырьләр укуын тыңлап ята. Тыңлый да: «И-и-и шул да булдымы шигырь! Менә ичмасам синекеләр шигырь!» – дип куя. Зөлфәт аптырап кала. Инәкәенә бер генә шигырен дә укытканы юк бит. «Каян белдең?» дип үзеннән-үзе сорап куя үсмер. «Соң куышыңа кергән идем, читәнгә кыстырган шигырьләреңне укыдым. Елап утырдым», – ди ана.

Уң кулында урак сабы эзе.
Сул кулында учма җылысы.
Нечкә иләк була бу кулларда.
Уклау була, җиләк тырысы...

Зөлфәт Маликов шагыйрь Рәдиф Гаташны үзенең укытучысы, ягъни «хәлфә»се дип атый. Үсмернең күзен шөпшә чагу сәбәпле укырга бара алмаган көннәре була бу, мәктәпкә Рәдиф Гаташ укытучы булып килеп төшә. Аңа «Безнең үзебезнең шагыйрь бар», – дип әйткәннәр, үсмернең иҗатын мактаганнар. Зөлфәт мәктәпкә килгәч, Рәдиф Гаташ аның янына килеп, шигырьләрен сорап ала һәм «Казан утлары» журналына җибәрә. Озак та үтми, Зөлфәткә Нури Арслан белән Әхсән Баянның шигырьләргә зур бәя биргән хатын китереп тапшыралар. Зөлфәт, университетка укырга керергә имтихан биреп йөргәндә, шигыре журналда басылып чыга. Әлбәттә, бу авыл баласы тарафыннан әйтеп ышанмый торган хәл кебек кабул ителә. Аннары әле студент та булып өлгермәгән, хыялый егетне, чын шагыйрь Рәдиф Гаташның үз иҗатын хуплавы да тәмам алгысыта! Һәм ул аның белән Казанга юл тота. Китаптан сеңгән тәэссоратлары аша Казанны күз алдына китереп бастырган Сөембикә манарасы күренгәч, егетнең йөрәге тагын бер кат җилкенеп куя. Аның күңеленнән «Ак яллы дулкыннар өстеннән сиңа килəм, Казан!» дигән хисси уйлар уза. «Чытырманда былбыл сайрый»дигән автобиографик әсәрендә язганча, ул әле Казанның күпме гасырлар гарасат кичергәнен дә, тарих вулканының кайнар лавасында утырганын да белми әле ул чакта. «Гаҗәеп бер китап икәнсең син, Казан! Мин аны әле соңрак кына белермен! Сөембикә манарасы мәңгелек ташка әйләнеп калган хатын-кыз үксүе икән ләбаса!» – ди ул.

Остазы Р.Гаташ мәхәббәт шагыйре булгач, егет тә, аңа ияреп, мәхәббәт шигырьләре яза башлый. Әмма язучы Ләбиб Лерон искәрткәнчә, Зөлфәт «Милләт!», «Азатлык!» дип кычкыручы да булмаган һәм, ихтимал, ярамаган да елларда әдәбиятка үзенең «Чакырылмаган кунак, татардан да яманрак» дигән затлы бер шигыре белән килеп керә һәм халык күңелен яулап ала. «Ул шушы шигыре белән безне сискәндереп җибәрде», – ди Л.Лерон.

Җилдерде ул дала атларында,
Гөслә чиртеп аю биетте.
Көрәш белән биеклекләр алды –
Заманына лаек биеклек.
Дастаннары аның урда кебек
Җан яулаган... Алга күченгән.
Чакырылмаган кунак булып үткән,
Үткән татар дошман өстеннән.
Чакырылмаган кунак булып кергән
Зимнийларга, Перекопларга...

«Шагыйрьнең халәте дөньяны аңларга түгел, ә аңлатырга тырышу. Имансыз яшәүдән курыккан кебек шигырьсез яшәүдән дә куркуйк», – дип яза үзе шагыйрь.

Кардәшләрем! Сезнең җанда туган
Шигырьләрне әйтер сүз көчен
Ни өчендер Ходай миңа биргән –
Өлешемә тигән көмешем...

Үз туган ягының, авылдашларының уй-хисләрен сеңдереп үскән шагыйрьнең беренче китабына бәяләмә авторы Хәсән Туфан «Бу яшь талантның остазы – халык үзе», дип юкка гына язмаган, билгеле. Зөлфәтнең һәр шигырендә кайнарлык, ярсу хисләрендә милләт гаме, халык гаме ярылып ята.

Данил Салихов: «Шагыйрь «Йөрәгемне былбыл чакты», – дип язды, ә аның үз шигырьләре татар халкының йөрәген чакты», – дип әйткән иде. Шагыйрьне Язучылар берлегенә кабул иткәндә Шәйхи Маннурның да «Мине «Тимер Маннур» дип әйтәләр, минем елаганым юк. Ә Зөлфәтнең шигырен укыгач чын күңелдән еладым», – дип әйткән сүзләре теркәлеп калган. Язучы Фоат ага Садриев «Зөлфәтнең шигырьләре – энергия йомарламы. Җәмгыятебездәге гаделсезлекләргә, татар милләтенә туры килгән җәбер-золымнарга карата аның йөрәгеннән кан тама, бәгыре телгәләнә иде – аның поэзиясендә шушы әйбер ярылып ята», – дип шагыйрь иҗатының асылын билгеләгән сүзләре дә хәтердә.

Остазы Р.Гаташ Зөлфәтнең чын мәгънәсендә бөек, уникаль шагыйребез булуы турында сөйли. «Зөлфәт тумышы белән шагыйрь иде: төс-кыяфәт, буй-сын да, сүзнең чын мәгънәсендә тәмен-көчен тоеп, сурәтләү-фикерләү сәләте дә Ходайдан бирелгәндәй, ачык, бәхәссез иде», – дип искә алды. Ул, каләмдәше Г.Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә тәкъдим ителгәндә, аның «Ходай сулышы» дигән китабына карата язган мәкаләсендә, аны Тукай буыны белән чагыштыра. «Бу гасырның башында Тукай, Дәрдемәнд, Сәгыйть Рәмиев, Бабич, Такташ, Туфан килә, ә гасырның ахыры бөек шагыйрь Зөлфәт белән тәмамлана... Зөлфәт мәктәбе, аның шигърияте үрнәгендә тулы бер буын шагыйрьләр тәрбияләнде», – ди.

Ике талантлы шагыйрь З.Маликов

белән Мөдәррис Әгъләмнең дуслар булуын беләбез. Зөлфәт Мөдәррис белән танышулары хакында видеоязмада болай сөйләде: «Кичәге көтүче малайлар бүген аудиториягә килеп керде. Карыйм, минем янымда маңгае кояшта кара чуен булып янган тәбәнәк кенә буйлы бер егет утыра. Бәй, Мөдәррис Әгъләмов түгелме соң бу? Шул! «Татарстан яшьләре» газетасында иң оста, иң тәҗрибәле язучылар гына яза алырдай шигырьләре әле яңа гына басылып чыкты лабаса! Чын шагыйрьнең утлы сулышы сизелеп тора. Гафу итегез, шулайрак мөрәҗәгать итәргә кирәклеген бераз чамалый башлаган идем инде, «Сез Мөдәррис Әгъләметдинов бугай?» Җавап мине аягымнан бәреп екты «Ну и что?» Болар шәһәрчә генә түгел, русча да әйбәт кенә сиптерәләр икән. «Мин дә шигырьләр язам» «Ну и что?»

(Дәвамы 10 нчы биттә).

Атнаның сәяси мизгелләре

ГЛОБАЛЬ АҢЛАШУЛАР АТНАЛЫГЫ

Атна глобаль планлы аңлашуларга бай булды. Ул Давоста уза торган Бөтендөнья икътисад форумыннан башланып китте. Быел аның темасы "Борылыш мизгелендә тарих" дип билгеләнгән. Соңгы 35 елда анда тәүге тапкыр Россия делегациясен чакырмаганнар. Аның каруы, беренче көнне үк форумда Украина президенты В.Зеленский чыгыш ясаган. Форумда исә дөнья икътисадына кагылышлы күп кенә мәсьәләләрдә хәрби тематика өстенлек иткән. Шуның белән бергә, анда көчле аналитик структураларның 30 дан артык чыгышы тыңланган, глобаль көн тәртибенең төп мәгънәләре формалаштырылган. Британиянең Oxfam дигән оешмасы мәгълүматларына караганда, пандемия чорында дөнья миллиардерларының гомуми байлыгы 5 триллион долларга арткан, шул ук вакытта фәкыйрьлек чигендә яшәүчеләрнең саны инде 657 миллион кешегә җиткән. Сәясәттә исә игътибарны АКШтан ике картлач – 99 яшьлек геосәясәтче Генри Киссинджер һәм 91 яшьлек миллиардер Джордж Сорос чыгышлары җәлеп итә. Беренчесе Киевкә, Мәскәү куйган шартларда сөйләшүләр үткәреп, Донбасстан баш тарту хисабына, ике ай эчендә хәрби операцияне туктатырга киңәш иткән. Геосәясәт патриархының мондый киңәше инде зур сәясәттә Көнбатыш һәм Россиянең, капма-каршы яктан, әмма уртак максатларда эш итүенә тагын бер дәлил булып тора. Миллиардер Дж. Сорос исә тулы җиңүгә ирешкәнчегә кадәр дәвам итәргә чакырган.

Узган атнада Бишкәктә зур Евразия икътисади берлеге илләренең (ә анда Беларусь, Казахстан, Кыргызстан, Россия һәм Әрмәнстан керә) Евразия икътисади форумы да тәүге кат узды. Әлбәттә, игътибарны Европа Берлегенең (ЕС) 30-31 майда Брюссельдә узган чираттагы саммиты карарлары да җәлеп итә. Очрашуның тәүге көнендә ЕС илләре Россиягә каршы санкцияләрнең алтынчы пакетын үзара килештерүгә ирешкән. Аның нигезендә, Россиядән алына торган нефтьнең өчтән ике өлешенә эмбарго кертелачәк икән, ә 2022 ел ахырына инде ЕС ул нефтьне фактик яктан 90 процентка киметергә ниятли. Нефтьтән тыш, алтынчы пакетка шулай ук Сбербанкны SWIFT системасыннан аеру, ЕС территориясендә Россия дәүләт мәгълүмат чараларының өчесенең эшен туктату кебек чаралар да керә.

Фоат УРАЗАЙ.

Сәйф Сараины камышлылар үз итте

Билгеле булганча, Алтын Урда татарның дәүләтчелек, этник, мәдәни-мәгърифәти тарихында гаять мөһим роль уйный. Евразиянең зур мәйданнарын ике гасырга якын биләгән бу мәмләкәттә болгар, кыпчак, татар, хәзәр һәм кайбер башка этник компонентлар кушылуыннан оешкан безнең әби-бабаларыбыз дөньяга инде тәмам татар атамасы белән таныла. Бу мәмләкәттә яшәгән, иҗат иткән каләм әһелләренең тик бер өлеш әсәрләре генә безгә хәзергә мәгълүм. Әмма аларда Җучи Олысындагы рухи тормышның байлыгын ачык күрәбез. Болар арасында аеруча Сәйф Сараиның "Гөлестан бит-төрки", "Сөһәил вә Гөлдерсен" әсәрләре мөһим урын били. Еш кына аның иҗатын Алтын Урда чоры татар сүз сәнгатенең кульминациясе дип тә атыйлар. Бу бөек затның тирән уй-кичерешле, сәнгати яктан камил әсәрләре инсани рух, әхлаклылык белән сугарылган. Алар тормыш дәреслеге кебек.

Мәгълүм ки, шагыйрь иҗатын гыйльми өйрәнү, нигездә, узган гасырның урталарында гына башлана. Әмма, шуңа да карамастан, бу юнәлештә инде шактый зур эш башкарыла. Сәйф Сараи әсәрләренең 1969 елда А.Бодроглигети тарафыннан әзерләнеп чыгарылган фәнни басмасы укучыларга билгеле бер дәрәҗәдә таныш. Татар дөньясында С.Сараи Әмир Нәҗип, Хатип Госман, Зәйнәп Максудова, Хатыйп Миңнегулов... тарафыннан шактый өйрәнелгән. 1999 елда шагыйрьнең барлык әсәрләре "Гөлестан. Лирика. Дастан" исеме астында Казанда аерым җыентык рәвешендә дә басылып чыкты. Бу юлларның авторы тарафыннан әзерләнгән бу китап тиешле шәрех-аңлатмалар, кереш һәм ахыргы мәкалә белән тәэмин ителгән.

2021 елда шагыйрьнең тууына 700 ел тулу шактый киң күләмдә билгеләп үтелде. Сәйф Сараиның юбилее уңае белән төрле гыйльми, мәдәни чаралар да уздырылды. Бу юнәлештә аеруча Татарстан Фәннәр академиясе, Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институты, аның Алтын Урда бүлеге (җитәкчесе – Илнур Миргалиев) бигрәк тә нәтиҗәле эшләр башкарды. Мәсәлән, 2021 елның 15 июнендә Сәйф Сараига багышланган халыкара конференция гыйльми-иҗтимагый мөһим бер вакыйга рәвешендә кабул ителде. Конференция җыентыгында шагыйрьнең тормышы һәм иҗат мирасы Идел-йорт, Алтын Урда, татар тарихы белән тыгыз бәйләнештә карала. С.Сараи бер робагыенда болай яза:

Камышлы йорт бәнем
туган илем иде,
Белең: горбәтҗә килтергән –
белем иде.

Килеб улдым Сарайда шийр фидае (ягъни шигърияткә бирелгән кеше – **Х.М.**)

Сарайның шагыйре – илнең гидае.

Димәк, ул "Камышлы" төбәгендә туган, яшәгән, бераздан Алтын Урда башкаласына укырга килгән һәм биредә каләм әһеле буларак танылган. Билгеле булганча, бу исемдәге торак пунктлары Идел-йортта элек тә, хәзер дә бернечә. Равил Фәхретдинов, Габдрахман Таһирҗанов, Илнур Миргалиев һәм кайбер башка галимнәр робагыйда телгә алынган "Камышлы"ны хәзерге Самара янындагы район үзәгенә нисбәт итәләр. Алар фикеренчә, бу исемдәге торак пункты биредә Җучи Олысы чорында ук булган. Әлбәттә, шагыйрьнең туган елы, урыны мәсьәләсенә өстәмә факт-мәгълүматлар табылмыйча, тәмам нокта куярга әле иртәрәк. Әмма югарыдагы карашның да яшәргә хакы бар. Чөнки ул шул чор чынбарлыгы белән гомумән каршылыкка керми. Мәгълүм булганча, Урта Идел, хәзерге Самара төбәкләре – Болгар, Алтын Урда чорларында ук әби-бабаларыбыз гомер кичергән, икътисади, мәдәни-мәгърифәти яктан мөһим урыннар. Бу төбәктә соңгы вакытта Ш.Мәрҗани институты хезмәткәрләре, Самара өлкәсенең галимнәре белән берлектә җирле тарихны өйрәнү эшен тагын да көчәйтеп җибәрделәр. Уртак проектлар гамәлгә ашырыла, гыйльми чаралар уздырыла. Казанда үткәрелгән С.Сараи конференциясендә дә бу төбәкнең, аеруча Камышлы районының вәкилләре, актив катнашты. Мәгълүм ки, 1391 елда Кондырчы елгасы буенда Урта Азия хөкемдары Аксак Тимер белән Алтын Урда ханы арасында гаять күп корбаннар китергән зур сугыш була. Анда татар ханы Туктамыш җиңелә. Хәзерге Үзбәкстан хакимияте, шул тарихи вакыйга уңае белән, сугыш булган урында Аксак Тимергә һәйкәл куярга теләгәч, Самара төбәгенең татар җәмәгатьчелеге бу проектны гамәлгә ашыруга кискен каршы чыкты. Бу хәрәкәттә ул Казан галимнәренең дә төпле яклавын тапты.

Самара төбәгендә Сәйф Сараига мөнәсәбәтле аерым чаралар да үткәрелде. Шундыйларның берсе 2022 елның 17 маенда Камышлыда булды. Төбәкара фәнни-гамәли конференция – "Сәйф Сараи укулары – 2022" исеме белән уздырылды. Нигездә, Камышлы район хакимияте, Ш.Мәрҗани институты, Бөтендөнья татар конгрессы тарафыннан оештырылган бу чарада Татарстанның гыйлем әһелләре, журналистлар белән берргәттән, Самара өлкәсенең, аеруча Камышлы төбәгенең галимнәре, мәдәният һәм мәгариф хезмәткәрләре катнашты. Мәктәп балаларының җырбиюләре, С.Сараи шигырьләрен сөйләүләре, доклад-чыгышлар бу чараны тагын да баета төште.

Шунысын да искәртик: камышлылар Сәйф Сараины тәмам диярлек үз якташлары дип саный. Район китапханәсендә, мәсәлән, бөек шагыйрьгә бай эчтәлекле махсус стенд ясалган. Хәтта С.Сараиның исеме, шагыйрьләре язылган полиэтилен пакетлар да гамәлдә.

Камышлыдагы гыйльми-гамәли конференция район хакимияте башлыгы Рафаэль Камил улы Баһаветдиновның тәзек, камил татар телендә сәламләве, эчтәлекле кереш сүзе белән башланып китте. И.Миргалиев татар тарихы, С.Сараи хакында, ике төбәк арасындагы бәйләнешләр турында кызыклы мәгълүматлар бирде, юбиляр-шагыйрьнең әдип кенә түгел, күренекле дәүләт эшлеклесе булуына да басым ясады, камышлыларга, район китапханәсенә Ш.Мәрҗани институты әзерләгән, аның катнашында дөнья күргән бик кыйммәтле басмаларны (шул исәптән, Мәхмүд Болгарины "Нәһҗел-фәрадис" китабын да) бүләк итте. И.Миргалиев инициативасы белән Түбән Камада яшәүче билгеле рәссам Илдус Мортазин тарафыннан ясалган С.Сараи портреты да тантаналы төстә хуҗаларга тапшырылды. Еш кына элеккеге күренекле затларыбыз шактый өлкән кешеләр рәвешендә гәүдәләндерелә. Портреттагы С.Сараи исә көчле, куәтле, ир уртасындагы шәхес рәвешендә сурәтләнгән.

Без фәкыйрегезнең һәм Эльмира Сәйфетдинованың докладларында С.Сараи тормышының һәм иҗади эшчәнлегенең төрле яклары яктыртылды. Казан әдибәсе, әнисе ягыннан татар булган Ольга Иванова халкыбызның урта гасырлардагы аерым күренекле затлары (Нурсолтан, Гәүһәршад, Сөембикә) трилогиясе һәм кайбер башка әсәрләре белән укучылар арасында шактый танылып килә. Әле 2021 елда гына аның "Великая Орда" дигән күләмле (592 битлек!) китабы дөнья күрде. Аның хәзерге вакытта С.Сараи хакында тарихи роман язуын залдагылар бик хуплап кабул итте.

Тарих фәннәре докторы Искәндәр Измайлов Алтын Урдага шактый тулы сыйфатлама бирде. Самара төбәген өйрәнү җәмгыятенең җитәкчесе Шамил Галимов үз докладында Урта гасырлардагы Иделйорт тарихына кагылышлы мөһим мәсьәләләрне күтәрде.

Мәгълүм ки, күп кенә рәсми белешмә-энциклопедияләрдә Идел-Урал киңлекләрендәге шәһәр-авылларның килеп чыгышы күпчелеге бу җирләр Россия дәүләте составына кертелгәннән соңгы елларга нисбәт ителә. Шуңа карап еш кына төрле юбилей-бәйрәмнәр дә үткәрелә. Әйтерсең лә Урта һәм Түбән Идел буйларында XVI-XVII гасырларга кадәр кала-салалар булмаган, безнең әби-бабаларыбыз яшәмәгән. Ш.Галимов фикеренчә, хәзерге вакытта киң таралган мондый рәсми караш объектив тәнкыйтькә мохтаҗ.

Әстерхан, Сарытау, Сарычин һәм кайбер башка билгеле шәһәрләр кебек, Самара да Алтын Урда чорында ук яши. Ул бертуган Пицциганилар, Фра Мауро карталарында (1367, 1459) ук Samar атамасы белән теркәлгән. Кайбер галимнәр фикеренчә, бу шәһәрчек Болгар чорында барлыкка килә.

Җөмһүриятебезнең көньягына терәлеп торган Камышлы районындагы халыкның 86 процентын милләттәшләребез тәшкил итә. Юкка гына аны, кайвакыт "Кече Татарстан" дип йөртмиләрдер. Районның табигате матур, җирләре уңышлы. Юллары да начар түгел, кешеләре дә чагыштырмача мул яши. Йорт-каралтылар тәзек. Әмма шунысы пошындыра: элек милли тормыш кайнап торган, татар мәктәп-мәдрәсәләре гөрләп эшләгән Камышлы төбәгендә русча укытуга күчкәннәр. Мөгаен, шул сәбәпле русча сөйләм еш яңгырый. Конференция район үзәгендәге урта мәктәптә узды. Анда, нигездә, милләттәшләребезнең балалары белем ала. Әмма, ни кызганыч, мәктәптә татарча сөйләм бик ишетелми. Халкыбызның сакланышы, иң беренче чиратта, туган телдә укытуга, милли мәгарифнең тулы канлы яшәвенә бәйле. Әгәр дә без бу тарихи хакыйкатьне, тормыш тәҗрибәсен онытсак, С.Сараи әйткән шулай булырга ярамаганлыкка "гыйбрәтле" мисал булып калырбыз:

И ничәләрне күрептер бу җиһан,
И ничәләрдән дәгый артып калыр!
Сән алардан алмасаң
гыйбрәт бу көн
Таң белән сәндан болар
гыйбрәт алыр.

* * *

Хәзерге вакытта Ш.Мәрҗани исемендәге Тарих институтында Самара өлкәсе галимнәре катнашында С.Сараи, Камышлы төбәге турында махсус фәнни җыентык әзерләнә. Шөт, ул тиз арада укучыларыбызга барып ирешер.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ,
филология фәннәре докторы.

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

Йөзлек белән туганмын мин...

ӨЕҢДӘ КӨТСӘ ЯРАТУ*

(җыр)

Көтсә өеңдә ягымлы күзләр,
Каршы йөгерсә кадерле сүзләр –
Елмаер кояш кара төнеңдә,
Җылы тоелыр салкын көне дә.

Көтсә өеңдә ихлас ярату,
Мөмкиндер анда кайгың тарату.
Авыр уйларың качар, онтылыр,
Шундый бер көнең мең алтын торыр.

Көтсә өеңдә тәрбия, терәк,
Син диеп типсә анда һәр йөрәк,
Бәрәкәт иңәр бердәм нигезгә,
Тәгәрәр дөньяң төздә, тигездә.

Көтсә өеңдә кадер вә хөрмәт,
Сиңа дип пешкән ләззәтле нигъмәт. –
Үрнәк алып бу тату тормыштан,
Тәрбия күрер бала тумыштан!

*Илназ Баһ көе.

ТОРМЫШ ЯМЕ

Бисмилламны әйтеп токмач кисәм,
Ак яулыгым ябып башыма.
Тел өстендә генә тотарлык ул,
Туганнарым килсен ашыма.

Билләремдә чиккән ак алъяпкыч,
Кош телләре кисәм кыйгачлап.
Күпереп пешсен, сары майда йөзеп,
Күзегез кызсын, үзегез туйгач та.

Бәлеш салам, белгәнемне укып,
Каз итеннән, кайнар, шулпалы.
Чөкердәшеп чәйләп утырыйк соң,
Күршеләрем дәшим, туктале.

Бер сөйләрлек булсын, аш-суының
Теш төбендә калды тәме, дип.
Кардәш-ыру, дус-иш белән яшәү
Дөньяларның яме, гаме бит!

ИПИ ПЕШӘ

Кичке авыл мичләрендә
Утын яна әчләрендә:
Дөрли генә яркалары,
Сикерә ут алкалары,
Очып-очып китә шартлап,
Бабам тора мичне мактап,
Сырхау әбием терелә,
Йөзкәеннән нур түгелә.
Кинәндереп һәр күңелне
(Мәшәкате дә күңелле),
Бар кайнарлыкны сеңдереп,
Ипи пешә бөтерелеп.

СӘКЕ

Сәке безнең өстәл иде,
Сәке – безнең карават.
Кирәк икән, чәй эч шунда,
Кирәк икән, кырын ят.

Сәке безнең сандык иде,
Каз оясы сыярлык.
Сәке асты сарай иде,
Ярган утын куярлык.

Сәке түренә өелгән
Түшәк, ястык, мендәре...
Сәке – әби-бабаемның
Намаз укыр мөнбәре.

Йорт-җиремнең төп җиһазы
Сәке булган элгәре.
Әйтерсең шунда төйнәлгән
Җир һәм Җиһан егәре!

ЧИККӘН СӨЛГЕ

Чиккән сөлге – яшьлек истәлегем:
Яз гөлләре, моңлы гөрләвек.
Чиккән сөлге – минем гомер юлым:
Кышкы буран, җәйге күлләвек.

Чиккән сөлге – яшел урман юлы:
Күзгә сагыш, кышкы бозлавык.
Чиккән төсләремә карыймын да
Эндәшалмый торам беравык.

Чиккән сөлге – бүләк балаларга, –
Күзләремнән кучкән нурларым.
Ничәмә төс, ничә җыру анда –
Һәр төсендә минем кулларым.

Чиккән сөлге – әниләре төсе,
Сагынганда искә алырлар.
Янып торган яз бизәге чиктем,
Гомер үтәр,
Гөлләр калырлар!

БИЮЧЕ КЫЗГА

Әкияттәнме әллә син, бала?
Аяк баскан саен моң кала.
Күңелләрдә, җанда, күзләрдә –
Соклану һәм табыну сүзләрдә,
Әкияттәнме әллә син, бала?

Хәрәкәтең бирсен бәрәкәт,
Җилдән җитез йөреш-хәрәкәт.
Биегән кеше чынлап бай булсын,
Хыялында йөгерек тай булсын,
Хәрәкәтең бирсен бәрәкәт.

Онытылмасын гадәт-горефләр,
Кубәү булсын синең кебекләр.
Күз тимәсен сылу гәүдәңә,
Бие әйдә, көчең җәлләмә,
Онытылмасын гадәт-горефләр.

«ТАТАР КЫЗЫ БИЮЕ»Н КАРАГАНДА

Чулпыларын чылтыратып,
Кем бии әнә, кара.
Аягүрә баскан килеш
Әйтерсең йөзеп бара.

Тыпырдатып биер өчен
Имән идән димәгән.
Ничек шулай назлы иткән –
Бер җире юк килмәгән.

Табигать яраткан аны
Дөньясында бер итеп:
Карап туймас нәфис итеп,
Тоташ наз һәм сер итеп!

ЙӨЗЕМНЕ АК ИТКӘН КЕШЕМ

Йөзлек белән туганмын мин,
Туганда ук.
Җир йөзеннән куганда су,
Куганда ут,
Саклап калган шул йөзлегем,
Иткән ярдәм.
Йөземне ак саклар өчен
Япкан пәрдәм!
Йөзлек белән туганмын мин,
Туганда ук.
Башымда – уй, җанымда – җыр,
Йөрәктә – ут.
Ярты юлда туктап калмам
Бер эштә дә.
Рәхмәт яусын әнкәемә,
Йөземне ак иткән кешем –
Фәрештәмә!

ТАНЫП КАЛСЫННАР

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – көмеш каш белән.
Кисеннәр аны яхшы күңелләр:
Җиту кыз-кыркын, чая киленнәр,
Кыңгыр салсыннар назлы сеңелләр.

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – энҗе таш белән.
Киеп йөрсеннәр нечкә билләләр,
Ирсезләр кисен, кисен ирләләр,
Якын килмәсен керле күңелләр.

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – җәүһәр каш белән,
Шөһрәт казансын изге канлылар,
Милләтен сөйгән туташ-ханымнар,
Илһам алсыннар шагыйрь җанлылар.

Такыя чигәм асылташ белән,
Нәкыш бизәге – алтын каш белән:
Кашлары җем-җем, торадыр көләп,
Танып калсыннар – кемлекне белеп,
Сәлам бирсеннәр – ерактан күреп!

ХИКМӘТИ СЕР

Баланы таба ул һәр тере,
Нәселен, дәвамын калдыра.
Кайберсе шатлыклар китерә,
Кайберсе йөрәкне яндыра.

Баланы таба ул һәр тере,
Күңелнең аңарга иң түре.
Әнәле – мамыктай тоела,
Учыңа йолдызлар коела.

Баланы таба ул һәр тере,
Бик теләп, бик көтеп аласың.
Өметең акланмый кайчакта,
Телсезләр, ушсызлар каласың.

Баланы таба ул һәр тере –
Тормышның хикмәти бу сере
Йә сине күкләргә күтәрә,
Җиреңә озата йә кире...

ГОМЕР

Җир яңара –
Гөлләрдән гөл ярала,
Уй кагыла,
Кагыла, моң тарала.
Гөлчәчәкләр йә баса, йә чүгәли,
Әйләнәләр итәк җилем тирәли.
Тымызык көн ләйсән яңгыр бөркеде,
Үсеп чыкты ак күбәләк төркеме.
Юлга ятты шәфәкъ кыйган кыйпылчык
Күләгәңне алдымнан ал, кояш, чык!
Күз алдыннан нурлар, уйлар аксыннар,
Йә боз булып,
Йә куз булып ятсыннар –
Бу чагылыш яшәвемнең бер көне,
Бер көнемме? –
Гомеремнең бөртеге...
Мин йөгерәм,
Йөгерәм – көн яктыра,
Әле сулга,
Әле уңга чакыра.
Хәтерләтеп аңлы сабый чагымны,
Көлтә-көлтә нур төргән дүрт ягымны.
Төшәм төпкә,
Төпкеленә җиремнең,
Өлеш чыгар кодрәтеннән иремнең!
Ыргылмаска,
Ургылмаска юк чарам,
Төбенә төшми,
Җиренә җитми тукталмам.
Күккә менәм,
Яшен белән үртәшәм,
Үчекләшәм,
«Үчкә – үч» дип эндәшәм.
Хисләремнән исәнгерим мин тәмам,
Очам-кочам,
Янам-эрим һәм тамам...
Бер хәсрәт – гомеремнең мең төне,
Шатлыгымны?
Мең төнемнән бер көне...
Куз алдымнан утлы уйлар агыла,
Үткәнемә,
Үпкәнемә кагыла...

ГОМЕРЕМНЕ ТҮЛӘП**

(җыр)

Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды
Шигъри дөнья,
Бәллүр бишегендә тирбәтеп,
Бәллүр бишегендә тирбәтеп.
Йөрәкләрне әсир итте Сөю,
Әсир итте
Йөрәкләрне
Шул Сөюнең шигъри ширбәте,
Шул Сөюнең шигъри ширбәте.

Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды
Шигъри дөнья,
Йолдызларга кадәр күтәреп,
Йолдызларга кадәр күтәреп.
Шифа көтсәм, утлы яңгыр койды,
Утлы-бозлы
Яңгыр койды,
Үзәк-бәгырьләргә үткәреп,
Үзәк-бәгырьләргә үткәреп.

Шигъри дөнья безне кавыштырды,
Кавыштырды
Шигъри дөнья,
Сөю назларында көйдереп,
Сөю назларында көйдереп.
Гомеремне түләп җырлар яздым,
Гомеремне
Түләп яздым,
Шигырь буынына сеңдереп,
Шигырь буынына сеңдереп.

**Сара Садыйкова көе

РЕДАКЦИЯДӘН. **Иртәгә танылган шагыйрә, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, С.Сөләйманова, А.Алиш исемендәге әдәби бүләкләр иясе, милли мәгарифне үстерүдәге казанышлары өчен К.Насыйри исемендәге премия лауреаты Эльмира Шәрифуллинага 75 яшь тула. Без каләмдәшебезне күркәм гомер бәйрәме белән тәбрик итәбез, аңа исәнлек-саулык һәм яңадан-яңа иҗат куанычлары теләп калабыз.**

Мәдәни җомга
3 июнь
№21, 2022

Төньяк Корея – цивилизацияле кешелек өчен искелек калдыгы булган тыюларга бай дәүләт. Ләкин шушы дәүләттәге яшәешне аңларга теләүчеләр, Корея хакында укыгач, үз илләрендә яшәүләренә сөенеп туялмас.

Акны кара димәскә,

Кореялылар күп еллар Кимнар династиясе җитәкчелегендә генә көн күрергә мәҗбүр. Риторик сорау туа: әгәр әлеге илгә... җитәкче итеп башка холыктагы адәм куелган булса яисә бу халык аны шулкадәр мактап күккә чөймәсә, аңа табынмаса, ул бәхетлерәк булыр идеме икән?!

Төньяк Кореяда 2022 ел дип язмыйлар. Чөнки биредәге календарь Ким Ир Сенның туган елыннан, ягъни 1912 елның 15 апреленнән башлана. Ил халкын Ким Ир Сен уйлап чыгарган чучхе дәүләт идеологиясе берләштерә. КДХР белән әлеге җитәкче 1994 елга кадәр, үлгәнче идарә итә. Ул үзе исән чагында да, вафат булгач та «Бөек юлбашчы иптәш Ким Ир Сен» дигән титулга лаек. Ким Ир Сен социализм һәм коммунизмга ышанса да, еллар узу белән ил вәзгыяте үзгәрә. Дәүләт өчен коммунизм түгел, чучхе идеяләре яхшырак санала башлый. Төньяк Корея хакындагы язмаларга күз салганда, аның бик үзенчәлекле булуы күзгә ташлана. Беренчедән, ул – дөньядагы... некрократия җитәкчелегендәге бердәнбер дәүләт. Чөнки Ким Ир Сенның үлеменнән соң дүрт ел үткәч, 1998 елның 5 сентябрендә Ким Ир Сенга (1912-1994) КХДРның Мәңгелек Генераль секретаре дигән титул бирелгән. Димәк, ул рәсми рәвештә – Төньяк Кореяның «мәңгелек идарәчесе». Аны күккә чөеп мактау кайчан башланган? Ким Ир Сенга алтмыш яшь тулгач та. Аны Бөек Юлбашчы, Милләт Кояшы, Куәтле Республика Маршалы, Кешелекне Азат Итүнең Ышанычы дигән титуллар белән зурлаганнар. Портретларын барлык биналарга элеп куйганнар. Метрополитен һәм поезд вагоннарына да җитәкче сурәтләре генә беркетелгән. Кореядагы тау битләренә берничә метр озынлыктагы хәрефләр чокып, аның исәнлегенә яхшы теләкләр язылган. Тормыш юлын, ил өчен нинди батырлыклар кылуын яттан өйрәнү балалар бакчаларында башланып, мәктәпләрдә, югары уку йортларында да дәвам иткән. Ул турында урыннарга истәлек такталары беркетелгән. Теләсә кайсы җырда да аның исеме әйтеп җырланган. Барлык балалар бакчасындагы сабыйлар аңа бәхетле балачаклары өчен рәхмәт укырга тиеш булган.

Икенчедән, бу ил – үз кагыйдәләрендә абсурдлык дәрәҗәсенә җиткән илләрнең берсе. Әйтик, Төньяк Кореяда яңа туган балаларның дәүләт башлыгы исемен йөртергә хакы юк. Бу, билгеле, беренче тапкыр кертелгән тыю кагыйдәсе түгел: 2011 елда Ким Чен Ынның әтисе Ким Чен Ир шундый тыю хакындагы карар чыгарган булган, ләкин мондый карар беренче тапкыр Ким Ир Сен вакытында ук кабул ителгән инде. Сүз уңаеннан, 2011 елны Ким Чен Ир вафат булгач та, илдә иптәшләр судлары уздырылган. Аларда үз юлбашчылары үлеменә тиешенчә, акылдан шашар дәрәҗәгә җитеп, кайгырып еламаган гади кореялыларны хөкем иткәннәр. Хезмәт коллективлары күрсәтмәләре буенча, җиде мәңгә якын кореялы тиешенчә еламаган өчен төрмәләргә эләккән. Өстәвенә, 8 июльдә – Ким Ир Сен, 17 декабрьдә Ким Чен Ир вафат булганга күрә, бу көннәрдә туганнарның үз туган көннәрен билгеләп үтәргә, шатланырга хаклары юк. Гомумән, Ким Чен Ир үлгәч, илдә өч еллык траур башланган. Әйе, әтисен алыштырган улы да «Яраткан җитәкче» титулына ия булды, дүрт тапкыр КХДР Герое дәрәҗәсенә ирешкән Ким Чен Ир (1941-2011) шулай ук бу дәүләт белән үлгәнче идарә итте. Аны да әтисеннән ким мактамадылар. Аның тормыш юлы да яттан өйрәнелгән, барча китаплар аның цитаталары белән башланган, исеме дә мәгълүмат чараларында һәрчак калын хәрефләр белән генә бастырылган, аңа багышлап җырлар язылган, шигырьләр сөйләнгән... Туган көне исә дәүләт бәйрәме күләмендә билгеләнгән. Ул искиткеч сәләтле композитор да икән: 2 ел эчендә 6 опера язган. Ул әле гаҗәеп талантлы архитектор да, төрле проектлар әзерләгән...

Ил капитализмга каршы. Кореялыларга зәңгәр джинсы тукымадан тегелгән чалбар кию тыела. Чөнки зәңгәр джинсы чалбар – капитализм калдыгы. Хатын-кызлар да кыска итәк кими. Ә менә илне күрергә килгән туристлар мондый джинсы чалбарларын кия ала. Бу илдә яшәүчеләрнең тышкы кыяфәте дә катгый таләпләргә буйсындырылган булуын искәртеп торырга кирәкме икән?! Рәсми карар нигезендә ир-атлар чәчләрен – нибары 10, ә хатын-кызлар нибары 18 төрле итеп кенә кистерә ала. Хатын-кызларга чалбар кию рөхсәт, әмма ул бик кың итеп тегелгән булырга тиеш.

Биредә чит ил гражданнарына кагылышлы бинаһа тыюлар бар (Рәсми булмаган мәгълүматлар буенча, пандемиягә кадәр КХДРга елына 120 мең кытайлы һәм 5 мең диярлек башка дәүләт вәкилләре килеп китә торган булган). Алар өчен кабул ителгән тәртип һәрчак бертөрле: туристлар бары тик төркем составында гына керә ала, туристларга индивидуаль виза бирелми. Паспорт контролен үтүгә үк, аларны махсус хезмәт вәкилләре, җирле гидлар каршы ала һәм алар килгән туристлар артыннан нык күзәтә. Туристлар автобусларында да күзәтүче утырып йөри. Туристларга үз теләкләре белән кая да булса сәяхәт итү катгый тыела. Шулай ук аларга кунакханәдән чыгып китәргә, кибеткә барып килергә дә ярамый, мондый гамәлләрне гидлар рөхсәте белән һәм төркемгә ияреп кенә кылырга мөмкин. Үз теләге буенча урамда йөреп керү – җитди тәртип бозу. Аларга экскурсоводлардан башка кем белән булса әңгәмә кору да тыела. Һәрхәлдә, Төньяк Корея халкы үзләре дә чит ил гражданнары белән сөйләшергә атлыгып тормый, чөнки бу алар өчен үлем белән бер. Биредә бернинди дин кануннары пропагандасы алып барыла алмый. Илдә бер генә «дин». Ул да булса – чучхе хезмәте «дине». Калган диннәр тыелган. Ил гражданнарын фотосурәткә төшерергә дә ярамый. Хәрби һәм дәүләт дәрәҗәсендәге объектларны фотога төшерү шулай ук тыелган, ә андый исемлеккә мондагы барлык зур биналар һәм корылмалар кертелгән. Асылда, юлбашчыларның һәйкәлләрен һәм алар сурәтләнгән плакатларны гына фотога төшерергә мөмкин. Һәйкәлләргә якынлашканда да җитди таләпләр үтәлергә, әйтик, киемнәрдәге бар төймәләр дә төймәләнгән булырга тиеш...

КХДР кануннарын үтәмәү аяныч нәтиҗәләргә китерә. Мәсәлән, 2016 елны АКШ студенты Отто Уормбир кунакханә диварында эленеп торган агитация плакатын үз белдеге белән алып куйган өчен кулга алынган иде, ул шуның өчен... ел ярым гомерен төрмәдә үткәрде. Аны үз Ватанына кайтару өчен бик зур тырышлык куелды, җитди сөйләшүләр алып барылды. Бу ир-атның сәламәтлеге шулкадәр дәрәҗәдә начарланган булып чыкты, ул

кайткач хастаханәдә үлде. Шушы трагедиядән соң АКШ хакимияте үз гражданнарына Төньяк Кореяга бару өчен виза бирүне туктатты.

Ил армиясенә игътибар – беренчел. КХДР – милитаризмның чын үрнәге, хәрби көчләр өчен биредә акча кызганмыйлар. Хәрбиләр сан ягыннан гаять дәрәҗәдә күп. Армиядә ир-атлар да, хатын-кызлар да җитәрлек. Төньяк Корея армиясе 2018 елда сан ягыннан дөньяда бишенче урынга чыга (1,2 млн кеше). Ә илдә 25 миллионнан артык халык яши. Әмма шул ук вакытта Төньяк Кореядагы электр инфраструктурасының күп өлеше гаять искергән, аны яңарту акрын хәл ителгәнгә күрә, кич белән биредә электр утлары аз яна. Шуңа да карамастан Көньяк Корея чигенә терәп төзелгән буш калада иртәдән алып аттракционнар гөрли. Имеш тә, бу калада яшәүчеләр бик бәхетле! Балаларны бирегә иртә белән үк махсус автобуслар китерә. Башка халык та бу буш калада эш урыныңда эшләгән кыяфәт чыгарып йөреп, кичкә үз калаларына кайтарып куела... Һәркөн шулай. Көньяк кореялылар белсен: биредә – хәрлек һәм бәхетле тормыш!

КХДРда кесә телефоннарын дүрт миллионнан артык кеше куллана. Ләкин җирле сим-карталар фәкать ил эчендә шалтырату мөмкинлеген генә исәпкә алып җитештерелгән. 2013 елдан алып бар телефоннар да махсус «имзалар»ы булган видео, аудио, текст файлларын гына ачарлык системага көйләнгән. Башка дәүләтләр белән элемтәгә чыгып булмый. 2007 елны телефоннан башка илгә шалтыратучы бер бәндә үтерелгән. Чит ил кешеләренең, киресенчә, әчке линияларны куллану мөмкинлеге юк. Бу таләпләрне бозучыларны катгый җәза көтә. Әйтик, 2013 елда Төньяк Кореяның 80 кешесе, операцияләр системасын ватып, Көньяк Корея сериалларын караган өчен... үлем җәзасына тартылган; 2014 елда шушындый ук җинаять өчен җәзалап үтерелгәннәр саны иллегә җиткән. Башка дәүләт җыр-көйләрен тыңлау да тыела. 2015 елда Ким Чен Ын тарафыннан кабул ителгән, дәүләт тарафыннан тыелган җырлар булган бар кассеталарны, дискларны җыеп юкка чыгару хакында карар үтәлә.

Иң аянычы: бу дәүләттә «өч буынны җәзалау» карары хөкем сөрә. Ягъни әгәр дә берәр кеше төрмәгә эләксә һәм аннан качса, аның нәселендәге өч буын вәкилләрен дә төрмәләргә яисә концентрацион лагерьларга ябып куячаклар. Интернетта: «Мондый концентрацион лагерьларда 200 мең кеше яши һәм аларның 40 проценты ачтан үлә», диелгән хәбәр дә бар.

Гражданнар тыңлаучан булсын өчен, һәрбер хуҗалык һәм мәшгульлек өлкәсе биналары дәүләт тарафыннан контрольдә тотылган радиоалгычлар белән җиһазландырылган, ул радиоалгычларны сүндереп куярга ярамый.

Кореялылар телевизордан нибары дүрт канал тапшыруларын гына карый. Замана интернетсыз да була алмый, яшьлеген Швейцариядә үткәргән Ким Чен Ын моны яхшы аңлый. Әмма компьютер технологиясе – илдәге режим өчен куркыныч. Интернет бары тик дәүләт оешмалары, дипломатлар өчен генә тулысынча кулланышта, әмма аларга да дөнья челтәренә чыгу өчен рөхсәт сорау таләп ителә. Илнең үз интернет челтәрендә – өч дистәгә якын сайт, аларда да чучхе идеяләренә каршы килмәгән уку-укыту әсбапларын, техник әдәбиятны гына укып була, калган барлык сайтлар да яңалыклар, киңәшләр, аш-су хәзерләү темасына гына багышланган. Халыкка интернетның кирәксезлеге капитализм үтеп керү куркынычы белән аңлатыла. Башкача мөмкин дә түгелдер. Чөнки Ким Чен Ын үз илендәге реформалар хакында: «Кояш Көнбатыштан чыгар, әмма без социализмнан баш тартмабыз!» – дип белдергән.

Әлеге илнең капкалары башкалар өчен ябык. Кореялылар рөхсәтсез чит дәүләтләргә чыга алмый. Ил – моноэтник, биредәге халыкның 99 проценты – кореялылар. Карталарда да... бер генә Корея сурәтләнгән, Көньяк Корея хакында сүз юк. Әмма моңа кечкенә балаларны,

мәктәп укучыларын гына ышандырырга мөмкиндер... Чөнки Төньяк Кореяның шактый күп гражданнары Кытай аша Көньяк Кореяга кача алган, ә бу юл үлем, авыр михнәтләр белән тулы... Инде Көньяк Кореяга барып җитеп, анда тук тормышта гомер итә башлаган кореялылар үз ватаннарындагы газапларын тасвирлап, китаплар нәшер итсә дә, бу әлеге тоталитар дәүләт өчен куркыныч түгел.

стралиядә гомер итүче рус егете Михаил Зарубин. Былтыр ул әлеге илне үз күзләре белән күреп, фикерләре белән уртаклашты: «Ким Ир Сенның монда 48 төрле титулы бар. Ул аларны рәсмиләштереп калдырган. «Бөектән-бөек юлбашчы», «XXI гасырның юл күрсәтүче йолдызы», «Якты кояш»... Аның портретына карап авыз еручы табылса, аны ун елга хезмәт лагерена олактырачаклар. 50 ел элек капиталистлар манерасы»нда кистертүче табылса, ул үзе дә, чәчтараш та 5 елга хезмәт лагерена ябылачак. Бергәләп җыелышу һәм күңел ачу тыелган. Тыелган сәгатьләрдә яисә траур вакытында аракы эчүчеләрне атып үтерәләр».

Михаил Зарубин язмаларын укыгач, чәчләр үрә тора. Бер ир-ат үз истәлекләрен сөйләп, шул хакта да өстәгән: «Ким Чен Ир үлгәч, Санкт-Петербургта эшләүче күн плащлар кию модага кереп киткән. Чөнки Ким Чен Ын халык алдына бик тә кыйммәтле, сыйфатлы кара күн плащ киеп чыккан. Аннан күреп, аның сеңлесе дә шундыйрак плащ тектергән, аларга карап һәм юлбашчыга охшарга тырышып – бай кореялылар да, боларына ияреп гади халык та... ясалма күннән кара плащлар тектергән. Моны күреп, Ким Чен Ын үз плащының дәрәҗәсе төшүен аңлаган һәм Мода полициясенә башка кешеләргә кара плащлар кию катгый тыела дип кагыйдә кертергә һәм кием сатучылардагы бар арзан плащларны да конфискацияләргә туры килгән...

күн плащлар кимәскә

Билгеле, дәүләттә уңай яклар да юк

Чөнки биредә Корея Хезмәт партиясе, чучхе идеяләре генә чәчәк ата. Партия билеты булган затлар – яхшы кешеләр рәтендә. Алар җәмгыять тарафыннан ихтирам ителә. Режим турындагы теләсә кайсы уңышсыз көлке сүз аны әйткән кешене юкка чыгара. Биредә гади халык кол булып туа, кол булып үлә.

15 апрель – Кояш көне, дәүләт бәйрәме. Ә Милләт Кояшы, билгеле инде, әлеге дә баягы Ким Ир Сен. Мәктәпләрдә аның хакында бик дулкынланып сөйләргә тиешләр. Балалар Ким Ир Сен туган мәлдә... күк йөзенә ике салават күпере чыгуына һәм күктә өр-яңа йолдыз тууына инанып үсә!

Үткән тарихка әйләнеп карасаң, 1992-1993 елларда хөкүмәт халыкны көненә өч түгел, ә ике мәртәбә генә ашарга өндәгән. 1995-1999 елларда КХДРда табигать катаклизмнары, икътисади кризис сәбәпле бар уңыш юкка чыккач, ил халкы коточкыч ачлык кичергән. Бу еллардагы аяусыз ачлык аркасында 220 меңнән алып өч ярым миллионга кадәр кореялы ачтан үлгән дип санала (Ә бу ил халкының 0,05-15 проценты дигән сүз). Ачлар башта мал-туарларын, аннары чикерткәләрне, аннары агач кайрыларын ашаган. Аннары, ахыр чиккә җитеп, каннибализмны искә төшергәннәр һәм үз балаларын ашарга тотынганнар. АКШ, Япония, Корея Республикасы, Кытай, Европа берлеге, Канададан китерелгән гуманитар булышлык сонгун, ягъни «армия беренчел» сәясәте кысаларында гаскәрләр өчен генә сарыф ителгән. Шул ук вакытта, берничә елдан соң, Төньяк Кореяны өйрәнүчеләр, ил гражданнарының үзләрен кытайлардан кала иң бәхетле кешеләр дип санавын раслаган.

Төньяк Кореяга 2021 ел җәендә турист буларак сәфәр кылучылар табылган, шуларның берсе – интернетта сәяхәтнамәләре белән популярлык казанган, Ав-

биредә яшәүче һәркемгә ил лидерлары портретлары сурәтләнгән значок тагылган. Аларны һәр ике айдан соң яңаларына алыштыралар. Значокны югалтырга ярамый. Ул ялтырап торырга тиеш. Значоклар тагылганмы икәнен карап-тикшереп йөриләр. Чит ил кинофильмын карау өчен җәза – эчтәлегенә карап, йә 15 ел төрмә, яисә үлем карары. Ким үзенә багышлап 5800 һәйкәл куйган. Аларның һәммәсенә «Безнең Бөек Юлбашчы мәңге безнең белән» дигән сүзләр уелган. Һәйкәлләр яныннан узганда кореялылар туктарга һәм баш иярге тиеш.

Башлангыч мәктәпләрдә 171 сәгатьлек «Бөек Генералиссимусның балачак еллары» дигән дәрес үткәрелә, мәктәпкә китүче баласы булган ата-ана үз баласы өчен мәктәп партасы һәм урындык сатып алырга тиеш.

Әгәр илгә «кока-кола» алып керүче табылса, ул 15 ел гомерен хезмәт лагеренда үткәрәчәк. Этләрне өйдә тоту – буржуазия калдыгы. Әмма шул ук вакытта этләрне ашарга рөхсәт ителгән.

Әгәр лидерлар турындагы язмада хәреф ялгышлыгы китсә, бу ялгышны җибәрүченең язмышы бик аяныч. Мәсәлән, 2015 елда нибары бер хәреф хатасы җибәргән газета редакторын җәзалап үтергәннәр.

«Игра в кальмара» сериалы яздырылган флешка табылгач, аны Кытайда укучы алып кайтканы ачыкланган. Ул аны иптәшләренә биргән һәм тагын ике кешегә яздырып алырга рөхсәт иткән. Яшүсмерне шунда ук атып үтергәннәр. Флешкадан караган 6 кешене табып, 5 еллык каторга хезмәтенә җибәргәннәр. Ул укыган мәктәпнең директорын, профком сәркатибен, класс җитәкчесен эшләреннән куганнар. Алар бер ел буе күмер шахтасында эшләргә мәҗбүр ителгән.

Чәчен башка төскә буяучы яисә «ка-

Төньяк Корея эшчеләрен күрергә туры килде. Алар ул көнне әтисе белән әнисе берьюлы үлгәндәй елады. Шуларның берсеннән: «Нигә шулкадәр кайгырып елыйсыз?» дип сорашкач, ул: «Әгәр мин шулай кайгыга батып еламасам, үзебезгә кайткач, шушы ук иптәшләрем өстемнән донос язачак», – дип аңлатты».

Ил сайлаулар да үткәрә. Һәрбер сайлау вакытында бары тик бер генә сайлау варианты теркәлгән була. Нәтиҗәдә, барлык кореялылар да һәр 5 ел саен шул ук лидерны, Кимны гына сайлауга хокуклы. Сайлауга бармыйча калырга ярамый. Андый кеше табылса, шундук юк ителәчәк...

Былтыр бу дәүләттә тагын бер тыю кертелде. 2019 елда Төньяк Кореяда кара түгел. Мәсәлән, илдә һава саф, чөнки сәнәгатьтә алга китеш юк, урамнарда машиналар аз, уку түләүсез, медицина хезмәте түләүсез, табиб үз хезмәте өчен акча сораса, аны 25 ел төрмә көтә. Тик рәсми исеме «Иртәнге сафлык иле» дип тәрҗемә ителә торган бу дәүләт халкы өчен дә берзаман үзгәрешләр булмый калмас әле. Ләкин бу хакта халык хәтта уйда да өмет итәргә тиеш түгел. Әлегә исә, бер тарихчы сүзләре белән әйткәндә: «Кызганыч, әмма кореялылар үзләре шундый хөкүмәткә лаек». Кем белә, бәлкем, бу дәүләттәге меңнәрчә зур-зур һәйкәлләр дә урыннарыннан кубар!..

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА
әзерләде.

Давыл булып яшәгән Зөлфәт

(Дәвамы. Башы 5 нче биттә).

Җәмәгать, минем русчам бераз бар-барын, әмма болай текә сөйләшерлек түгел иде. Даһиларга болай гына тел ачкычы табышлы түгел икән. Ләкин бәхетемне үгез бөтенләй үк сөзеп атмаган икән. Кирәк бит, ә! Имтиханның беренче көннәрендә үк иң затлы, дәрәҗәле журналда чыгып килә торган шигырьләремнең корректурасы кулга килеп эләкте. Моны Мөдәррис, әлбәттә, алдан ук укып чыккан. Килеп җилкәмә шапылдатты бу. «Гениальный шигырьләрең чыккан, мә – бишне! Шушы наданнар белән имтихан чиратында торасыңмы, мин анда кереп тә тормадым. Үземә «бишле» икәнне беләм бит». Мин Аллаһ бәндәсе әле яңа гына тирләп-пешеп имтихан биреп чыкканын үз күзләрем белән күреп тордым лабаса! Ышандырырлык итеп әйтте бит. Ышандым. «Кереп тә маташма, сиңа да – «отлично» анда», – диде Мөдәррис. Әйдә, киттек. Менә шул көннән башлап Мөдәррис белән сукмакларыбыз аерылмады».

Мөдәррис Әгъләмнең җәмәгате шагыйрә Нәҗибә Сафина бу уңайдан Зөлфәтнең ирләрчә чын дуслыкның кадерен белә торган һәм аны ахыргача алып бара торган шагыйрь булуын әйтә: «Алар Мөдәррис белән дә аның соңгы көненә кадәр дус булды. Мөдәррис хәтта аңа үлем түшәгендә ятканда, без синең белән киләсе елларда 9 майларда очрашабыз, дип әйткән иде. Кызганыч ки, шулай булып чыкты. Зөлфәт тә Мөдәрриснең вафатына бер ел тулганда китеп барды. Әйтерсең лә ул Мөдәррис дустыннан башка яши алмады. Якташы, язучы Фоат Садриев әйткәнчә, Зөлфәт давыл булып яшәде һәм мәңге сүнми торган поэзия, драма әсәрләре калдырды».

Зөлфәт тә «коеп куйган шагыйрь генә түгел» иде. Ул публицистик мәкаләләре, юмор-сатира әсәрләре, курчак театры өчен пьесалар язучы да, шулай ук «Мәкерле песи» исемле беренче татар балалар операсының либреттосы авторы да, «Юлбасарлар» (Ф.Шиллер), «Йөгәнсезгә авызлык» (У.Шекспир), «Биюче» (Лопе де Вега) комедияләрен татар теленә шигъри тәрҗемә итүче дә.

Кичәдә Зөлфәт шигырьләренә язылган җырларны артистлар Рөстәм Закиров, Алинә Кәримова, Илгиз Мөхетдинов, Ризидә Галимова, Филүс Каһиров, Эльза Исламова һ.б. башкарды.

Шушы көннәрдә Казанның Татарстан урамындагы Зөлфәт (Дөлфәт Маликов) гаиләсе 1981-2000 елларда яшәгән 7 нче йорты диварына, Татарстан Президенты каршындагы мәдәниятне үстерү фондының башкарма директоры Н.Хашимова, мәдәният министры урынбасары Д.Натфуллин, Язучылар берлеге рәисе Р.Зәйдулла, Мөслим районы Башкарма комитетының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары М.Бәдретдинова, каләмдәшләре катнашында мәшһүр шагыйрь истәлегенә мемориаль такта куелды.

Сөембикә КАШАПОВА.

БЕР ТАТАР ХАТИРӘСЕ

Надежда ДУРОВА

(Ахыры. Башы 20 нче санда).

– Менә, – диде Хәмидулла. – кинәт туктап. – Менә, Якуб ага, бичарам Зөһрә шушы булыр.

Ул караңгыда шәйләнелгән печәнме, саламмы өеменә күрсәтте. Мин якынрак бардым һәм күрдем, Хәмидулла чи печән, нарат ботаклары астыннан бер хатын-кызны аралап чыгарды. Бу – аның сөеклесе Зөһрә иде. Хәмидулла җылыйҗылый сөеклесен кочаклады, ул аның аякларын җылытырга тырышып карады.

– Зөһрәм! Зөһрәкәем! Бердәнбер бәхетем! Без шушында аерылышырга тиеш.

Нишләргә белмичә, ул юеш чирәмгә тезләнде дә Зөһрәнең балтырларын кочаклады.... Кыз аның янына чүгәләде,

башын егетнең күкрәгенә салды, кочаклады, күпме җәфалар күргән егетнең апак битен үбә-үбә җылый башлады. Мин дә үкереп җылыйм. Аһ, барин! Безнең тупас кыяфәтебез астына нинди хиссият яшерелгән, беләмсез, шушы салкын якта, кеше аягы басмаган карурман салкынына нинди серләр качырылган? Рәхимсезлек, чамасыз интегүләр, җәзалар, мәхәббәт бимазаларының беренче дулкыны узып киткәч, аерылышу хәсрәте калка, кайчак шул аерылышу хәсрәте айнытып җибәрә бичараларны. Зөһрә телгә килде.

– Вакытлыча гына буйсыныйк без, җаным, язмышыбызга. Без аерылыйк, син табарсың берәр урын, без шунда яңадан кавышырбыз, мин атам янына кайтырмын, ирем янына түгел, атам янына. Теге кеше инде миңа ир түгел! Алар минем ризалыгымны сорамады. Атам калымын кире кайтарыр. Мин гомерлеккә синеке, җаным! Башка ир миңа кирәк түгел.

– Аһ, Зөһрә, Зөһрә, без бит гомерлеккә аерылышабыз! – диде бичара егет.

Аерылышу алдыннан егет кыза башлады, зур йодрыклары белән күкрәгенә кыйнарга тотынды, үзен белештермәстән, ул кычкыра иде:

– Зөһрә! Мин сине кабат күрә алмамын! Үтер мине, Якуб агай! Үтер! Зөһрәдән башка миңа ни бәхет?!

Әкренләп яктыра башлады... Мин Хәмидулланы юатырга тырышып карадым. Аңа таң атканын әйттем. Пүнәтәйләр килеп каптырганчы бер-бер карарга килергә кирәклеген аңлаттым...

– Мин әлегә чаклы аңламыйм, ни өчен мине карурманга алып килдең? Син миннән ниндидер ярдәм көтәсең? Мин синең өчен ни кылаем? Менә атаң кебек кешеңнең кулы һәм йөрәге, син аларны кирәгенчә файдалана аласың! – дидем.

Хәмидулла калыкты, янә Зөһрәсен кочаклады, сөеклесен күкрәгенә кысып ул озак торды... Ниһаять, ул җиңелчә генә Зөһрәне минем тарафка этте. Егетнең йөзе ап-ак иде. Ул чак ишетелерлек тавыш белән әйтте:

– Алып кайт син Зөһрәне үз өеңә, Якуб абый! Хәзергә син аны атасыннан яшереп, үз өеңдә тот, атасының ачуы басылганчы! –диде.

Хәмидулланың кире уйлавыннан куркып, мин яшь киленне кулыннан тотып, авылга таба йөгердем, без аның белән авылга чаклы йөгереп кайта торгач, әлсерәп беттек. Зөһрә күз яшенә тыгылып елый иде.

Өйгә кайткач, Зөһрәне хатыннарыма тапшырып, туплану көзбасына киттем: качкын Хәмидулланы тотар өчен ни кылалар икән?

Камалышны подполковник-исправник үзе оештыра икән, бөтен урманга каравыл төркемнәре урнаштырылган. Күзгә яфраклар коелгач, качкынның эзләре ачык күренәчәк, маневрлар уздыру өчен уңай вакыт, имеш. Бичара Хәмидулла һичшиксез тотылачак! – дип алгысыйлар. Өйгә кайткач, мин Зөһрәнең хәлен белештем, ул эчкәридә йоклый иде. Бичараның йөзе ап-ак, гәүдәсе арык. Йокы аралаш дерт итеп куя да ыңгыраша. Хәмидулла! Хәмидулла! – дип кычкырып куя иде.

– Барысын да сөйли башласаң, озакка китә, барин. Зөһрә күп нәрсәләр сөйләде миңа. Ничек итеп карурманда яшәгәннәре, ничек бәхетле булганнары турында, ләкин аларның иң бәхетле мизгелләре шунда, качкын булып яшәгәндә булган. Яфраклар коелып, агачлар шәрә калгач, безне тотарлар, дип кайгырганнар. Алга таба урман аларны качырып саклый алмасын белеп, бик борчылганнар. Шуннан Хәмидулла Зөһрәне миңа тапшырырга булган, уңай форсат чыкканга чаклы. Ләкин егет өлгерә алмый, исправник-полковник, земская полиция алга таба качкыннарны тотарга ныклы карар кыла, бичара Хәмидулланы кулга алалар һәм төрмәгә ябалар. Аңа суд булды... Алга таба сөйли алмыйм! Адәм каны коюда егетнең гаебе юк бит, барин! Ләкин аның исправникны үтерүче сыйфатында хөкем иттеләр. Аның төп җинаяте итеп: бәрелештә үтерелгән исправник булып чыкты. Имеш, Хәмидулла исправникны җәрәхәтләп, гәүдәсен катып үләргә каурманда калдырып качкан, дип гаепләделәр. Хәмидулланың гаебе юк, юк аның гаебе ул эштә!

Ямьче агай ике учы белән йөзен каплады, ул сулкылдый, әллә авыр итеп күрсенә идеме, башы тезләренә хәтле иелгән иде.... Аңа тынычланырга вакыт биреп, мин сорадым:

– Зөһрәгә ни булып бетте? – дидем.

– Зөһрәне атасы үз йортына кайтарды. Зөһрә атасына әйткән: әгәр дә мине яңадан теге киявеңә кайтарасы булсаң, мин үземне үзем асачакмын! – дигән.

Аның гүзәллеге, бәхетсез мәхәббәте, сабыр хәсрәте, бәхетсез күз яшьләре – барысы да кешеләрне үзенә тарта, әмма ул Хәмидулла турындагы хатирәләреннән башка бөтенесе өчен дә үле иде. Көнен-төнен җылый иде, пәрдә артында утырып ул гел моңлана иде һәм сез бая ишеткән җырны ул чыгарды. Җырында ул үзен бәхетле итеп күрә, каурман уртасында яшәгән чакларын сагына, тиздән гомерлеккә аерылышасын сизенеп җырлый ул, эзәрлекләүчеләр тавышын ишеткән саен куңелендә курку ярала... бу – мәңгегә аерылышу җыры... Хәзер бөтен авыл шушы җырны җырлый.

– Җырның кушымтасы: «Һәйдә, һәйдә, Хәмидулла!» Ул нәрсәне аңлата?

– Һәйдә, һәйдә, ашык, Хәмидулла, һәйдә, тиз бул, ашык, Хәмидулла!

Якуб ямьче тынып калды.

Карурман уртасындагы атау, синең куелыгында киек-җәнлекләрнең өне, шушы өннәр янында сөйләп бетергесез якты мәхәббәт уты яна! Хәмидулла инде күптән юк. Әмма шул атауда аның исеме яңгырый: Хәмидулла, Хәмидулла! Бу атауда алар бәхетле иде! Күпме тапкыр кабатлый карурман аның исемен, ничә тапкыр кайтаваз булып яңгырады урманда аның исеме, пышылдап та, дәһшәт белән дә яңгырады Хәмидулла исеме, ә Зөһрәсе, ятим калган Зөһрәсе аны җырга салды!..

– Һәйдә, һәйдә, ашык, Хәмидулла!

Рабит БАТУЛЛА
тәрҗемәсе.

Уникенче җәлилче

Герой-шагыйрь Рәхим Саттарның исеме киң таралмаган, яшьләр арасында аны белүчеләр сирәк. Аны «уникенче җәлилче» дип атыйлар. Быел тууына 110 ел тула.



Рәхим Саттар (Габделрәхим Сөләйман улы Габделсаттаров) 1912 елның 15 августында Башкортстан Республикасының Чишмә районындагы Түбән Хаҗәт авылында туа. Югары белем алган, кече командирлар курсларын узган. 1937 елда гаиләсе белән Казанга күчеп килә.

1939-1941 елларда ул «Яшь сталинчы» газетасында хәрби бүлек мөдире булып эшли. 1941 елның җәендә үз теләге белән фронтка китә, десантчы була. 1942 елның маенда чолганышта калып, фашистлар кулына эләгә һәм, берничә ай Смоленск, Борисов тирәсендәге хәрби әсирләр лагерендә газап чиккәннән соң, Берлин янындагы Вустрау лагерена озатыла.

Шунда ул Абдулла Алиш белән очраша һәм озакламый Муса Җәлил һәм аның иптәшләре тарафыннан оештырылган яшерен антифашистик оешмада ышанычлы вәкилләренең берсенә әйләнә. Ул «Идел-Урал» легионында гитлерчыларга каршы листовкалар язуда һәм аларны бастырып таратуда актив катнаша. 1943 елда Р.Саттар җитәкләгән төркем алдына бурыч куела: фронт линиясен үтеп, үзебезнекеләр ягына чыгарга, «Идел-Урал» легионында яшерен оешма төзелү һәм легионерларның кораллы восстаниегә әзерләнүе турында совет командованиесенә хәбәр итәргә. Р.Саттар җитәкләгән биш кешелек төркем Едлино лагереннан кача... Р.Саттарның шуннан соңгы язмышы билгесез.

Рәхим Саттарның ничек вафат булуы турында фаразлар гына яши. Әмма «менә бу версия дөрес» дип раслаучылар да бар. Р.Саттар җитәкләгән төркемгә урманчы поляк качарга ярдәм иткән. Урман эчендәге сукмаклар аша поляк аларны Варшавага кадәр озаткан. Соңыннан ул полякны дошманнар кулга алган һәм җәзалап үтергән. Качкан легионерларның язмышы ут эчендә өзелгән. Алар засадага эләгә һәм печән кибәне астында яшеренеп торган вакытта фашистлар ут ача. Бер төркем кешене тереләй яндырып үтерәләр…

Р.Саттарның ике баласы кала. Улы Ил аны фронтка озата. Улы кечкенә вакытта ук Р.Саттар хатыны белән аерылган була. Кызы Алсу хатыны Нажия белән калган.

Ил Саттаров - республикабызда Милли социаль-икътисад институтын оештыручыларның берсе. Гомере буе әлеге югары уку йортының ректоры булып эшләгән. Герой әтисенең якты исемен, иҗатын, батырлыгын яшь буынга җиткерү өчен ул күп тырышкан. Р.Саттар баласына багышлап бер генә хат язарга өлгерә. Хатны алганда улына тугыз яшь кенә булган. Ил абый әтисе белән гомер буе шул хат аша «аралашкан».

Ил абый әтисенең әсирлектә вакытта язылган шигырьләрен бастырып чыгарган. Р.Саттар Борисов, Вустрау, Радом һәм Берлиндагы хәрби әсирләр лагерьларында иҗат иткән шигырьләренең егерме дүрте 1964 елда туган иленә кайта. Җыентык турыдан-туры туганнарына түгел, ә Язучылар берлегенә тапшырыла. Р.Саттар лагерьдан качар алдыннан ул җыентыкны А.Алишка биреп калдырган була.

Р.Саттарның әдәбиятка тартылуы мәктәп елларында ук башлана. Күренекле татар язучысы Нәкый Исәнбәт аның татар теле укытучысы булган.

Бүген Р.Саттар, аның иҗаты турында сүз әйтә алырлык белгечләребез дә күп түгел, иҗатын өйрәнүчеләр бик аз.

В.И. Ленин музеенда герой-шагыйрьнең 110 еллыгына багышланган кичә узган иде. Анда Р.Саттарның оныгы – ТР Милли музеенның тупланмалар буенча генераль директоры урынбасары Лилия Саттарова килгән иде. Калган кунаклары күбесе лаеклы ялга чыккан, өлкән яшьтәге апалар. Тамашачылар арасында гел рус сөйләме ишетелде.

Лилия ханым үз әтисе – Ил абыйның тырышлыгын күп тапкырлар ассызыклады. Р.Саттарның нәсел дәвамчылары фикеренчә, М.Җәлил һәйкәле янындагы барельефка куелган геройлар арасында уникенчесе дә булырга тиеш.

– Әти безгә бабайның геройлыгы турында сөйли иде, – дип әкрен генә сүзен башлады Лилия апа. – Кечкенәдән бабайның батырлыгы турында белә идек. Ул бит профессиональ десантчы, Рәхим бабайның әсирлеккә эләгүе дә алдан уйланылган операция булган. Бабай немец телен дә белгән, югары белем алган. Рәхим бабай Җәлил, Алиш белән Матбугат йортында редакциядә эшләгәндә үк таныш булганнар. Нәби Дәүли бабамны якыннан белгән, алар фин сугышында бергә катнашкан.

Без пионер, комсомол чорын үттек. Ниндидер чараларда, политинформация сәгатьләрендә бер тапкыр да бабам герой дип чыгышлар ясаганым булмады. Әти аның исемен торгызу өчен тырышты, ә безне ул эшкә җәлеп итмәде. Әтинең язмаларында әтисенә карата булган бөтен хисләре ярылып ята. Безгә сөйләгәндә дә күңеле тула иде. Әти һәрвакыт аның турында язган, чыгышлар ясаган. Аларның үз илләрен сатмавын исбатлап торган, чөнки ул вакытта пленда булган кешеләргә тәрлечә мөнәсәбәт яшәгән бит. Әти аның белән горурлана иде, әмма бер тапкыр да мин герой улы дип кычкырып йөрмәде. Пленда булган кешенең малае буларак, әти берничә ел буе югары уку йортына да керә алмаган.

1999 елда безнең гаиләдә булган барлык материал нөсхәләрен Милли музейга тапшырдык. Шулай итү дөрес дип саныйм, чөнки гаиләдә алар сакланмаска да мөмкин.

Рәхим бабай белән бүген дә горурланам. Аның исеме гаиләдән тыш, җәмгыятьтә саклануы мөһим. Нигә 11 барельеф янында уникенчесе – Рәхим Саттар портреты юк?! – дип янып сөйләде ул.

Р.Саттар эшләгән «Яшь сталинчы» газетасы редакциясе Матбугат йортында булган, ләкин бина диварында истәлек тактасы юк. Дөрес, Казанның Тынычлык бистәсендә – Р.Саттар, башка төбәкләрдә кайбер җәлилчеләрнең исемнәрен йөрткән урамнар бар. Тынычлык бистәсендәге 129 нчы рус-татар мәктәбендә Р.Саттарга багышланган почмак та ясалган.

Р.Саттарның туган авылында һәм район үзәге Чишмәдә да аның исемен йөрткән урамнар бар. Чишмә районы музее директоры Радик Әхмәдиев герой-шагыйрьгә багышланган бик күп чаралар булуын, авыл халкының аның белән горурланып яшәвен ассызыклый.

– Авыл, район халкы өчен ул – герой. Балалар аның иҗатын мәктәптә өйрәнә, шигырьләрен укый иде, ни кызганыч, туган авылында мәктәп юк инде, оптимизация булды бит, балаларны башка мәктәпкә автобуслар йөртә, – дип сызлана да.

Р.Саттар яшәгән нигезнең кайда булуын төгәл генә белүче дә юк.

Кинорежиссер Нәсүр Юрышбаев җәлилчеләр турында нәфис фильм өчен сценарий язган иде. Ул ун еллап сценарий өчен материаллар туплаган. Фильм әле төшерелмәгән. Сценарийга Р.Саттар да кертелгән. Кинорежиссер ул күренешне ничек тасвирлавын сөйләде.

– Яшерен оешма төзүдә Р.Саттарның роле искиткеч зур. Фронт сызыгын узу өчен әзер булмаган кешене җибәрмәгәннәр бит. Р.Саттар анда җитәкче дә булган әле. Фронт сызыгын узу өчен дә, тоткынлыкта яшерен оешма төзү өчен дә кушйөрәкле, сынмас җанлы батыр булу кирәк.

Фильмда Җәлилче-Кормашчылар турында моңа кадәр билгеле булмаган фактлар да бар. Мәсәлән, Михаил Черепанов (Бөек Ватан сугышы музей-мемориалының элеккеге мөдире) әйтүенчә, Кормашчыларның эшләрен Мәскәү белеп торган. Чөнки М.Җәлил үзе һәм яшерен оешма вәкилләре Берлинда безнең чын разведчиклар белән очрашкан, – дип сөйләде режиссер.

Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре, нәфис сүз остасы Әлфия Хәбибуллина Җиңүнең 75 еллыгына сугыш кырында ятып калган шагыйрьләр турында «Үлемсезлек җыры өзелмәс» дигән проект эшләгән иде. Ул исемлектә Рәхим Саттар да бар.

– Проектта 23 шагыйрьне яктырттым, хәзер аларның исемнәре телгә алынмый диярлек. Ул исемнәр югалырга тиеш түгел, алар бер кулына мылтык, бер кулына каләм тотып сугышкан. Күп шагыйрьләр фронтта язганнарын «Совет әдәбияты» (хәзерге «Казан утлары») журналына җибәреп торган. Р.Саттарның да берничә шигыре шунда басылып чыга. Көчемнән килсә, бер паркта сугышта үлгән 35 язучының аллеясын булдырыр идем. Анда һәрберсенең үз агачы калкып чыкса, һәрберсе турында мәгълүмат урнаштырылса, алар яшь буынның хәтерендә кала.

Гөлүзә ИБРАҺИМОВА,
intertat.tatar.



Мәдәни җомга
3 июнь
№21, 2022

●Оныгы белән М.Гәрәев, Илеш райкомы секретаре Т.Рахманов һәм район Башкарма комитеты рәисе Х.Халиков Яркәй Сабан туенда. 1982 ел.

●Муса этисе Гайсә, уллары Валерий һәм Евгений белән. Мәскәү, 1958 ел.

МУСАЛАР – ТАТАР,

(Дәвамы. Башы 20нче санда).

1940 елда аны Кызыл Армиягә хезмәткә чакыралар, ул Энгельс каласындагы авиамәктәптә укый башлый. 1942 елның июнендә аны тәмамлагач, сержант дәрәҗәсендә 944 нче авиаполкка штурман итеп билгеләнә. Бу вакытта инде Башкортстаннан 700 меңгә якын ир-егет фронтка озатыла, аларның 300 меңнән артыгы яу кырында ятып кала.

Мусага әүвәл Сталинградны саклап калу өчен яуга керергә туры килә. Аннары Ростов, Миусс, Донбасс, Мелитополь, Никополь-Кривой Рог, Кырым, Витебск, Орша, Минск, Вильнюс, Мемель, Көнчыгыш Пруссия, Кенигсберг, Землянскны азат итү өчен сугышчан операцияләрдә катнаша. Донбасс, Кырым, Пруссияне азат иткәндә һава флотында инде легендар очучыга әверелгән Кырым татары Әмәтхан Солтан белән бергә яуларда да була.

●М.Гәрәевнең Югары Яркәй авылындагы музей күренеше.

Сугыш – үлем, кан һәм шөбһә тулы көннәр дигән сүз ул. Мусаның әле бөтенләй тәҗрибәсез чагы бит, 1942 елның 1 августында ук көч-хәл белән генә үлемнән котылып кала. Шул беренче яуда ук аңа күктә дошманның өч истребителе белән алышка керергә туры килә. Тик фашист очучылары азау тешен чыгарып өлгергән, Муса утырган Ил-2 очкычының двигателен теткәләп бетерәләр. Самолетны ялкын чорнап ала, тик шулай да Муса фронт сызыгыннан соң да 800 метр үтеп, очкычны аэродромга утыртуга ирешә. Аннан соң инде ул соңыннан

●Иләкшиде үзәгендә М.Гәрәев һәм Бөек Ватан сугышында һәлак булган авылдашлары хөрмәтенә куелган истәлек ташлары.

Дан орденнарының тулы кавалерына әвереләчәк Александр Кирьянов атлы укчы-радист белән бер экипаж булып оча башлый. Бер-берсенең иңен һавада да тоеп сугышу ышаныч һәм тәҗрибә өстәгәндер. Муса тиздән звено, ике елдан соң эскадрилья башлыгы итеп үстерелә. Дошман өстенә звенолар булып та, кайчакларда хәтта йөз самолетлы армада булып та очалар. Үзенең штурмовигыннан бомба һәм ут яудырып, Муса Гәрәев экипажы кайбер яуларда берьюлы өчәр фашист танкын, кайчакларда дистәләгән туп һәм дошман солдатларын тетеп сала. Батыр очучы күкрәген Кызыл Йолдыз, Ватан сугышы, Сугышчан Кызыл байрак орденнары бизи башлый. Инде сугышчан очышлар саны 160 тан арткач, 1944 елның көзендә Муса Гәрәевне Советлар Союзы Герое исеменә тәкъдим итеп документлар юллыйлар. Ләкин алар кайсыдыр сейфка бикләнә, хәбәр хаты да килми. Тик фронт тын алып, чәч көдрәләтеп ята торган имин вакыт түгел, 1945 елда сугышлар Балтыйк буе һәм Көнчыгыш Пруссия өстенә җәелә. Бу вакытка инде очыштан соң һәрбер рапортыңның дөреслеген тикшерү өчен штурмовиклар фюзеляжы астына фотоаппаратлар да куеп өлгерәләр, контроль нык көчәя. Ә Кенигсберг каласын да, Көнчыгыш Пруссияне дә фашистлардан чистартырга кирәк. Сугышчан очышлар гына түгел, фашистлар ягыннан корбаннар саны да арта тора. Нәкъ менә шул 1945 елның 23 февралендә – Кызыл Армия көнендә Муса Гәрәевкә Каһарман исемен бирү турында фәрманга да кул куйганнар икән. Хәбәре килеп җитә, әмма Ленин орденын һәм Алтын медаль эзләп йөрердәй вакыт түгел. Көн дә яуга, яуга...

Сугышчан очышлар саны 200 дән, ә фашист гаскәрләренә китерелгән зыян һаман арта баргач, командование Муса Гәрәевне инде икенче мәртәбә

●Уфаның Җиңү паркына куелган М.Гәрәев бюсты. Н.Томский эше.

●Уфада М.Гәрәев яшәгән йортка куелган барельеф.

● М.Гәрәевнең Таш-Чишмә авылындагы музей-йорты.

● Яркәй авылындагы музейда яңарту бара.

МУСАЛАР БАТЫР БУЛА

● Иләкшиде урамы.

● Олы Бишкурай авылы мәчете.

Советлар Союзы Каһарманы исеменә тәкъдим итә. Бу юлы Указ озак көттерми, 19 апрельдә Муса колагына да килеп җитә. Ләкин ни әйтсәң дә, һаман бер бәла бит – сугышны Берлин өстендә, фашист Германиясен тулысынча җиңеп тәмамларга кирәк! Менә шулай ял да күрмичә орышканга күрә, армия башлыгы, генерал-полковник Т.Хрюкин Муса Гәрәевкә дәүләт бүләкләрен 1 май иртәсендә Кенигсберг аэродромының бетон мәйданында тапшыра.

– Син Советлар Союзы Герое дигән бөек исемнең берьюлы ике медален аласың. Мондый тантана гомердә бер була, оныта күрмә, майор!

Чыннан да, Кызыл Армия тарихында ике Каһарман медален берьюлы алган бердәнбер очрак бу!..

Бөек Җиңүдән соң Мусаны штурмовикларның 76 нчы гвардия полкына баш штурман итеп озаталар һәм ул Белоруссиянең Лида каласында хезмәт итә башлый. Ул 1943 елда ук полкларына парашют җыючы итеп билгеләнгән Галина Мигунова атлы кыз белән гаилә корган була. Инде балалар үстерергә, тыныч тормышка җайлашырга да вакыт. Тик сәламәтлек бер дә сөендерми, Мусага транспорт авиациясенә күчәргә туры килә. Шуннан Мусаны Генераль штаб каршында оештырылган Хәрби академиягә укырга озаталар. Академиядән соң, 1951 елда Мәскәүдә үк урнашкан 2 нче һава дивизиясенең командир урынбасары булып билгеләнә. 1960-1964 елларда Мәскәү янындагы Щелково каласында урнашкан 10 нчы һава бригадасы командирының урынбасары булып хезмәт итә. Ләкин сырхау-чирләр бер дә тынгы бирми, 1964 елның май аенда отставкага чыга.

Бу вакытка Мусаның Валерий һәм Евгений исемле малайлары да үсеп җитә инде. Мусаны туган ягында да искә төшереп, Уфа каласына күчәргә чакыралар. Ул 1965 елдан 1977 елның гыйнварына кадәр республиканың ДОСААФ оешмасын җитәкли. 1946-1958 елларда СССР Югары Советы депутаты булса, 1967-1980 елларда Башкортстан Советында халык ышанычын яклый.

Ни кызганыч, Муса Гәрәев 1987 елда, 65 яшендә вафат була. Аны Уфа каласының үзе васыятьләгән Җиңү паркында җирлиләр. Кабере янына бюсты, ул яшәгән йорт диварына барельеф куелган. Гәрәевнең Н.Томский атлы сынчы ясаган бюсты Третьяков галереясында саклана. Район үзәге Югары Яркәйдә ике катлы музее, аның каршында бронзадан коелган бюсты бар. Бәхетсезгә җил каршы, дигән төсле, мин фәкыйрегез барганда музей ихатасында яңарту эшләре кузгалган иде. Муса Гәрәев очкан Ил-2 самолетының бер макетын алып, аны музей ихатасына кую турында Оборона министрлыгы белән сөйләшүләр бара, тик кесә җылытырга өйрәнгән погон ияләре үтә зур хак куеп тинтерәтә икән...

Туган авылы Иләкшиде үзәгендә сугыш ветераннарына багышланган матур сквер бар, һәлак булганнар һәм исән әйләнеп кайтканнар исемлеге язылган ташлар уртасында, әлбәттә, Муса аганың аерым ташы бар. 100 еллыгы якынаю хөрмәтеннән авылдашлары Гайсә агайның иске ихатасы урынына 100 агач үсентесе утыртырга да өлгергән. Элек коммуна җәннәте булган Таш-Чишмәнең 17 йортлы бердәнбер урамы да, күл һәм чишмә буйлары да бик күркәм. Шундагы музей да күпләр көнләшерлек. Кызганыч ягы шул: район үзәгеннән Таш-Чишмәгә яки Иләкшидегә алып килә торган юллары гына җимерелгән, ватык, сызланмалы. Уфада яки Мәскәүдә бордюр белән брусчаткаларны да ел саен яңарталар. Җиһанга ике тапкыр Советлар Союзы Каһарманы үстереп биргән татар авылларына ярамаган тагын, дияләрме әллә?..

Вахит ИМАМОВ.
Автор фотолары.

Ул бик күп күренекле затларны биргән Байлар Сабасында дөньяга килә. Әтисе райком секретаре, райбашкарма комитеты рәисе һәм кайбер башка җаваплы җитәкче вазифаларда эшли (Ни кызганыч, чагыштырмача иртә – 59 яшендә вафат та була). Шуңа нисбәттән Сверигиннар гаиләсенә күчкәләп йөрергә туры килә. Рифат алтынчы сыйныфка кадәр элеккеге Кызыл Юл районы үзәгендәге Яңа Кенәр урта мәктәбендә белем ала. Аннан укуын Сабада дәвам иттерә. Аны тәгәлләгәч, 1950-1955 елларда ул – Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеге студенты. Диплом алгач, Аксубай районындагы Яңа Ибрай мәктәбендә мөгаллим булып эшли. Кукмаралылар да аны еш кына «үзебезнең Рифат» дип йөртә. Моның өчен ныклы нигез дә бар. Чөнки ул берничә ел шул районның Оштырма-Юмья авылындагы удмурт мәктәбендә укытучы, Ядегәрдә мәктәп директоры булып эшли. 1961-1964 елларда СССР Фәннәр академиясенең Казан филиалы Тел, әдәбият һәм тарих институты аспиранты (җитәкчесе – күренекле галим Гали ага Халит). Алга таба – шушы гыйльми оешмада фәнни хезмәткәр. 1971 елның июлендә Фатих Хөсни иҗатын тикшерүгә багышланган хезмәтен диссертация итеп яклый һәм филология фәннәре кандидаты дигән гыйльми дәрәҗәгә ия була. 1972 елдан алып 40 елга якын Казан педагогика институтының татар әдәбияты кафедрасында өлкән укытучы, доцент, профессор вазифаларын башкара, меңәрләгән мөгаллим, журналист, иҗат һәм фән әһелләрен тәрбияләүгә үзеннән өлеш кертә.

Рифат әфәнде Сверигинның татар һәм рус телләрендә дистәләгән монографияҗыентыклары, дәреслек-хрестоматияләре бар. Аның Ф.Хөсни, Ә.Еники, А.Гыйләҗев, Г.Бәширов, А.Расих һ.б. әдипләрнең иҗатларын стиль, психологизм, әдәби осталык күзлегеннән карап яктырткан мәкалә-хезмәтләре әдәбият сөючеләргә, мөгаллимнәргә яхшы таныш.

Рифат Хәсән углы тәнкыйтьче буларак җанлы әдәби процесста да актив эшләп килә. Аның төпле чыгышлары әдәби ел йомгакларында, төрле семинар-конференцияләрдә яңгырап тора. Рифат әфәнде турында кызыклы гына язмалар да бар. Аеруча аны дистә ел элек арабыздан китеп барган якташы, юмор остасы Тәлгать Нәҗмиев хөрмәт итә иде. Аның берничә мәкаләсе дә бар. Якташы, хезмәттәше Азат Әхмәдуллин да яшьтәшенә бик тә җылы мөнәсәбәттә торды.

Аның күптән түгел генә кулыбызга кергән бер китабы турында уртаклашмый булмый. Китапның исеме дә мәгънәле, оригиналь: «Һәр кошның үз кунычасы. Ирониялe автобиографик элегия» дип атала (Казан, 2021. -192 б.). Аны автор 89-90 яшьләр аралыгында язган. Басмада шактый гына фоторәсемнәр дә урнаштырылган.

Гаять катлаулы, каршылыклы чорларда бер гасырга якын яшәгән Рифат Хәсән углына да күпне күрергә, күпне кичерергә туры килгән. Аларның барысын да искә төшерү, укучыларга җиткерү мөмкин түгел. Шулай да уртача калынлыктагы бу китабында авторның гомер юлы, шәхесе, гаиләсе, эш-гамәлләре, күңел дөньясы шактый тулы күзаллана. Анда без галимнең балачак һәм үсмер елларын да, студентлык һәм мөгаллимлек чорын да, фән дөньясында эшләү дәверен дә, гаилә тормышында, кайгылы-фаҗигале хәлләрен дә күрәбез. Тәрҗемәи хәлнең төп герое-каһарманы чынбарлык, иҗтимагый-рухи тормыш белән тыгыз мөнәсәбәттә сурәтләнә. Без, гадәттә, түрә-«начальник» балалары матди муллыкта гына яшәгән дип уйлауга күнеккәнбез. Әмма алай түгел. Аеруча совет чорында Рифат Сверигиннар гаиләсе дә шактый гына кыенлыклар кичергән. Китап авторы эти-әнисе, туганнары, якыннары, чордашлары, каләмдәшләре хакында күп мәгълүматлар бирә, гыйбрәтле мисаллар, вакыйга-хәлләр дә китерә. Күпләр Рифат Хәсән углының юморны яратуын искәртә. Бу аның китабында да сиздерә. Автор үзенең тәрҗемәи хәлен, эш-гамәлләрен еш кына юмор, тәнкыйди яссылыктарак бәян итә. Мондый алым әсәрнең үтемлелеген, тәэсир көчен арттыра. Әмма авторның «ирониясе», тәнкыйди-юмористик алымы кешеләрне һич тә рәнҗетми, түбәнсетми, киресенчә, аларны тулырак, үтемлерәк аңларга ярдәм итә.

Рифат Хәсән углын күп кенә якыннары, аеруча студентлары, хезмәттәшләре спортчы буларак та белә. Китапта аның йөгерү-кросслары, футбол-волейболда, шахматта уйнаулары тулы һәм кызыклы язылган.

Мәгълүм ки, авторның татарга хас булмаган фамилиясе күпләрдә сорау тудыра. Шуңа карап аны кайвакыт урыска нисбәт итү очраклары да бар. Бу хакта тәрҗемәи хәлдә дә берничә мәртәбә телгә алына. Китапның «Ни өчен Сверигин?» дигән бүлекчәсендә бу фамилиянең тарихы да аңлатыла. Баксаң, «Сверигин» бернинди нәселнәсәп белән дә бәйләнмәгән икән. Ул гражданнар сугышы елларында Хәсәнгата Мөхәммәтсафа углына «север» сүзе белән бәйләнештә бирелгән очраклы, ясалма атама гына. Безнең татар шулай инде ул: кайвакыт үзенең өммәтенә хас булмаган исем-атамаларны алырга, аларны үзенең балаларына, оныкларына да бирергә ярата. Бираде, әлбәттә, чор атмосферасы, совет дәвере «кызыллыгы» да билгеле бер роль уйнагандыр. Бу хакта автор үзе дә искәрткәләп тора, хәтта үзен «алданган буын вәкиле» дип тә атый. Гомумән, әсәрдә кызыклы, гыйбрәтле хәл-вакыйгалар, эпизодлар белән бергә, чор, тереклек, яшәү мәгънәсе хакында уйлану-кичерешләр дә бар.Төп каһарман билгеле бер үсеш-үзгәрештә, эчке эволюциядә бирелә. Әсәр ахырына таба ул, яшенә, тормыш юлына бәрабәр рәвештә, философка – фикер иясенә дә әйләнеп китә.

«Һәр кошның үз кунычасы» китабы бер гасырга якын яшәгән, бай тормыш тәҗрибәсе туплаган кешенең хәзерге укучыларга үзенә күрә бер сабагы, васыяте рәвешендә дә кабул ителә. Ул аеруча безнең буын, өлкән кешеләр һәм каләм әһелләре өчен кызыклы. Андагы күп кенә хәлләр совет чорында һәм аннан соңгы елларда яшәгән, эшләгән кешеләрнең башыннан кичкән. Яшәеш сукмакларыбызның кушылып киткән очраклары да бар.

Тәрҗемәи хәл, истәлек-хатирә жанрындагы әсәрләр бездә элек-электән кызыксынып, яратып укыла. Каләмдәшебез Рифат әфәнде Сверигинның да бу китабы автобиографик типтагы әдәбиятка бер өлеш кертә. Аның укучылар тарафыннан кызыксынып кабул ителәчәгенә ышанам. Бу китап авторның үз туган көненә – 90 яшьлегенә кыйммәтле бер бүләк тә.

Хатыйп МИҢНЕГУЛОВ.

Үзем дә шактый өлкән кеше: Ходайга шөкер, 84 яшьне тутырдым. Әмма, сөенеч ки, миннән өлкәнрәк кайбер каләмдәшләрем дә исән-сау. Без күпләребезнең остазы булган, 94 яшен тутырып килүче Мирфатыйх ага Зәкиевнең арабызда булуына шатбыз. Бераз сәеррәк фамилияле Рифат Хәсән углы Сверигин атлы мөхтәрәм, тыйнак затка да тиздән 90 яшь тулачак. Аның озын гомер юлы шактый борылмалы.

Галимнең гомер сукмаклары

Беренче рәттә: Ф.Хатипов, М.Җәләлиева, С.Хәким, И.Юзеев, (...), М.Сәгыйтов. Икенче рәттә (сулдан өченче): Р.Сверигин. II курсның 208 нче төркеме кызлары белән. 1977 ел.

Тальянга җан өрүче

Шәһәр үзәгендә урнашкан иркен остаханә. Ул түгәрәк шәкелдә пыяладан ясалган, кояш нурлары белән туп-тулы! Монда останың эш җайланмалары тора, киштәләрдә – үзенә тылсымлы бармаклар кагылып, яңадан җан өргәнне көткән иске гармуннар, алар янәшәсендә – ялт-йолт килеп нур чәчеп утырган өр-яңа тальяннар… Мәнә даланың ихласлыгын һәм морза бабаларының затлылыгын да бердәй үзенә җыйган нурлы йөзле Оста, кулына бәләкәй чүкечен алып, яңа гармунга дигән җиз телләрне чүки башлый. Чең-чең, чең-чең… Аннары бер кыңгыраулы тальянны ала да, яңгыратып уйнап җибәрә. Шәһәр үзәгенә күңелләрне җилкендереп татар моңы түгелә. Казан кунаклары, туристлар һәм Останың могҗизалы шөгылен карарга, гармун тавышын тыңларга килгән кешеләр кызыксынып, гаҗәпләнеп, ләззәтләнеп тамаша кыла...

Тик бу җанга ятарлык күренеш хыялда гына шул. Җырлап торган тальян гармуннар ясаучы оста гына чын. Без шәһәребезнең сәнгать зонасындагы складлар арасында урнашкан салкын остаханәсендә әңгәмә корып утырабыз. Киштәләрдә – төзәтелүне яисә хуҗалары килеп алганны көтеп яткан иске һәм өр-яңа гармуннар тезелешеп тора. Өстәлләрдә – музыка коралының төрле өлешләренә әвереләсе фанера, күн, катыргы, җиз һәм тагын әллә ниләр. Агач исе, җилем исе, күн исе кушылмасы остаханәне тутырган. Без бүген җиз телле тальян ясаучы берәмтекле осталарның берсе – Айрат Харисовта кунакта. Аның сәнгать әсәре иҗат итү кебек үк, илһамлы да, мәшәкатьле дә бу шөгыльгә илткән юлларын барлыйбыз.

Әтисе оста гармунчы булса да, Айрат балачакта музыка белән әллә ни кызыксынмый. Ул күбрәк рәсем ясарга ярата, чын рәссам булырга хыяллана. Шуңа күрә мәктәпне тәмамлаганнан соң, Уфа педагогика институтының сәнгати-графика факультетына барып керә. Соңгы курска җиткәч, рәсем сәнгате буенча диплом эше сайлар вакыт җитә. Әтисенә хөрмәт йөзеннән, ул киндердә гармунлы бабай образын ясамакчы була. Тәвәккәлләп эшкә дә тотына, тик үзе дә көтмәгәндә ниятен үзгәртә: һөнәрчелек сәнгате бүлеге җитәкчелегендә ул тальянның үзен ясап карарга була! Әйтергә генә җайлы, әгомердә бер шөгыльләнмәгән эш бит ул! Тик максат куйгансың икән, аңа инде ирешергә кирәк. Айрат та шулай уйлый һәм Уфаның танылган гармун ясаучы остасы Җидеяр Мухаяровны эзләп таба. Оста аңа үз янына килеп йөрергә рөхсәт итә. Шулай итеп, Җидеяр оста кул астында егет башта әтисенең чормада яткан иске гармунын реставрацияли, аннары үзенең беренче тальянын эшләп чыга. Әлбәттә, останың ярдәменнән башка булмый. Эшнең нәтиҗәсе дә сөенderә: дипломны әйбәт итеп яклый. Ә беренче тальянның язмышы да кызык кына була. Башта аны диплом эше буларак, кафедрада калдыруны сорыйлар. Тик егетнең күз нурлары түгеп, җан җылысы салып ясаган тәүге гармуныннан һич тә аерыласы килми – ул аны үзе белән алып китә. Шуңа күрә озак кына дипломын да бирмичә йөртәләр әле. Ләкин соңрак, илдә дефолт белән бәйле авыр бер чорда кызыл агач белән затлы итеп ясалган ул гармунны бер Чистай кешесенә сатып җибәрергә туры килә.

Дипломлы белгечне Дүртөйле районының Исмәгыйль авылына музыка мәктәбенә эшкә җибәрәләр. Мәктәптә моңарчы рәсем сәнгате бүлеге булмый, шуңа күрә дә Айрат үзе балалардан түгәрәк җыя. Музыка мәктәбенең баян, гармуннарын көйләү, ремонтлау эше дә аңа йөкләнә. Осталыгы шул рәвешчә чарлана бара.

Соңрак язмыш юллары аны кабат Җидеяр остазы белән очраштыра һәм Айрат моның очраклылык түгел, ә үзенә тиң иҗат юлы икәнен чамалый. Бу вакытта Җидеяр ага инде Чаллы шәһәрендә эшли. Аны Уфадан Чаллының ул чактагы хакиме Р.Алтынбаев чакыртып кайтара, өч бүлмәле фатир, остаханә бирә. Айратның ике елы музыка мәктәбе белән Чаллы арасында йөреп уза. Аның төп максаты – тальянның җиз телләрен үзе ясарга өйрәнү ләбаса. Чын оста җиз телләрне нәкъ менә үзе ясый белергә тиеш, ә музыка кораллары фабрикалары чыгарган әзер телләрне генә куярга түгел. Җидеяр ага исә алтын куллы оста гына түгел, ә виртуоз гармунчы да. Ул югары музыкаль белемгә һәм абсолют ишетү сәләтенә ия. Җидеяр оста ясаган гармун дигән сүз иң югары сыйфат билгесен аңлата. Аның белән аралашып үткән кыйммәтле ике ел эчендә Айрат тальяннарны реставрацияләү, ясау, көйләү буенча осталыгын чарлап кына калмый, ниһаять, бу искиткеч уен коралында үзе дә уйнарга өйрәнә.

2004 елдан ул музыка мәктәбен җитәкли. Өстәмә инструмент рәвешендә, тальян дәресләрен кертәләр. Балалар белән тальянчылар ансамблен төзеп, төрле бәйгеләрдә катнашалар. Оста кечкенә малайларның кулларына яраклы итеп нәни тальяннар ясый, тиңсез ансамбльне Уфага, Мәскәүгә, Казанга да чыгыш ясарга чакыралар. 7 ел музыка мәктәбен җитәкләгәч, танышлары чакыруы белән Айрат әфәнде Казанга кайтырга тәвәккәлли. Шәһәребез җитәкчеләре татар мәдәнияте өчен никадәр файда китерә алачагын чамалап, социаль ипотека юлы белән фатир мәсьәләсен хәл итәргә булыша. Башта оста өендә эшли. Тик гармун ясау – мәшәкатьле эш, телләрен чүкегәндә тавыш та чыга. Җан биргәнгә җүн бирер дигәннәр бит, Айрат янына бер халык иҗатчылары күргәзмәсе вакытында илбашы Рөстәм Нургали улы үзе туктала. Тальяннарны кызыксынып карый, хәлләрен, проблемаларын сорый. Шулай итеп, остаханә кирәклеген әйтергә җай чыга. Президент кушуы буенча, ике республикага бердәнбер булган остага эшләр өчен, шушы остаханәне бүлеп бирәләр. Безгә салкын һәм шыксыз урында урнашкан булып тоелса да, Айрат үзе аңа шөкер итеп туймый. Мәдәният министрлыгы да игътибарсыз калдырмый: республиканың 100 еллыгы алдыннан авыл клублары өчен 100 тальянга заказ бирә. Әлбәттә, мондый зур заказга җиз телле тальяннар ясап утырып булмый, «фабричный» әзер телләр куеп эшләнә. Тик санкцияләр җиле үз остаханәсендә тыныч кына гармун ясап утырган Айрат оста Харисовка да кагылган: Чехиядәге йөз еллык тарихлы музыка кораллары фабрикасы белән элемтәләре өзелгән. Тула белән Шуяның гармун ясаучы фабрикалары да әзер телләрне шуннан сатып алган.

Тальяннарга заказлар килеп тора, оста эшсез тормый. Тик ул бу һөнәрнең гомумән югала баруына, үткәндә генә кала баруына борчыла. Яшьләр бу шөгыльгә әллә ни кызыксыну күрсәтми шул. Аннары соң теләсә кем гармун ясау остасы була да алмас иде, чөнки ул музыкаль тоемга, сәнгати зәвыкка да ия, тагын агач, тимер, күн, пластик белән эш итә белерлек алтын куллы да булырга тиеш. Яңа гармунны ясау фанерадан корпусын ясаудан башлана. Аннары катыргыдан күрек ясала. Ул күн белән, сатин белән тышлана, почмаклар куела. Корпусның милли бизәкләр уелган кайбер детальләрен оста хәзер лазер станогында кисә. Мондый җиһазны Мәдәният министрлыгы биргән грант хисабына алган. Гармун ясауда иң четереклесе – телләрен ясау һәм уен коралын көйләү. Мәнә шунда кулларның осталыгы да, көйне ишетү сәләте камил булуы да күренә инде.

Җидеяр останың шәкерте бүген Татарстан белән Башкортстанда гармун ясаучы бердәнбер оста диярлек. Дөрес, аның үзенең дә берничә шәкерте бар, тик бу шөгыльдә камиллеккә ирешүе вакыт һәм эзлеклелек таләп итә. Ике республикага бер гармун остасы калу әлеге милли уен коралыбызның киләчәге өчен борчылырга, чаң сугарга кирәген аңлата. Хәзер кайчандыр гөрләп эшләгән гармун заводларыбыз юк, Җидеяр агалар да китеп бара. Ә бит тальян гармун – татар тормышының нәзакәтле бер бизәге, ул ике гасырга якын милләтебезнең шатлыгын да, хәсрәтен дә бүлешкән. Тальянда уйнап сугышка чыгып киткәннәр, тальянда уйнап мәҗлесләрдә җырлашып утырганнар, тальянсыз сабан туйлары үтмәгән. Тальян гармун халкыбызның милли моңы белән үрелгән газиз бер уен коралына, аның дәртле дә, моңлы да күңел көзгесенә әверелгән. Айрат оста: «Башкортстанда курай-кубыз нык почетта. Җырласалар да, биесәләр дә, башкортлар милли чалым итеп курайларын кушып җибәрәләр. Ә безнең тальян моңы онытылып бара. Югыйсә, ул бит татарның җанын ачып бирә. Теләк булса, тальяныбызны милли үзенчәлек итеп мәдәни тормышыбызда рәхәтләнеп кулланып булыр иде», – ди. Татарны татар иткән рухи байлыкларыбызны кыйпылчыклап җуеп бетермәсәк иде.

Эльмира СИРАҖИ.

Алтын Урданың

Алтын Урданың тарихы бөек тә, гыйбрәтле, шул ук вакытта фаҗигале һәм үкенечле дә. Барлык империяләрнең язмышы – атылган йолдызлар сыман. Тик йолдызлар атылгач, аларның эзләре сүнеп югалса, төрки империяләрнең эзе мәңгелек. Алтын Урданың эзе изелгән-имгәтелгән булса да, аның тарихындагы күп вакыйга әле ныгытып ачыкланууны, ялганнардан арынуны көтә.

Чыңгызхан үз империясе җирләрен өч улына – Җучигә, Тулуйга һәм Үгэдэйгә бүлеп биргәннән соң, Җучи Олысы – Алтын Урда дип атала башлый. Җучи хан үз дәүләтен Болгар иле үрнәгендә төзи, чөнки Идел Болгарстанын яулаганнан соң, монголларны мондагы күп тараф таң калдыра: мәдәният һәм мәгърифәт үсеше, илдәге тәртип һәм тормыш матурлыгы, оборона ныгытмалары, хәрби көчләр, сугыш стратегиясе, сакчылар күрсәткән батырлык һ.б.

Тора-бара Җучи Олысы җирләрендә яшәгән халыкларның тормышы кискен үсеш ала. Киләчәктә үзенә бирелгән «Алтын Урда» исеме – аның хакыйкый бөекләнгән, уңышлы һәм чәчәк атучы ил икәнлеген аңлата.

Европада инквизиция көчәйгән, фәннәр үсешенә юллар ябылган һәм тормышны караңгылык баскан чорда Алтын Урдага төрле яктан галимнәр, һөнәрчеләр килеп туплана. Төрки халыкларны берләштергән бу татар дәүләте торган саен үсә, көчәя бара. Монда татар мәдәнияте, идеологиясе һәм халыкның милли үзаңы оеша. Ул торган саен ныгый, камилләшә бара.

Алтын Урда дәүләтен төрле җирдә төрлечә атыйлар: гарәпләр – Дешт-Кыпчак иле, Җучи Олысы, яки Төньяк Татар патшалыгы; Европада – Кыпчак дәүләте, Татар иле; татарлар үзләре – Олуг Улус, Алтын Урда, дип йөртә.

Җучи үлгәч, аның урынына тәхеткә улы Бату утыра. Ул илнең башкаласын Болгар шәһәрендә урнаштыра, ләкин тиздән аны Идел елгасының түбән агымына күчерә. Аны шундагы җылы климат, йомшак, коры һава торышы һәм иксез-чиксез дала киңлекләре үзенә тарта. Моннан Җучи Олысының көньягын да, Европа өлешен дә контрольдә тоту җиңелрәк һәм Урта Азия, Кавказ, Иран кебек сәүдә үзәкләре дә якынрак була.

Илнең төрле регионнары белән идарә итү өчен Бату хан атлы почта курьерлары системасын оештыра. Бу әле моңа кадәр беркайда да күрелмәгән яңалык була. Тора-бара барлык зур юлларда ямнар – почта станцияләре челтәре оеша. Сәүдә юллары аерым өлешләргә бүленә һәм алар белән губернаторлар (даругалар) идарә итә. Алар узган-барган кешеләрне һәм товарларны исәпкә алып, барын да контрольдә тота. Тулы тәртип булдыру өчен аларга чикләнмәгән мөмкинлекләр һәм үз гаскәрләрен дә тотарга рөхсәт бирелә.

Ныклы тәртип урнаштыргач, бөтен империядә урлаулар туктатыла. Нәтиҗәдә товарлар агымы арта һәм казнага акча кереме күбәя. Ямнар хәзерге почта станцияләре, телеграф, тимер юл кебек элемтә вазифаларын да үти.

1313 елда ислам Алтын Урдада дәүләт идеологиясенә әверелгәч, башка дини конфессия вәкилләренә дә үз диннәрен тоту өчен тулы ирeклек һәм руханиларны рәнҗеткән кешеләргә каты җәза бирелә. Дин башлыклары барлык салымнардан да азат ителә.

Алтын Урда иленә Көньяк Европаның 3/4 өлеш җирләре һәм Көнбатыш Азиянең 1/2 өлеше керә. Урта гасырларда ул шәһәр һәм дала халыкларының күчмә культураларын да берләштерә, көчле һәм бай тарихлы уникаль дәүләткә әверелә.

Монда вәзир дәүләт башлыгы була. Ул хан идарәсе каршындагы диванны (советны) җитәкли. Хан нәселеннән булган хәрби кешеләрнең балалары – угланнар, башкаларныкы – морзалар дип, ә ханга буйсынган җирләрнең башлыклары – әмирләр дип атала һәм үз җирләре белән идарә итү өчен аларга махсус ярлыклар бирелә.

Хан гаскәрләре унлыкларга, йөзлекләргә, меңлекләргә һәм ун меңлекләргә бүленә. Монда каты тәртип хөкем сөргән һәм һәркемгә үзенең гаскәри бүлеге өчен тулы җаваплылык йөкләнә. Мәсәлән, бер кешенең куркаклыгы өчен бу хәрби бүлекчәдәге барлык сугышчылар да җәвапка тартыла.

Чынлыкта, Алтын Урда – ул барлык төрки халыкларның борынгыдан бирле килгән җирләрен берләштергән зур ил, империя була. Аңа Идел-Урал регионы, Урта Азия, Казахстан, Себер, Кырым һәм Дәште-Кыпчак җирләре керә. Димәк, ул шушы җирләрдә яшәгән төрки халыкларны берләштергән көчле дәүләт була. Шул халыкларның телләре бер-берсенә якын һәм аңлаешлы булганга, яңартылган, баетылган татар теле – ул Евразия киңлекләрендә яшәгән барлык халыклар өчен уртак телгә, яисә халыкара телгә әверелә.

Болгар олысы Алтын Урданың мәдәни үзәгенә әйләнә һәм шәһәрләр төзү буенча Алтын Урдада гына түгел, ул бөтен Евразия киңлекләрендәге дәүләтләр өчен дә үрнәк булып тора. Монгалы күчмә шәһәрләр үзләренең мәчетләре һәм базарлары белән бөтен дөнья халыкларны таң калдырырлык, уникаль күренешкә әйләнә. Шулай да, шәһәрләрендә бай тормыш кайнаган, югары культуралы бу илнең гомере чагыштырмача кыска була. Үз эчендәге каршылыклар, килеп чыккан эпидемияләр, табигать катаклизмалары аркасында Алтын Урда дәүләте көчсезләнә, хәлсезләнә бара. Нәтиҗәдә андагы төрле халыклар тулы бәйсезлеккә омтыла башлый.

Ни кызганыч, Евразия киңлекләрендә барлык төркиләрнең бербөтен булып берләшү процессы туктала һәм кумәк төрки-татар этносы оеша алмый кала...

Алтын Урда цивилизациясе – ул төрки халыкларның гына түгел, руслар һ.б. халыкларның да уртак ватанына әверелә. Монда үзара ызгышып, бер-берсен талап яшәгән рус кенәзлекләре берләшә һәм көчле дәүләт булып оеша. Сарайда беренче рус патриархаты оеша (Саровский) һәм күп чиркәүләр, монастырьлар төзелә.

Рус дәүләте Алтын Урда канаты астында ныгый, көчәя һәм үсеш ала. Алтын Урда гаскәре ярдәме белән алар шведларны җиңә һәм Литва кенәзлегенең яулап алу һәм католикларга әйләндерү сәясәтенә бирешмичә, православие динен саклап кала. Ниһаять, тора-бара Россия империя булу дәрәҗәсенә ирешә. Ни кызганыч, тик үз тарихларын язганда, руслар Алтын Урда чорын бары тик кара төсләргә генә буйый һәм үз илләре империянең басымы астында, изелеп яшәгән дип раслап килә.

Чынлыкта Алтын Урда белән Рус дәүләте мөнәсәбәтләре вассаллык, яисә үзидарә (самоуправление) рәвешендә төзелә. Монда аларның дәүләт төзелеше, аның идарә системасы һәм мөстәкыйльлеге саклана. Шулай ук тәхеткә утыру тәртибе, милли культура, мәгърифәт, дин, кораллы көчләр, дәүләт төзелеше, сәүдә системасы – барысы да мөстәкыйльлеккә нигезләнгән була.

Александр Невскийның Алтын Урда гаскәрләре белән ныклы хәрби-сәяси союзда булуы да билгеле хәл. Рус кенәзләренә болгар-татар кызларына өйләнү – ул зур дәрәҗә саналган. Мәсәлән, Александр Невскийның әбисе дә, әнисе дә татарлар булган.

Алдынгы фикерле сәясәтчеләр: «Татарлар һәм руслар – бер анадан туган, Алтын Урда балалары кебек. Аларны капма-каршы куярга түгел, киресенчә, Россиянең киләчәге ныклы булсын өчен, үзләрен берләштереп, араларын ныгытырга кирәк. Ләкин дә бу халыкларны бергә кушарга диган сүз түгел!» – дип яза. Алтын Урда дәүләтенең тарихы белән кызыксыну хәзер торган саен көчәя бара...

Үзбәк хан Алтын Урданың ил башлыклары арасында иң көчлеләрнең берсе була. Урта гасырларда инквизиция котырынып Европа илләрен караңгылыкка батырганда Алтын Урда империясендәге төрле фәннәр, мәгърифәт, һөнәрчелек һәм сәнәгать үсеше моңа кадәр күрелмәгән биеклеккә күтәрелә.

Үзбәк хан тәхеттә утырган чорда Алтын Урда дөньядагы иң көчле һәм бай дәүләтләрнең берсенә әверелә. Ни кызганыч, тик ул үткәргән кайбер реформалар нәтиҗәсендә бу империя торган саен көчсезләнә, ахыр чиктә бөтенләй таркала башлый. Ә мондый гайрәтле илнең таркалуына ниләр сәбәпче булган соң:

Беренчедән, Үзбәк хан төркиләрдә меңнәрчә еллар буена сакланып килгән һәм халык демократиясенең нигезе булган корылтайны – үзидарә (самоуправление) системасын юк итә. Бу аның хаталарының иң зурысы була. Чөнки ул дәүләт Конституциясе булган «Яса»дан читләшә. Мәсәлән, элгәре ханнарны бөтен халык Корылтайда сайлагач, аны ак киезгә утырткач һәм кулларында күтәреп, җыелган халыкка күрсәтеп чыкканнар. Тора-бара бу тәртип үзгәргән һәм хан үлгәч, аның урынына бер улы утыра башлаган. Ханның уллары күп булу сәбәпле, алар арасында канлы сугышлар купкан. Тәхет яулап, алар бер-берсен үтергән. Чөнки хан улларының һәркайсысы тәхеткә утыру хокукына ия булган.

Нәтиҗәдә 1359-1380 елларда гына да Алтын Урдада 20 дән артык хан алышынгач, ил хәлсезләнгән һәм таркалу юлына баскан. Үзара сугышлар барган җирләрдә тәртип какшагач, чит илләрдән сәүдәгәрләр дә монда йөрми башлаган. Индия, Иран һәм Кытай белән тоташтырган сәүдә юллары Европа-Азия җирләре аша түгел, ә океаннар буйлап, Африканы әйләнеп уза башлаган. Ямнар, базарлар, таможнялар ябылгач, гөрләп торган шәһәрләр мескен хәлгә калган. Ил бөлгенлеккә төшә башлагач, аның белән идарә итү дә авырайган. Кырым, Хорезм, Руслар иле һәм Идел Болгары кебек дәүләтләр бәйсезлеккә юл тоткан.

Икенчедән, Яса законнарыннан читләшкәч, җир биләү хокукы да үзгәргән. Элгәре бөтен җирләр дә хан кулында булып, ул аны бирә һәм яңадан тартып ала алган. Ә Үзбәк ханнан соң бөтен җирләр шәхси биләмәләргә әверелгән һәм алар

алтын тарихы



нәселдән-нәселгә бирелә башлаган. Бу хәл шулай ук ханнарның идарә итү системасының көчсезләнүенә китергән.

Өченче сәбәп – ул борынгы Тәңре дине кагыйдәләренең һәм Яса законнарының кинәт Шәригать кануннары белән алышынуы. Мәсәлән, ислам динендәге төп шарт – ул өйләнешүчеләрнең икесе дә мөселман булырга тиеш. Ә төрки булуы – шарт булмаган. Кемдер башка диндә икән – ул бары тик мөселманлыкны кабул итәргә тиеш булган. Әлбәттә, бу каннар катнашуына китергән һәм җиңелмәс дип саналган төркиләр генотибының да бөтенлегә какшаган.

Һәр халыкка Аллаһы Тәгалә тарафыннан аның үзенә генә хас булган көч-гайрәт (энергетика) бирелә. Аларның кайберсендә милли сыйфатлар көчле, икенчеләрендә – түбәнрәк. Халыктагы гайрәтлелек ул аның холкында, темпераментында һәм менталитетында ачык күренә. Бу аның канында туплана һәм нәселдән-нәселгә бирелә. Каннар катнашу нәтиҗәсендә төркиләр канында меңнәрчә еллар дәвамында тупланган һәм сакланып килгән пассионарлыгы (гайрәте, яшәү көче) һәм милли рухы кими, саега.

Дүртенче сәбәп – ул Алтын Урда чорында шәһәрләрнең күбәюе һәм аларның кискен үсеш алуы. Нәтиҗәдә зур урманнар киселеп юкка чыга. Экосистема бөтенлеге бозыла. Климат үзгәрә. Далалар ком чүленә әверелә. Кыш көннәрендә кар яву кими. Шул ук вакытта Каспий диңгезенең суы күтәрелә һәм күп җирләр су астында кала. Төрле бәлаләр аркасында халык ашкынып шәһәрләргә туплана. Бу хәл эпидемияләр килеп чыгуына сәбәп була. Чума чире халыкның дүрттән берен, кайбер җирләрдә туксан процентына кадәр кырып сала.

XIV гасыр ахырында ил күләмендә зур мәйданнардагы җирләр бушап кала. Бу хәл XVII гасырга кадәр дәвам итә. Хәлсезләнгән илдә тәртип урнаштырырга тырышкан Туктамыш ханның планнары да файда бирми. Аның зыялы катлау кешеләрен эзәрлекләве дә зур зыян китерә. Нәтиҗәдә алар хан властена каршы көрәш башлый.

Ә Туктамышның Аксак Тимер белән 1391 һәм 1395 елларда алып барган сугышлары хәлсезләнгән Алтын Урда дәүләтен катастрофага китерә. Нәтиҗәдә Урта Идел җирләре тулысынча бушап кала. Ә XV гасыр башында Алтын Урда тулысынча таркала.

Ләкин Алтын Урда таркалгач, аның халкы башкалар арасында сеңеп юкка чыккан дип уйларга ярамый. Аның урынында үзеннән аерылып чыккан башка дәүләтләр барлыкка килә:

- Көнчыгыш Европаның көньягында – Кырым ханлыгы;
- Урал артында – Себер ханлыгы;
- Түбән Иделдә – Әстерхан ханлыгы;
- Идел белән Җаек елгалары арасында – Нугай Урдасы;
- Идел белән Кама елгалары тирәсендә – Казан ханлыгы;
- Урта Иделдә – Рус дәүләте.

Яңа дәүләтләр арасында Рус дәүләте иң тормышчан булып чыга. Ул Алтын Урдадан аерылып чыккан илләрдәге иң уңышлы хезмәткәрләрне, галимнәрне һәм төрле халыкларның зыялы катлам кешеләрен үзенә тартып китерә. Нәтиҗәдә ул үсеш юлында булып, иң көчле дәүләтләрнең берсенә әверелә. Россия дәүләте тора-бара Алтын Урдадан чыккан барлык дәүләтләрне басып ала һәм элгәреге бөтен империя җирләренә хуҗа була...

Европаның, Урта Азиянең һәм Төньяк Африка континентларында яшәгән халыкларның күбесенә цивилизация үрнәкләре күрсәткән Алтын Урда иленең язмышын Чыңгызхан империясе тарихыннан башка күз алдына китерү мөмкин түгел.

Кызганычка, тарихчылар арасында Чыңгызханга карата әлегәчә төрле караш яшәп килә. Берәүләр аны дөнья тарихын кискен рәвештә борып, аңа уңай юнәлеш биргән данлыклы полководец һәм төрки халыкларны берләштереп, Евразия цивилизациясенә нигез салган бөек юлбашчы дип исәпли. Икенчеләр – киресенчә, аны ярты Җир шарын яулап, күп халыкларны җәберләп изгән, кансыз шәхес булган дип раслый. Чынында кем булган соң ул, кешелексез тиранмы, әллә бөтен кешелек тарихын уңай эзгә салган прогрессив реформатормы?

Ни булса да, әле хәзерге көндә дә, күпләр аны көчле идеология һәм пропаганда коралы итеп куллана. Берәүләр аңа һәйкәлләр куя, ә икенчеләр аннан куркыныч карачкы ясый. Ләкин дөреслекне җиргә күмеп тә, яндырып та булмый. Тора-бара ул җир асларыннан, су төпләреннән калкып чыга, хәтта көл хәлендә дә телгә килеп, күпне сөйли ала.

Мәсәлән, Чыңгыз ханның хәрби походлары алдыннан аның дипломатлары үзләренең барасы җирләрендә яшәгән халыкларның җитәкчеләрен, аксакалларын хан ирегенә буйсынырга үгетләп, империя канаты астына керү турында сөйләшүләр алып барган. Буйсынган халыкларга алар тимәгән һәм беркайчан да коралсыз халыкка корал күтәрмәгән.

Кем соң ул, бөек Чыңгызхан һәм нинди тормыш юлы үткән? Моны белү өчен ул яшәгән чорларны һәм сәяси хәлләрне күз алдына китерү кирәк.

Чыңгызхан яшәгән чорда, яисә XII гасыр башында дала халыклары арасында бер-берсе белән талашып яшәгән күпсанлы хәрби дружиналарның барлыкка килүе – ул феодализм үсешенә бәйләнгән. Аларның үзара булган каршылыклары да көтүлек җирләре бүлешеп, бер-берсеннән салым түләтергә тырышудан килеп чыккан.

Бу очракта далада ныклы тәртип урнаштыру кирәклеге көн тәртибенә баса. Коралланган хәрби дружиналар арасында Тимучжин (Тимерҗан) иң гайрәтлеләрдән була һәм 1189 елда ул халык тарафыннан хан итеп сайлана. Ә инде 1206 елда ул бөтен монголларның һәм төрки халыкларның ил башлыгы (Верховный правитель) итеп сайлана һәм «Чыңгызхан» – ханнар ханы дип атала башлый һәм кыска вакыт эчендә үз дәүләтендә катгый тәртип урнаштыра. Аңа буйсынган феодаллар арасында булган каршылыклар туктала. Чыңгызхан дөньяда иң көчле армия төзи һәм якын-тирәдә яшәгән Себер халыкларын, Төньяк Кытайны, Урта Азиядәге илләрне яулап, Тын Океаннан Кара диңгезгә кадәр җәелгән җирләрдә империя төзи.

Чыңгызхан төзегән «Яса» Конституциясе һәм дәүләт төзү тәртибе барлык төрки дәүләтләр өчен XIX гасырга кадәр өлге булып килә. Хәтта Рус дәүләтенең «Русская правда» дигән 1497 елгы Иван III чорындагы беренче суд кануннары һәм Иван Грозныйның 1550 елдагы судебнигы да Ясага һәм христиан дине кануннарына нигезләнә.

Яса кануннары аңа кадәр кешелек дәверендә кулланылган күп империяләрнең хокук кануннарын да кулланып язылган. Чыңгызхан иң элек үзе шуңа буйсынган һәм халкыннан да шуны таләп иткән. Яса кануннарының әһәмияте бөтен дөнья күләмендә киң танылган һәм төрле илләрдә аны үзләренчә уңышлы кулланалар.

Фәрид ШИРИЯЗДАНОВ.

Айга кырын карама

Халык медицинасы чаралары белән дәвалануга керешкәнче, табиб белән киңәшү зарур!

4 июнь (шимбә). ***Зөлкагдә аеның 5 нче көне. 6 нчы Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында, 6.43 сәгатьтә калка, 0.23 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.16 сәгать.***

Хисчәнлек арта. Һәртөрле аралашу күңелгә ятышлы. Бу көннәрдә эти-әнигә ихтирам көче аеруча куәтләнә, гаиләдә бергә җыелып, балачакның күңелле хатирәләрен яңарту яшәү көче өсти. Бизләр системасы, җилкә, кул, үпкә, бронхлар зәгыйфь, салкын тию ихтималы зур. Теш алдырырга ярамый.

Гастриттан дәва

Хроник гастрит (ашказанының лайлалы тышчасы ялкынсыну) һәм ашказаны җәрәхәтеннән интеккәндә, кәбестә согын сыгып, җылы килеш, көненә 2-3 тапкыр, ашарга 1 сәгать калгач эчәргә кирәк. 5 көннән соң хәл җиңеләя. Мондый дәвалануны елына 2 тапкыр үткәрү җитә.

5 июнь (якшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 6 нчы көне. 7 нче Ай тәүлеге. Ай Арыслан йолдызлыгында,8.00 сәгатьтә калка,0.37 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.18 сәгать.***

Һава энергиясенә бәйле көн. Тынгысызланырга, гайбәт сөйләргә ярамый. Ялгыз калып уйлану файдалы. Нерв системасы, үпкә зәгыйфь. Ач тору, ашказаның һәм эчәклекне чистарту уңай нәтиҗә бирә.

Чикләвек сөте

Ашказаны җәрәхәтеннән интеккәндә, чикләвек сөте эчү файдалы. 4-5 әстерхан чикләвеген төеп, өчтән бер стакан кайнаган җылы су өстиләр, 30 минут тонәтәләр дә, яхшылап болгаталар. Аннары сөзәләр, 2 чәй кашыгы бал кушалар. 10 көн дәвамында, көненә 5 тапкыр, ашарга ярты сәгать кала, 1әр чәй кашыгы кабалар.

6 июнь (дүшәмбе). ***Зөлкагдә аеның 7 нче көне. 8 нче Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында,9.19 сәгатьтә калка, 0.49 сәгатьтә бата. 1 нче фаза. Көн озынлыгы 17.20 сәгать.***

Бүген бигрәк тә ут белән эш иткәндә саклык сорала. Ризык җиңел үзләштерелүчән булырга тиеш. Ашказаны, бизләр системасы зәгыйфь, невралгия һәм стенокардияне кисәтү чаралары уңай нәтиҗә бирә. Колак авыртырга мөмкин. Бу атнада күзне саклау мөһим.

Сихәтле сок

Кызыл чөгендер согы бигрәк тә хатын-кызларга файдалы, тик аны кишер согына кушып эчү мәслихәтрәк. Чиста чөгендер согы эчү күңелне болгатырга, башны әйләндерергә мөмкин. Күрем көннәрендә 2-3 тапкыр 50-100әр грамм чөгендер-кишер согы катнашмасы эчәргә кирәк. Климакс вакытында тәүлегенә 1 стакан сокны әкренләп эчеп бетерү дарулардан яхшырак дәвалый. Чөгендер согында 20 процент калий бар, ә составында 8 процент хлор булу аңа бавырны, бөерне, үт куыгын чистартырга мөмкинлек бирә. Әлеге соктагы

(Дәвамы 18 нче биттә).

Айга кырын карама

50 процент натрий һәм 5 процент кальций нисбәте, куе канны сыегайтып, веналарның варикоз киңәюе, югары кан басымы, йөрәк авыруларыннан саклый.

7 июнь (сишәмбе). ***Зөлкагдә аеның 8 нче көне. 9 нчы Ай тәүлеге. Ай Кыз йолдызлыгында, 10.39 сәгатьтә калка, 0.58 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.22 сәгать.***

Авыр энергетикалы көн, алдашу, ялганга бай. Хәтта сыйфатлы ризык белән дә агулану ихтималы бар. Күп аралашу хупланмый. Фикерләрне тупларга, үзегезне үпкәләткән кешеләрне кичерергә кирәк. Үпкә, ашказаны зәгыйфь. Кан басымы күтәрелергә, йөрәк, арка яки баш авыртырга мөмкин. Мунча керү файдалы.

8 июнь (чәршәмбе). ***Зөлкагдә аеның 9 нчы көне. 10 нчы Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 11.59 сәгатьтә калка, 1.06 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.23 сәгать.***

Нәсел, гаилә, гореф-гадәтләр белән бәйле көн. Ял итү, йокы туйдыру, гаиләне ныгыту өчен иң шәп вакыт. Әйләнә-тирәдәгеләргә игътибарлырак булу сорала. Сизү әгъзалары, йөрәк-кан тамырлары системасы, сөякләр зәгыйфь. Ач тору файдалы.

Бөтнек биздерә

Аракыдан бизү өчен, эмальләнгән кәстрүлдәге 1 стакан кайнар суга 1 аш кашыгы вакланган бөтнек яфрагы салып, капкачын ябып, 15 минут пешерәләр, ярты сәгать төнәткәч, сөзәләр. Көненә 2 тапкыр, ашаганнан соң 1 сәгать үткәч, яртышар стакан эчәләр, 10 минуттан соң ярты стакан суга 1 аш кашыгы аракы кушып, авызны чайкыйлар.

9 июнь (пәнҗешәмбе). ***Зөлкагдә аеның 10 нчы көне. 11 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 13.22 сәгатьтә калка, 1.14 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.25 сәгать.***

Үзгәрү, сафлык, катгыйлык көне. Һәр эштә дә сак һәм игътибарлы булу сорала. Башланган эшне ахырына җиткерергә кирәк. Бу көннең энергетик куәте бик зур, кешедә искиткеч табигый көч уянырга мөмкин. Арып-талганчы эшләргә ярамый. Сизү әгъзалары, йөрәк, умырткалык, үпкә зәгыйфь.

10 июнь (җомга). ***Зөлкагдә аеның 11 нче көне. 12 нче Ай тәүлеге. Ай Үлчәү йолдызлыгында, 14.48 сәгатьтә калка, 1.23 сәгатьтә бата. 2 нче фаза. Көн озынлыгы 17.27 сәгать.***

Шәфкать, сабырлык, мәхәббәт энергиясенә бай көн. Сәламәтлеккә игътибарлы булырга, йөрәккә киеренкелек китермәскә кирәк. Ашкайнату әгъзалары, кан әйләнеше системасы зәгыйфь. Дарулар яхшы үзләштерелә.

Кыздырылган тавык

Кыздырылган тавыкның тиресе кетердәп торсын өчен, берничә ысул бар: 1) газ миченә тыкканчы, тавыкны газ өстендә атланмайда кыздырып алалар, 5 минуттан соң мичкә куялар; 2) мичкә тыккач, бүленеп чыккан тавык маен әкренләп өстенә агызгалап алалар, соңгы 10 минутта исә тимиләр – тире кибеп китә һәм тагын да яхшырак кетерди; 3) мичкә тыгар алдыннан тоз, борыч һәм зәйтүн мае белән ышкыйлар; 4) әзер булыр алдыннан бал һәм май катнашмасы белән майлыйлар; 5) пешеп җитәр алдыннан тавыкны 3 өлеш соя (кытай борчагы) соусына 1 өлеш бал кушып майлыйлар.

«Татар сүзе»нең җиңүчеләре билгеле

Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Татар телен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе һәм Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе икенче тапкыр татар әдәби әсәрләрен сәнгатьле сөйләүчеләрнең «Татар сүзе» халыкара бәйгесен оештырды.

Быел анда дүрт меңгә якын милләттәшебез катнашкан. Икенче турга шуларның 310 ы үткән, 40 ы финалга чыккан. Татар шигырьләре, проза әсәрләре, мәсәлләренә гашыйк милләттәшебезнең чыгышын күренекле әдәбият галиме Фоат Галимуллин, шагыйрә Илсөяр Иксанова, җырчы Айдар Фәйзрахманов, телевидениедә тапшырулар алып баручы Илдар Кыямов, К.Тинчурин театры артисты Резидә Сәлахова бәяләде. Бәйге Г.Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясенең концерт залында зур гала-концерт белән тәмамланды.

Катнашучылар яшьләре һәм әзерлекләренә карап төркемнәргә бүленгән. 10 яшькә кадәргеләрнең байтагы Балтач районыннан булуы игътибарны җәлеп итте. Икенче категориягә кергән яшүсмерләрнең шактые Казан шәһәреннән булса да, чыгышларына караганда татар телен әйбәт беләләр. Өченче төркемдәге гүзәл ханымнар ничә яшьтә булуларына карамастан, күңел ялкынын җуймаулары белән һәркем үрнәк алырлык. Автор-башкаручылар төркемендә җиңү яулаган шагыйрьләр Гөлүсә Батталова, Булат Ибраһимов, күренекле нәфис сүз остасы Алмаз Хәмзин янәшәсендә Алинә Шәгәрәева һәм Нурия Бәшированы күрү һәм һөнәрмәндләрнекеннән бер дә ким булмаган иҗат әсәрләрен ишетүдән күңел бик мәмнүн булды. Гаиләләр белән чыгыш ясаучыларны аерым бүләкләделәр. Мамадыштан Мишустиннар, Лаештан Нурмөхәммәтовлар, Актаныштан Гаяновлар, Казаннан Шахбановлар гаиләләрендә олысы-кечесе милли гореф-гадәтләребезне кадерләп саклый, телебезнең сафлыгы өчен көрәшә. Андый гаиләләрдә тәрбияләнгән балалардан галимнәр, шагыйрь, язучылар, җырчылар чыгар әле, иншаллаһ. Һөнәрмәндләр төрендә җиңүчеләр татар спектакльләре аша милләттәшләребезгә яхшы таныш. Камаллылар Ришат Әхмәдуллин, Эмиль Талипов, Тинчурин театры артисты Артем Пискунов, Әлмәт драма театрыннан Динар Хөснетдинов әнә шулай төп эшчәнлекләреннән тыш татар сүзенең сафлыгын сакларга үзләреннән өлеш кертә.

Бүләкләү тантанасында былтыргы лауреатлардан Камал театры артисты Фәннур Мөхәммәтҗановны күрү бәхете елмайды. «Татар сүзе» бәйгесе оештырылмаса, сәнгать сөючеләребез егетнең үткер теллелеген белми дә калган булыр иде, мөгаен. Былтыр җиңү яулаган егет – мөмкинлекләре чикле Тимур Фазлыев бәйгедә җиңгәне өчен бүләк итеп бирелгән арбасына утырып сәхнәгә чыкты һәм тетрәндерерлек шигырь бүләк итте. Нәфис сүз А.Фәйзрахманов җитәкчелегендәге Татар дәүләт фольклор музыкасы ансамбле, җырчылар Илгиз Мөхетдинов, Рөстәм Насыйбуллин һ.б. чыгышлары белән үрелеп барды. «Бу чараны сәнгатьле сөйләүчеләр бәйгесе дип әйтү дөресме икән? Һәр чыгыш ясаучы үзенең сайлаган әсәре геройлары булып яши кебек. Татар халкы шулкадәр талантлы! Матур телебез, талантлы татар милләте югалырга тиеш түгел!» – диде кичәне йомгаклап Татарстан Республикасы Дәүләт Советы рәисе урынбасары Марат Әхмәтов. Ул җиңүчеләрнең чыгышлары буклетлардагы QR-кодлар аша бөтен республика халкына таратылачагы, киләчәктә «Татар сүзе» бәйгесен зур телевизион проектка әйләндерәчәкләре турында әйтте.

Миләүшә ГАЛИУЛЛИНА.

МӘК тамаша заллары чакыра

Г.КАМАЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

3 июнь – Евгений Вахтангов исемендәге академия театрының «Война и мир» спектакле (Л.Толстой).
4 июнь – «Килмешәк» (С.Гаффарова).
5,6 июнь – Евгений Вахтангов исемендәге академия театрының «Евгений Онегин» спектакле (А.С.Пушкин).
6 июнь – кече залда – «Томан» (Г.Сәгыйтова).
8 июнь – Театр оркестры концерты.
10 июнь – «Сәфәр» (А.Шакиров).

К.ТИНЧУРИН ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ДРАМА ҺӘМ КОМЕДИЯ ТЕАТРЫ

3 июнь – «Беренче театр» (Г.Камал).
5 июнь – 13.00, 15.00 – «Менә сиңа куш кулым» (А.Садриев).
6 июнь – «Ак тәүбә, кара тәүбә. Безнең көннәр» (Т.Миңнуллин).
7 июнь – «Күрәсем килгән иде...» (И.Мәхмүтова),
8 июнь – «Мәдинә» (И.Зәйниев).
9 июнь – «Өзелгән яфраклар» (Р.Габделхакова).
10 июнь – «Полиционер» (И.Зәйниев).

М.ҖӘЛИЛ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ҺӘМ БАЛЕТ АКАДЕМИЯ ТЕАТРЫ

10 июнь – «Трубадур» (Дж.Верди).

Г.КАРИЕВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТАТАР ДӘҮЛӘТ ЯШЬ ТАМАШАЧЫ ТЕАТРЫ

6 июнь – «Ак чәчәкләр кебек...» (Р.Мухина).
7 июнь – «Матур City» (А.Әхмәтгалиева).

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ

3 июнь – «Ночь перед Рождеством» (Н.Гоголь).
4 июнь – 11.00, 13.00, 15.00 – «Маугли» (Р.Киплинг), 12.00 – «Су анасы» (Г.Тукай).
5 июнь – «Один день из жизни улитки» (Ольга һәм Юрий Устюговлар). 12.00, 14.00 – «Буратино» (А.Толстой). 13.00 – «Сертотмас үрдәк» (А.Алиш).
10 июнь – «Дитя Аллаха» (Н.Гумилев).

Тары җире, киндер җире

● К.Сатиев белән. 80 нче еллар.



Кая гына барсаң да, кем белән генә аралашсаң да, берәр мәзәк яки кызыклы вакыйга сөйләүне сорыйлар. Ләкин Хәнәви Шәйдуллин турында кызык-мызыклар әлләни күп дип әйтмәс идем. Гомумән, хакыйкать бик кызык булмый инде ул. Шулай да, хәтер йомгагын сүтеп, бер вакыйганы искә төшереп узу урынлы булыр.

Кыш. Буран. Әче таңнан концерт оештырырга барам. Караңгы урамда ике апаның гәпләшүе колакка чалына: – Ишеттеңме, Хәнәви концерт белән килә. – Нинди Хәнәви? – Соң, Хәнәви Шәйдуллин инде. – Белмим мин аны! – Теге инде «Тары җире»н җырлый торган. – Ә, шулай диген. Аны беләм. Ә син Хәнәви Шәйдуллин дип баш катырасың.

Тагын берсе.

Х.Шәйдуллин Татарстан радиосына җыр яздыра. «Ай, булмай, булмай, булмай».

– Стоп! Хәнәви абый, бу Татарстан радиосы – булмай дип түгел, булмый дип җырлагыз.

– Ярар, аңладым.

– Тынлык, язабыз, башлагыз.

– Ай, булмай, булмай, булмай.

– Түгел инде, булмый дияргә кирәк.

– Аңладым, аңладым.

– Пишем! Ай, булмай, булмай...

– Стоп! Булмай түгел, булмый!

– Булмай инде, алайса, ди.

Нишлисең, үзенчә патриот – башкорт теленә якынайтып, Актанышча итеп язмакчы була, ләкин җыр язылмыйча кала.

Башкаручыны – җырыннан, җырны башкаручысыннан белеп була. Кайвакытта җыр кешене дөньяга таныта һәм кеше җырны җиһанга тарата, аннан «үлемсез» әсәр ясый. Һәркемнең үз җыры. Ул аңа гына хас, аңа гына килешә. «Эх, сез матур кызлар» – Асафныкы. «Җомга» – Хәмдүнә, «Җидегән чишмә» – Зөһрә, «Керкәле таулары» – Газинур, «Туй җыры» – Вафирә, «Идел буе каеннары» – Илһам абый, «Кәккүк» – Әлфия апа, «Кайтыгыз, торналар» – Габдулла ага, «Нефтьчеләр маршы» – Мәсгут абый, «Әниемә» – Флүрә ханым, «Гөлнарым» – Таһир, «Киек казлар» – Нәфисә... Ә «Тары җире, киндер җире» – әлбәттә, Хәнәвинеке! Х.Шәйдуллин «Тары җире»н «үстерде»ме, әллә «Тары җире» Хәнәвине дөньяга таныттымы – монысы бераз бәхәсле мәсьәлә. «Тары җире» – Хәнәви абыйның «визит карточкасы».

Җырчының пенсия вакыты якынлаша. Филармония җитәкчеләре: «Х.Шәйдуллинның лаеклы ялга чыгарга берничә концерты җитми, әллә эшләп кайтасыңмы?» «Бик теләп», – дидем. Якын-тирә районнарда, авылларда кунып эшләп йөрибез. Кунакханә йә бөтенләй юк. Йә – тулы. Кыш. Салкын. Буран. «Якташлар булыйк, яңакташлар булмыйк», – дидем.

Бер авылга килеп җиттек. Кечкенә клуб. Безгә аның зурлыгы мөһим түгел: план тутырырга концертның саны кирәк. Идән – бозлавык, кайнар су белән эретә-эретә юалар. Без клуб тирәсен арчыйбыз – кар көрибез. Нишләптер, төтен торбадан түгел, мич авызыннан сәхнәгә, залга тарала. Сәбәбе – төтен торбасына кош оялаган икән! Аны ничек итсәк иттек, чистарттык – төтеннән котылдык. Эш җайланды. Концерт шыгрым тулы залда гөрләп узды.

Х.Шәйдуллин сәхнәгә чыкканда ук, «Тары җире»н җырлавын сорыйлар. Ул аныкы, аның җыры – визит карточкасы! «Булыр», ди халкыбызның сөекле җырчысы. Халык түземсезләп белән көтә. Һәм... соңгы җырым – «Тары җире, киндер җире» дип игълан итә. Зал гөрләтеп кул чаба һәм шушы әсәрне тамашачы соравы буенча, берничә тапкыр башкара. Көчле алкышлардан клуб ишелер дәрәҗәгә җитә...

● Әлфия Авзалова җитәкләгән «Казан утлары» вокаль инструменталь ансамбле белән. 80 нче еллар.

Хәмзә улы Хәнәви Шәйдуллин сугыш алдыннан – 1938 елда Актаныш районының Табанлыкүл авылында туа. Тормыш ул гел шулай – йә сугыш алды, йә сугыш арты. Сугышларның беткәне, туктаганы юк. Кешелек дөньясы, кешенең психологиясе шулай корылган. Адәм баласы гына түгел, хайваннар да, кош-кортлар да гел сугышып, сөзешеп, нәрсәдер бүлешеп яши. Ике этәч сугыша. Ә нигә, ризык җитәрлек, тавыклар – күп. Аша, эч, җитә бит! Көтүдә сыерлар сөзешә. Болын иркен, үлән – күп. Юк, сөзешә, нәрсәдер бүлешә. Һаман җитми җан ияләренә. Ә кешегә – ике метр җир җитә...

Хәнәви ятим үсә, көтү көтә. Әдәбият–сәнгатьне ярату, җыр-моңга гашыйк булу табигатьтән килә...

Ашханәгә кергәч, тәлинкәдәге үләннәрне читкә алып куя.

– Хәнәви абый, бу бит витамин, нигә ашамыйсың дип бер артист әйткәч, энем, мин аны авылда көтү көткәндә кибәне белән ашадым, хәзер сез ашагыз инде. Минем яшел үлән ашау планым гомерлеккә тулды, диде.

Хәмзә улы Хәнәви 1961–1965 елларда Татар дәүләт җыр һәм бию ансамблендә хор җырчысы булып эшли... 1965–1969 елларда Казан музыка училищесында белем ала. 1969 елдан 1975 елга кадәр ансамбльнең солисты. 1975 елдан эстрада җырчысы, Татарстанның атказанган артисты. Өйләнгән, улы, кызы, бер оныгы бар.

Без өч якташ – Хәнәви абый, мин, Әлфия Авзалова бригадасында эшләдек, дөнья гиздек. Гастрольләрдә татарлар яши торган барлык төбәкләрдә диярлек булдык: Мәскәү, Ленинград, Ижау, Сембер, Йошкар-Ола, Пермь өлкәсе, Свердловски, Чиләбе, Уфа, Ырынбур, Төмән, Волгоград, Әстерхан, Төркмәнстан – Ашхабад, Чарджау, Бәйрам-Али, Мары, Кушка. Үзбәкстан – Ташкент, Сәмәркәнд, Бохара, Фирганә, Әндиҗан, Нәманган, Маргелан. Таҗикстан – Дүшәмбе, Турсунзаде һ.б.лар.

Кешелек сыйфатлары турында берничә сүз.

Ул мине күп нәрсәгә өйрәтте. «Энем Кирам, армия – бер нәрсә, ә филармония – башкачарак, – дия иде. – Төп аерма шунда: анда офицерлар, прапорщиклар синең турында кайгырта, ә гражданкада – үзең». Остап Бендерның: «Спасение утопающих, дело рук самих утопающих»ны исемә төшерде.

Кунакханәләрдә бер бүлмәдә яшәдек, үзен миннән өстен куймады, кимсетеп, түбәнсетеп карамады. Бары – бергә, югы – уртак булды. Кыска җырларны (такмакларны) башкару өчен аерым бер осталык кирәк. Әйтик, «Бөрьян егетләре»нә үзеннән, дөресрәге, үзенә генә хас булган бизәкләр: әте, әте, әте, «әте»ләрне; «әттер итә, тердер итә, әттер итә, тердер итә»ләрне өстәп, бу такмактан зур композиция, аерым бер спектакль ясады һәм такмакны шедеврга әйләндерде.

Ә «Тары җире»н, Хәнәви Шәйдуллинны искә алу кичәсендә, бер халык артисты җырлап маташты. Ул аның эчтәлеген, характерын ачып бирә алмады, образ турында сүз дә юк, җитмәсә ике урында сүзен онытты.

Хәнәви абый гел әйтә иде: «Кирам якташ, 2000 елны күрәсем килә. Дөнья бетә дип әйткән бит бер акыл иясе. Ничек булыр микән? Шуңа кадәр үлмәскә иде!» Теләге кабул булды: ул 2001 елда арабыздан мәңгелеккә китеп барды.

Хәмзә улы Хәнәви Шәйдуллин турында күп һәм мәгънәле итеп сөйләргә, язарга була. Ул моңа һичшиксез лаек... Аның исемен мәңгеләштерү турында җитәкчеләр уйлансын һәм аны тормышка ашырсын иде.

Кирам САТИЕВ,
Татарстанның
халык артисты.

Кыю хатын

Дөньяда беренче халыкара авторалли 1901 елда Париж белән Берлин арасында үтә. Озынлыгы 1100 километрлы узышта 121 ир-ат һәм бердәнбер хатын-кыз – Камилла дю Гас катнаша. Һәм бу кыю француз кызы 32 нче булып килә! Кызганыч ки, ул башка узышларда катнашмый. Камилла бик мавыгучан кеше була, автоспорт белән җенләнә башланганчы, ул аэростатта оча һәм парашют белән сикерә (бу бит әле XIX гасыр азагы гына!). Автомобиль рулен исә дю Гас спорт катеры штурвалына алыштыра, һәм инде 1904 елда Алжир-Тулон диңгез узышында җиңә! Соңрак исә ат чабышлары белән мавыга, атлар үрчетә. Аның турында соңгы хәбәр 1939 елда теркәлгән: бу вакытта Камилла дю Гас виртуоз-пианист сыйфатында Европа буйлап гастрольдә йөри.

(“Batona.net”).

Кыйммәтле табылдык

Майкл Спаркс Нэшвиллдагы иске әйберләр сатыла торган City Thrift Store кибетенә йөрергә ярата. 2006 елда бер баруында ул саргаеп беткән, кырыйлары ертылган, гравюрага охшаган бер документны 2,48 долларга сатып ала. Өенә кайтып яхшылап карагач, ул әлеге кәгазьнең АКШ ның Бәйсезлек декларациясе булуын аңлый. Бәяләүче моның чыннан да Декларациянең рәсми күчермәсе икәнен раслый. Джон Квинси Адамс 1820 елда шундый 200 нөсхәне ясатып алган, безнең заманга кадәр исә нибары 35 данәсе генә килеп җиткән. Майкл сатып алганы 36 нчы булып чыккан, ул аны реставрацияләткән һәм 2007 елда Төньяк Каролинадагы Берлингтон аукционына куйган. Анда исә Спаркснең табылдыгы 477650 долларга сатылган. Ә менә 1991 елда Пенсильвания штатының Адамстаун базарыннан 4 долларга алынган картина эченнән чыккан документ Декларация оригиналларыннан берсе булып чыккан һәм бәхетле яңа хуҗасына аукционда 2,4 миллион доллар табыш китергән.

(“Novate.ru”).

Акула дельфиннан куркамы?

Акуланың дельфинны яратмавы кешегә күптән мәгълүм. Дельфиннарны күреп алуга ук, акула мөмкин кадәр ераграк йөзеп китәргә тырыша. Ул – бик сак җан иясе, ялгызлыкны сөюче ерткыч. Гел берүзе генә йөри. Дельфиннар исә гел төркемләп сәяхәт итә, зәгыйфь һәм карт кардәшләре турында да кайгырта. Алар үзләре беркайчан да акулага һөҗүм итмәс иде. Әмма кайвакыт ерткыч зәгыйфьләнгән дельфиннардан берсенә кызыга һәм тотып ашый, шуннан соң исә аңа көн бетә – акыллы хайваннар аны төркемнәре белән урап ала да, куәтле томшыклары белән акуланың саңак ярыкларына кыйный башлый. Бергәләп, алар акуланы тиз арада бик җиңел үтерә, ә менә бергә-бер чыгарга туры килсә, ерткыч һичшиксез җиңәр иде.

(“Fauna.ru”).

Фиргавен консервасы

Консерваларны бик борынгы заманнарда да ясаганнар икән. Тутанхамон төрбәсендә табылганы – иң борынгысы. Авызы сумала белән ябыштырылган балчык савыттагы үрдәкне галимнәр хәзер дә ашарга яраклы, дип саный, гәрчә аның яраклылык вакыты моннан 3 мең ел элек үк чыккан инде. Ризыкны пыяла банкаларда консервлауны француз Аппер уйлап тапкан, 1809 елда ул моның өчен 12 мең франк премия алган. Әмма пыяла банкалар тиз ватылганга, юлда йөртергә җайсыз булганга, консерва савытын камилләштергәннәр. Моны инглиз Питер Дюран эшләгән. Ул пыяла урынына ныгытып ябылган калай банка кулланыну керткән. Англиядә калай консерва савытларын кулдан берничәшәр данә генә ясасалар, 1817 елда Америкада аларны станокларда йөзәрләп җитештерә башлаганнар. Россиядә исә беренче консерва заводы 1870 елда ачылган. Анда төрле боткалар, рагу, борчак шулпасы, кыздырылган ит, итле борчак кебек ризыклар тутырылган консервалар җитештерелгән.

(“ИнтересNIK”).

Каһвә хәтерне саклый

Каһвәне чамасын белеп кенә даими куллану хәтер начарланудан һәм Альцгеймер авыруыннан саклый икән. Каһвә турында фәнни мәгълүмат институты галимнәре шундый фикергә килгән. Алар әйтүенчә, бу тәмле эчемлекне көненә 2-5 чынаяк эчү өлкән яшьтәгеләрдәге нейродегенератив тайпылышлар ихтималын 27 процентка киметә. Әлегә белгечләр моның фәнни механизмын аңлатып бирә алмый, тик сәбәпнең каһвәдәге кофеин, антиоксидантлар һәм ялкынсынуга каршы агентларда булуын инде төгәл белә.

(“Die Presse”).






Балетта иң бай кеше

Париж операсының мәһабәт бинасы бик күп күренекле шәхесне хәтерли. Әмма XX гасырда биредә чын революция ясаучы кеше бер генә – татар баласы, мәшһүр биюче Рудольф Нуриев. 1983 елдан 1989 елга кадәр ул биредәге балет труппасына җитәкчелек итә. 1961 елда Франциядә сәяси сыену урыны тапкан, аннары Австрия гражданлыгы алган биюче 1965 елда һәр спектакле саен 2800 доллар акча эшли. 1970 елда аның бер спектакльдә биюе 7 мең долларга бәяләнә. Ә инде Noureev and friends труппасы белән бергә чыгыш ясаулары 10 мең доллар тора. 1990 елда исә Нуриев һәр чыгышы саен 20 мең доллар акча эшли. Елына 250-300әр спектакльдә биеп, ул гаять зур байлык туплый. Нуриев искиткеч кызу темпта яши: мәсәлән, көндез Парижда спектакльдә бии; иртән Лондонда репетициядә катнаша; бер көннән Монреальдә чыгыш ясый; тагын ике көннән Токиога гастрольгә китеп бара; аннан – Буэнос-Айрес; аннары Австралия буйлап турне; шул арада Нью-Йоркта телевизион тапшыруда да төшәргә өлгерә. Тәүлегенә нибары 4-5 сәгать йоклый – йә машинада, йә самолетта. Һәм ул шул темпта бер-ике ел гына түгел, дистәләрчә ел буе яши. Париж һәм Нью-Йорктагы зиннәтле фатирлары, Сент Барт һәм Лондондагы виллалары, АКШтагы ранчосы, Урта диңгездәге ике утравы (аларны 40 миллион долларга сатып ала) антиквариат һәм сынлы сәнгать әсәрләре белән шыплап тула. Нуриев балетта иң бай кеше була, костюмнарын данлыклы итальян кутюрьеларыннан гына тектерә (вафатыннан соң, мәсәлән, “Жизель” спектакленнән граф Альберт костюмы Нью-Йорктагы “Кристи” аукционында 51570 долларга сатылган). Vanity Fair аның мөлкәтен 80 миллион долларга бәяли. 1993 елның 6 гыйнварында 54 яшендә бакыйлыкка күчә, әнисенә Парижны күрсәтү хыялы чынга ашмый кала. Үз баласы булмаганга, бу вакытта чит илдә яшәгән апасы Розага Монте-Карлодагы фатирын һәм 200 мең доллар, аның кызы Гүзәлгә 50 мең доллар васыять итә дә, Нуриев бөтен мөлкәтен диярлек үзенең хәйрия фондларына калдыра. Тик бүген Парижда Нуриевның музее да, аның хөрмәтенә аталган урам да юк. Озакка сузылган мәхкәмәләрдән соң, Рудольф Нуриевның Европадагы фонды Роза белән Гүзәлгә 1 миллион 800 мең евро акча бирергә ризалаша, Россиядәге туганнарына исә бер тиен дә тәтеми. Биюче Париждагы Сент-Женевьев-де-Буа зиратында җирләнгән.

(“Terpsyhora.ru”).

Газета өчен
Алсу ЗӘЙДУЛЛИНА әзерләде.

Дүшәмбе

6 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 16.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
11.30, 21.00 «Заман көзгесе». 6+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Семь дней». 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество». 12+
15.15 «Акыл батл».
17.00 «Татарлар». 12+
17.30 «Трибуна «Нового Века». 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы». 16+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Каравай». 6+».

ТНВ-ПЛАНЕТА

6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Башваткыч». 12+
9.50 «Семь дней». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Заман көзгесе». 6+
12.05 «Йөрәктән - йөрәккә». Фирдәвес Хәйруллина турында телеочерк. 6+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «МАЧЕХА». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК». 16+
10.30 «ОДНОЛЮБЫ». 16+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «РАЗ, ДВА! ЛЮБЛЮ ТЕБЯ!» 16+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Просто физика с Алексеем Иванченко». 12+
15.30 «Неизвестные сражения Великой Отечественной (Патриот 8)». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТОБОЛ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.15, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Невский ковчег. Теория невозможного. Лидия Чарская.
7.35 Черные дыры. Белые пятна.
8.20 Дороги старых мастеров. «Мстёрские голландцы».
8.30 «ПИКОВАЯ ДАМА».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 «Пушкин. Битов. Габриадзе. Побег».
12.10 «Дом полярников».
12.50 Линия жизни. Ренат Ибрагимов.
13.45 «Узбекистан. Ремесло, ставшее искусством».
14.15, 20.05 «Наедине с Петром Великим».
15.05 Новости. Подробно. АРТ.
15.20 «Агора».
16.25 «ДУБРОВСКИЙ».
17.35 Неделя симфонической музыки. Максим Емельянычев и оркестр «Солисты Нижнего Новгорода».
18.40 «Хомо сапиенс. Новые версии происхождения».
19.45 Главная роль.
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.05 «Сати. Нескучная классика...»
21.45 «ШЕРЛОК ХОЛМС».
23.15 «Первые в мире».
23.50 XX век. Екатерина Максимова и Владимир Васильев. «Дуэт».

«НТВ»

5.05 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.20, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.40 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ДЕЛЬФИН». 16+
22.00 «ГЕНИЙ». 16+

Сишәмбе

7 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Туган җир». 12+
13.30 «Юлчы». 6+
14.00 «Путь». 12+
14.15 «Не от мира сего...» 12+
15.15 «Төймә».
16.00, 21.00 «Ватандашлар». 12+
18.00 «Казаннан - казанга». 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
9.40 «Туган җир». 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Мәңгелек... Ирек... Хисләр...» Ирек Баһманов турында телеочерк. 6+
15.30 «Тамчы-шоу». 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30 «МАЧЕХА». 12+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК». 16+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «РАЗ, ДВА! ЛЮБЛЮ ТЕБЯ!» 16+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Химия». 12+
15.30 «Неизвестные сражения Великой Отечественной (Патриот 8)». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
23.00 «СВОИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТОБОЛ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35, 18.40 «Хомо сапиенс. Новые версии происхождения».
8.25 «Беларусь. Несвижский замок».
8.50, 16.35 «ДУБРОВСКИЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 «Мстислав Запашный. День циркового артиста».
12.25 Цвет времени. Леон Бакст.
12.40, 21.45 «ШЕРЛОК ХОЛМС».
14.15, 20.05 «Наедине с Петром Великим».
15.05 Новости. Подробно. Книги.
15.20 «Эрмитаж».
15.50 65 лет Владимиру Симонову. «2 Верник 2».
17.45 Неделя симфонической музыки. Андрис Нелсонс и Люцернский фестивальный оркестр.
19.45 Главная роль.
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.05 «Белая студия».
23.15 «Первые в мире».

«НТВ»

4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.20, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.40 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ДЕЛЬФИН». 16+
22.00 «ГЕНИЙ». 16+

Чәршәмбе

8 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00, 0.15 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00, 0.40 «Җырлыйк әле!» 6+
14.00 «Азбука долголетия». 6+
14.15 «Если хочешь быть здоровым...» 12+
15.15 «Бергәләп өйрәник».
16.00 «Переведи!» 6+
18.00 «Халкым минем...» 12+
19.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
20.15 «Кучтәнәч».
21.00, 23.50 «Соотечественники». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05, 8.40, 23.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
9.40 «Ачыктан - ачык». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05 «Баяның кулыннан төшмәде». Рәшит Мостафин турында телеочерк. 6+
15.30 «Яшьләр тукталышы». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
20.00 «Таяну ноктасы». 16+
20.30 «Юлчы». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30 «ПОЛИЦЕЙСКИЙ УЧАСТОК». 16+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПСИХОЛОГИЯ ЛЮБВИ». 12+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Угрозы современного мира». 12+
15.30 «Неизвестные сражения Великой Отечественной (Патриот 8)». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+

«1 НЧЕ КАНАЛ»

5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТОБОЛ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»

5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»

6.30, 7.00, 7.30, 8.20, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Хомо сапиенс. Новые версии происхождения».
8.25 «Испания. Тортоса».
8.50, 16.35 «ДУБРОВСКИЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10, 23.50 XX век. «Мастера искусств. Народная артистка СССР Людмила Касаткина».
12.30, 23.15 Цвет времени. Иван Крамской. «Портрет неизвестной».
12.40, 21.45 «ШЕРЛОК ХОЛМС».
14.15, 20.05 «Наедине с Петром Великим».
15.05 Новости. Подробно. Кино.
15.20 «Библейский сюжет».
15.50 «Белая студия».
17.40 Неделя симфонической музыки. Владимир Федосеев и Большой симфонический оркестр им. П.И. Чайковского.
18.35 «Рождение медицины. Как лечили в Древней Греции».
19.45 Главная роль.
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.05 Абсолютный слух.

«НТВ»

4.45 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.20, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.40 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ДЕЛЬФИН». 16+
22.00 «ГЕНИЙ». 16+

Пәнҗешәмбе

9 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»

5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00, 23.00 «БРАК ПО ЗАВЕЩАНИЮ». 16+
11.00, 0.40 «Каравай». 6+
11.30, 16.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Кәмит Җәвит». 16+
14.00 «Здоровая семья: мама, папа и я». 6+
14.15 «Фолиант в столетнем переплёте». 12+
15.15 «Шома бас» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Казаннан - казанга». 12+
18.00 «Юлчы». 6+
19.00, 20.00 «Точка опоры». 16+
21.00 «Ватандашлар». 12+
22.00 «Вызов 112». 16+
23.50 «Видеоспорт». 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Кәмит Җәвит». 16+
9.40 «Кунак БИТ Шоу». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30, 17.30, 19.35, 0.40 «Татарлар». 12+
12.05, 20.00 «Ирекле кубәләкләр». Луара Шакирҗанова турында телеочерк. 6+
15.30 «Халкым минем». 12+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»

5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ». 16+
9.25, 11.25, 12.55, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30, 18.40 «Советы Дня». 16+
13.00, 23.50 «ПСИХОЛОГИЯ ЛЮБВИ». 12+
14.30 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
14.45 «Не женское дело». 12+
15.00 «Меганаука». 12+
15.30 «Неизвестные сражения Великой Отечественной (Патриот 8)». 12+

16.20 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20, 23.45 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «ТОБОЛ». 16+
22.45 «Большая игра». 16+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА». 16+
22.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Рождение медицины. Как лечили в Древней Греции».
8.35 Цвет времени. Валентин Серов.
8.50, 16.35 «ДУБРОВСКИЙ».
10.15 «Наблюдатель».
11.10 ХХ век. «Портреты из легенды. Петр Лещенко... Оскар Строк».
12.10 «Казань. Дом Зинаиды Ушковой».
12.40, 21.45 «ШЕРЛОК ХОЛМС».
14.15, 20.05 «Наедине с Петром Великим».
15.05 Новости. Подробно. Театр.
15.20 Моя любовь - Россия! «Вологодские кружевницы».
15.50 «2 Верник 2». Ирина Муравьёва.
17.40 Неделя симфонической музыки. Риккардо Шайи и Люцернский фестивальный оркестр.
18.35 «Гутенберг и рождение книгопечатания».
19.45 Главная роль.
20.50 «Спокойной ночи, малыши!»
21.05 «Энигма. Кристиан Тилеман».
23.20 Цвет времени. Жорж-Пьер Сёра.
23.50 ХХ век. «Портреты из легенды. Петр Лещенко... Оскар Строк».

«НТВ»
4.55 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.20, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.40 «За гранью». 16+
17.50 «ДНК». 16+
20.00 «ВИРУС». 16+

Җомга

10 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35, 14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
5.50, 7.00, 7.00, 18.30, 20.30 Татарстан хәбәрләре. 12+
6.00, 7.10 «Манзара». 6+
8.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана. 12+
8.10 «Здравствуйте!» 12+
9.00, 17.00 «ЯЛАНАЯКЛЫ КЫЗ». 12+
10.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
11.00 «Нәсыйхәт». 6+
11.30 «Татарлар». 12+
12.00, 22.10 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
13.00 «Башваткыч». 12+
14.00 «Актуальный ислам». 6+
14.15 «Классный час». 12+
15.15 «Тизрәк! Алга! Җитезрәк!» һәм «Алты хәреф».
16.00 «Аулак өй». 6+
16.30 «Әдәби хәзинә». 6+
18.00 «Туган җир». 12+
19.00 «Болгар радиосы» концерты. 6+
20.00, 22.00 «Вызов 112». 16+
21.00 «Юлчы». 6+
23.00 «ДВА ДНЯ, ОДНА НОЧЬ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00, 13.00 «Манзара». 6+
8.00, 17.00, 21.25, 0.15 «РӘХӘТ ЯШИБЕЗ!» 12+
8.40, 23.05 «Ком сәгате». 12+
9.40, 15.30 «Нәсыйхәт». 6+
10.30 «Казаннан казанга». 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 0.00 «Яңалыклар». 12+
11.30 «Татарлар». 12+
12.05 «Кырыс җилле дала гөле». Гөлсем Исәнгулова турында телеочерк. 6+
16.00 «Әдәби хәзинә». 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. 6+
17.30, 0.40 «Калеб». 6+
18.20, 22.20 «АЙ ТУЛГАНДА». 16+
19.10 «Туган җир». 12+
19.35 «Заман көзгесе». 6+
20.05, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+

«ЭФИР»
5.00, 7.45 «Новое утро». 16+
7.00, 19.00, 22.00 «Город». 16+
8.30, 23.00 «СВОИ». 16+
9.25, 11.25, 21.55 «Казанская Афиша». 16+
9.30, 20.00 «СЕРЕБРЯНЫЙ БОР». 12+
10.30, 21.00 «СТАРШАЯ ДОЧЬ». 12+
11.30, 17.10 «ПОСЛЕДНИЙ ЯНЫЧАР». 12+
12.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00, 23.50 «В ЛОВУШКЕ ВРЕМЕНИ». 12+
15.00 «Не факт». 12+
15.30 «Неизвестные сражения Великой Отечественной (Патриот 8)». 12+
16.30 «Лекс и Плу: Космические таксисты».
18.00 «Добрый вечер, Казань». 16+
18.30 «Fam TV». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
5.00 «Доброе утро».
9.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
9.20 «АнтиФейк». 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.45, 12.15, 15.15, 18.20 Информационный канал. 16+
21.00 «Время».
21.45 «Две звезды. Отцы и дети». 12+
23.25 «АФЕРИСТКА». 18+

«РОССИЯ»
5.00, 9.30 «Утро России».
9.00, 14.30, 21.05 Вести. Местное время.
9.55 «О самом главном». 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести.
11.30, 17.30 «60 минут». 12+
14.55 «Кто против?» 12+
21.20 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30, 7.00, 7.30, 8.30, 10.00, 15.00, 19.30, 23.30 Новости культуры.
6.35 «Пешком...»
7.05 Легенды мирового кино.
7.35 «Гутенберг и рождение книгопечатания».
8.35 Цвет времени. Караваджо.
8.50 «ДУБРОВСКИЙ».
10.20 «СИЛЬВА».
11.40 «Сергей Мартинсон».
12.25 «Забытое ремесло».
12.40 «ШЕРЛОК ХОЛМС».
14.15 К 75-летию Константина Лопушанского. Острова.
15.05 Письма из провинции.
15.35 «Энигма. Кристиан Тилеман».
16.15 Неделя симфонической музыки. Кристиан Тилеман и Венский филармонический оркестр.
17.40 Цвет времени. Валентин Серов.
17.55 «Царская ложа».
18.35 К 75-летию Иосифа Райхельгауза. Линия жизни.
19.45 «Смехоностальгия».
20.15 Искатели. «Затерянное сокровище рода Харитоновых».
21.05 Линия жизни. Мира Кольцова.
22.00 «СТАРИКИ-РАЗБОЙНИКИ».
23.50 «СКВОЗЬ ЧЕРНОЕ СТЕКЛО». 18+

«НТВ»
4.50 «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ». 16+
6.30 «Утро. Самое лучшее». 16+
8.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00 Сегодня.
8.25 «Мои университеты. Будущее за настоящим». 6+
9.20, 10.30 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. СМЕРЧ». 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие.
14.00 «Место встречи».
16.40 «ДНК». 16+
18.00 «Жди меня». 12+
20.00 «ВИРУС». 16+
23.30 «Своя правда». 16+

Шимбә

11 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «Йөрәктән - йөрәккә». 6+
7.00 «Синң Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00 «Татар халык җырлары».
11.30 «Казаннан - казанга». 12+
12.00, 0.55 «Каравай». 6+
12.30 «Видеоспорт». 12+
13.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
13.30 «Акча корты». «Мунча ташы» театры тамашасы. 12+
17.00 «Әйдә, шаяРТ!» 12+
18.00 «Кәмит Җәвит». 16+
19.00 «Халкым минем...» 12+
19.30, 21.30 Новости в субботу. 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Җырлыйк әле!» 6+
22.00 «КунакБит- шоу». 12+
23.00 «МАДАМ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
6.00 «Әйдә әле мәхәббәт иленә». 6+
7.00, 15.00 «Синң Миннән Сәлам». 6+
9.00 «Кәмит Җәвит». 16+
10.00 «Кайнар хит». 12+
11.00, 18.15 «Башваткыч». 12+
12.05, 19.05 «Җырлыйк әле!» 6+
13.00 Концерт «Сабан туенда». 6+
17.10 «Казаннан казанга». 12+
17.45 «Халкым минем». 12+
20.00 «Адымнар». 12+
20.30 «Очрашулар эзләп» Габделфәт Сафин концерты. 6+
22.15 Спектакль «Кыз урлау». 12+

«ЭФИР»
5.00 «Удиви меня». 12+
5.45 «Не женское дело». 12+
6.00 «Меганаука». 12+
6.30 «Один день в городе». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Кавалеры ордена Александра Невского». 12+
8.15 «ЛИНИЯ МАРТЫ». 12+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ВЫШЕ НЕБА». 16+
15.00 «Планета собак». 12+
15.30 «КОМАНДА Б». 16+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ДВОЕ ВО ВСЕЛЕННОЙ». 16+
23.00 «КЛАН КЕННЕДИ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00 «Доброе утро. Суббота».
9.00 «Умницы и умники». 12+
9.45 «Слово пастыря».
10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
10.15 «Порезанное кино». 12+
11.20, 12.15 «Видели видео?»
14.10, 15.15 «Янтарная комната». 12+
16.30 «Кто хочет стать миллионером?»
18.20 «Пусть говорят». 16+
19.55 «На самом деле». 16+
21.00 «Время».
21.35 «Сегодня вечером». 16+
23.00 Лига Бокса. Россия - Африка. 16+

«РОССИЯ»
5.00 «Утро России. Суббота».
8.00 Вести. Местное время.
8.20 Местное время. Суббота.
8.35 «По секрету всему свету».
9.00 «Формула еды». 12+
9.25 «Пятеро на одного».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00, 20.00 Вести.
12.00 «ЛИКВИДАЦИЯ». 16+
18.00 «Привет, Андрей!» 12+
21.00 «ВЫ МНЕ ПОДХОДИТЕ». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 «Библейский сюжет».
7.05 Мультфильмы.
8.10 «МОЯ ЛЮБОВЬ».
9.25 «Обыкновенный концерт».
9.55, 23.35 Исторические курорты России. «Липецкие воды».
10.25 «СТАРИКИ-РАЗБОЙНИКИ».
11.50 Земля людей. «Селькупы. Свой хлеб».
12.20 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
13.20 «Его Величество Конферансье».
14.05 «Добро пожаловать, или Посторонним вход воспрещён». Без сюрпризов не можете?!»
14.45 «ДОБРО ПОЖАЛОВАТЬ, ИЛИ ПОСТОРОННИМ ВХОД ВОСПРЕЩЕН».
15.55 Гала-концерт лауреатов конкурса «Щелкунчик».
17.30 Искатели. «Загадка исчезнувшей коллекции».
18.20 «Звезда Рины Зелёной». Рассказывает Полина Агуреева.
18.35 «ДЕВУШКА БЕЗ АДРЕСА».
20.00 Большой джаз. Финал.
22.05 «БЕЛЫЙ СНЕГ РОССИИ».

«НТВ»
4.50 «Хорошо там, где мы есть!»
5.15 «ЧП. Расследование». 16+
5.40 «НЕ БОЙСЯ, Я С ТОБОЙ! 1919». 12+
7.30 Смотр.
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.15 «Поедем, поедим!»
9.20 «Едим дома».
10.20 «Главная дорога». 16+
11.00 «Живая еда с Сергеем Малозёмовым». 12+
12.00 «Квартирный вопрос».
13.05 «Однажды...» 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.15 «Следствие вели...» 16+
18.00 «По следу монстра». 16+
19.00 «Центральное телевидение».
20.10 «Ты не поверишь!» 16+
21.00 «Секрет на миллион». 16+
23.00 «Международная пилорама». 16+
23.45 «Квартирник НТВ у Маргулиса». 16+

Якшәмбе

12 июнь

«ТАТАРСТАН - ЯҢА ГАСЫР»
5.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары». 6+
6.00 «ВОЛГА-ВОЛГА».
8.00, 13.00 «Адымнар». 12+
8.30 Мультфильмы. 6+
8.45 «Әти һәм мин».
9.15 «Тамчы- шоу».
9.45 «Яшьләр тукталышы». 12+
10.15 «Ачыктан - ачык». 12+
11.10 «Татар халык җырлары».
11.30 «Тархан». 6+
12.00 «Каравай». 6+
12.30 «Закон. Парламент. Общество». 12+
13.30 Спектакль «Утрау». 12+
16.00 «Ком сәгате». 12+
17.00 «Видеоспорт». 12+
17.30 «Соотечественники». 12+
18.00 «Башваткыч». 12+
19.00, 22.00 «Семь дней». 12+
20.00 «Заман көзгесе». 6+
20.30 «Болгар радиосы» концерты. 6+
21.00 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
23.00 «ЛЕВ». 16+

ТНВ-ПЛАНЕТА
5.05, 12.35 «Халкым минем». 12+
5.30, 13.00 «Нәсыйхәт». 6+
6.00 «Ватандашлар». 6+
6.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять». 12+
7.00 «Әниләр һәм бәбиләр». 6+
9.00 «Су буенда учак яна». 6+
10.00 «Юлчы». 6+
10.30 «Калеб». 6+
11.10 «Тамчы-шоу». 6+
11.45 «Бергәләп өйрәник». 6+
12.05, 0.40 «Яшьләр тукталышы». 12+
13.30 Спектакль «Моңлы ядкәр». 12+
15.50 Марат Мухин хитлары. 6+
17.15 «Әй, язмыш, язмыш...» 12+
18.10 «Кәмит Җәвит». 16+
19.05, 23.45 «Ком сәгате». 12+
20.00 «Семь дней». 12+
21.10 «Китмә, сандугач». Илһам Шакиров ядкәре. 6+

«ЭФИР»
5.00 «Маршал Конев. Иван в Европе». 12+
5.45, 15.00 «Не женское дело». 12+
6.00 «Не факт». 12+
6.30 «Один день в городе». 12+
7.00 «Четверо в кубе».
7.30 «Лео и Тиг».
8.00 «Планета собак». 12+
8.30 «КОМАНДА Б». 16+
12.00, 20.00 «Fam TV». 16+
12.30, 20.30 «Обыкновенные рецепты здоровья». 16+
13.00 «ДВОЕ ВО ВСЕЛЕННОЙ». 16+
15.15 «ЛИНИЯ МАРТЫ». 12+
19.00 «Город». 16+
21.00 «ВЫШЕ НЕБА». 16+
23.00 «СВЯЗЬ». 16+

«1 НЧЕ КАНАЛ»
6.00, 10.00, 12.00, 15.00, 18.00 Новости.
6.10 «ТОТ, КТО ЧИТАЕТ МЫСЛИ» («МЕНТАЛИСТ»). 16+
7.45 «Играй, гармонь любимая!» 12+
8.25 «Часовой». 12+
8.55 «Здоровье». 16+
10.15, 12.15 «ЮНОСТЬ ПЕТРА». 12+
13.15, 15.15 «В НАЧАЛЕ СЛАВНЫХ ДЕЛ». 12+
16.05 «СКАЗ ПРО ТО, КАК ЦАРЬ ПЕТР АРАПА ЖЕНИЛ». 12+
18.20, 21.45 «ИМПЕРИЯ. ПЕТР I». 12+
21.00 «Время».
23.05 «ПЕТР ПЕРВЫЙ». 12+

«РОССИЯ»
5.20 «БЕРЕГА ЛЮБВИ». 12+
7.15 «Устами младенца».
8.00 Местное время. Воскресенье.
8.35 «Когда все дома с Тимуром Кизяковым».
9.25 «Утренняя почта с Николаем Басковым».
10.10 «Сто к одному».
11.00, 17.00 Вести.
12.00 Церемония вручения Государственных премий РФ.
13.00 «ЛИКВИДАЦИЯ». 16+
18.00 Большой праздничный концерт, посвящённый Дню России.
20.00 Вести недели.
22.00 Москва. Кремль. Путин.
22.40 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». 12+

«КУЛЬТУРА»
6.30 Лето Господне.
7.05 «Двенадцать месяцев».
8.00 «БЕЛЫЙ СНЕГ РОССИИ».
9.25 «Обыкновенный концерт».
9.55 Исторические курорты России. «Старая Русса».
10.25 «ДЕВУШКА БЕЗ АДРЕСА».
11.50 Земля людей. «Чулымцы. Под защитой белой лошади».
12.20 «Рассказы из русской истории». Владимир Мединский.
13.20 «ПЁТР ПЕРВЫЙ».
16.40 Концерт Государственного академического ансамбля народного танца имени Игоря Моисеева в Государственном Кремлёвском дворце.
18.10 «Я ШАГАЮ ПО МОСКВЕ».
19.25 «Мир Александры Пахмутовой».
20.10 «Романтика романса». Песни Александры Пахмутовой.
21.15 «АРХИПЕЛАГ».
22.55 «Классика встречает джаз». Прогулка с Игорем Бутманом и Юрием Башметом.

«НТВ»
5.15 «ВЫЗОВ». 16+
6.45 «Центральное телевидение». 16+
8.00, 10.00, 16.00 Сегодня.
8.15 «У нас выигрывают!» 12+
10.20 «Первая передача». 16+
11.00 «Чудо техники». 12+
12.00 «Дачный ответ».
13.00 «НашПотребНадзор». 16+
14.00 «Своя игра».
15.00, 16.20 «Следствие вели...» 16+
19.00 Итоги недели.
20.20 «Ты супер! 60+». 6+
22.40 «ОТСТАВНИК. ОДИН ЗА ВСЕХ». 16+

Башкортстандагы Собхангол авылында яшәүче Артур Вәлиев узган ел июльдә өеннән чыгып китә дә әйләнеп кайтмый. Ата-анасы ошбу хәлгә берничә көн әллә ни игътибар бирмиләр. Чөнки шул көннәрдә 38 яшен тутырган буйдак, димәк, ирекле ир-ат, моңа кадәр дә ике-өч көнгә югалгалап тора, ләкин андый чакларда шалтыратып кайда икәнен хәбәр итә. Ә бу юлы аның телефоны җавап бирми. Вакыт узган саен, шом көчәя, 8 августта алар Туймазы эчке эшләр бүлегенә гариза яза, улларының фоторәсемен тотып, 6 меңләп халкы булган зур авылда йөреп сорашалар, ләкин юньле мәгълүмат алынмый.

Яр буенда явызлык

Шикләнүләр җәйләр узып, көзгә кергәч аклана. 25 сентябрьдә Туймазы полициясе түгел, ә Вәлиевләр интернетта тетрәндергеч мәгълүмат таба. Бөгелмә эчке эшләр бүлеге урнаштырган хәбәрдә шул районлагы Наратлы авылыннан ерак түгел Бобровка елгасы ярында ир кеше мәете табылу турында әйтелә. Уң иңбашындагы арыслан башы рәвешендәге татуировка аның Артур икәнен белдереп тора. Олы кайгыга төшкән ир белән хатын Бөгелмә моргына килеп, улларын танулары турындагы рәсми кәгазьләргә кул куя, мәрхүмнең телефоны һәм кул сәгате юкка чыгуын да әйтәләр.

Бактың исә, ул моргта да ай буе яткан икән. Шул тирәдә яшәүчеләр Казан-Оренбург юлындагы күпер астындагы мәетне 25 августта ук күреп полициягә хәбәр итә, аның аяклары суда, гәүдәсе яр буенда була. Җәйге челләдә ай буе, соңрак мәгълүм булганча, 28 июльгә каршы төннән бирле юештә яткан, рәсми кәгазьләрдә әйтелгәнчә, ярымтаркалган хәлдәге мәетне тикшерү катлаулы була. Суд-медицина экспертизасы аның баш түбәсе сөяге сынып иңү һәм башка авыр җәрәхәтләр аркасында җан бирүен күрсәтә, суга батып үлүне раслаучы билгеләр табылмый.

Соңгысының әллә ни әһәмияте юк, кешенең үтерелүе бәхәссез бит. Экспертиза нәтиҗәләре алынгач та тикшерү комитетының аеруча мөһим эшләр буенча тикшерүчесе Айдар Еникеев аңлы рәвештә кешегә үлем китерү хакындагы маддә буенча җинаять эше кузгата. Шулай килеп чыга ки, оператив-эзләү чаралары мәрхүмнең шәхесен ачыклау белән бик тиз алга китә. Юкса, бичара ата-ана шикләнердәй бер генә кешене дә атамый. Алар улларын вахта ысулы белән, ягъни бер айлап читкә йөреп эшләде, 80 мең чамасы хезмәт хакы алды, бурычлары, дошманнары юк иде дип уңай бәялиләр.

Күрәсең, Бөгелмә полициясендә яр буендагы табылдык алынгач та эшкә керешкәннәр, әйтик, әллә ни кеше йөрми торган бу тирәләрдә булган телефоннарны барлау белән шөгыльләнгәннәр. Аннан соң, Артурның кесә телефоны да кулланышта була бит әле. Әлбәттә, һәлак булучының Собханголныкы икәне ачыклангач, эзләү чаралары шул төбәктә алып барыла һәм шик төшәрдәй затлар табыла, шунда түләүле фатирда яшәп эшләүче Әлмәт кешесе Ирек Бутаков һәм Лениногорск егете Николай Кузьмин, соңгысының абзые, ягъни әнисенең шул районлагы Мордва Кармалкасы авылында торучы энесе Николай Крючков тоткарланып, күрсәтмәләр бирә башлый, тентүләр һәм башка тикшерү гамәлләре үткәрелә. Акрынлап җәй уртасында булган вакыйга ачыклана бара.

2021 елның 27-28 июль төнендә булган хәлләргә күчкәнче, әлеге өч кешегә, иң әүвәл, 1999 елда туган Николай Кузьминга кыскача бәяләмә бирер үтик. Чөнки тикшерү барышында төп явызның шушы йөгәнсез бәндә икәне дәлилләнә. Якыннарының әйтүенә караганда, кечкенәдән тәртипсез була ул. Үсә төшкәч грек-рим көрәше белән шөгыльләнә, бу өлкәдәге сәләтен урамда күрсәтергә керешә, 16 яшендә үзе кебекләр белән кеше талауда катнаша, бер яшүсмерне көрәш алымы кулланып асфальтка ыргытып умрау сөяген сындыра. Ата-анасы аның ошбу галәмәтләрен начар яшьләр даирәсенә эләгү нәтиҗәсе дип дусларына сылтарга тырышалар. Әлеге җинаятьләрдә башлап йөрүченең Николай икәне бәхәссез юкса, 16 яшьлек малайны 2 ел да ике айга колониягә озатмаслар иде. Ошбу кырыс җәзаны талау, куркытып талау (вымогательство), кеше сәламәтлегенә уртача дәрәҗәдәге зыян китерү кебек биш явызлыгы өчен ала ул. Аннан кайткач та, мошенниклык кылып, мәҗбүри эшләргә хөкем ителә, анда йөрергә теләмәгән өчен тагын бер ай утырып чыгарга өлгерә.

Ирек Бутаков та берничә тапкыр хөкемгә тартылган, азат ителгәч ышанычсыз кеше буларак административ күзәтүгә куелган зат. Собханголда Н.Кузьмин белән бергә эшләгән, бер фатирда торган Николай Крючковның да тормыш юлы бик сикәлтәле, ташланып эчә торган зәхмәте булганга төрмәдә күп утырган, әмма ел ярым чамасы аек йөргән, хәтта Яшел Үзән каласына барып эшләгән. Былтыр июль азагында телефоннан сөйләшкәндә бертуган апасы аның исерек икәнен сизә һәм, йөгәннән ычкынса, чит җирләрдә юкка чыгуыннан ук курка башлый, шул сәбәпле, ире Э.Кузьминга аны туган якларына алып кайтырга куша.

25 июль якшәмбе көнне Эдуард Кузьмин Туймазы якларыннан Татарстанның икенче почмагындагы Яшел Үзәнгә юл ала. Аның белән Николай һәм хезмәттәше Ирек тә бара. Н.Крючковны алып икенче көнне кичкә таба Собханголга кайта алар. Һәм әлбәттә, дүртәүләп бәйрәм итәргә керешәләр. Ошбу мәҗлес тыныч тәгәлләнә. Иртә белән Эдуард эшкә урнашырга, Николай белән Ирек эшкә китә, Н.Крючков фатирда кала. 27 июль кичә дә алдагысы кебек үк башланып китә, әмма бер-ике чәркәне бушаткан өлкәнрәк агай йокыга талгач һәм фатирда моңарчы таныш булмаган тагын бер ир-ат пәйда булгач, вакыйгалар башка төрләрәк юнәлеш ала.

Өч сәрхүш ишегалдында ялгызы эчеп утырган кешене балконга тәмәке көйрәтергә чыккач күрәләр һәм ул телефонын корырга сорагач, өйгә чакыралар. Шул рәвешле Артур Вәлиев килеп керә, үзе белән аның бер чәкүшкәсе дә була. Ләкин әллә ни озак утырмыйча чыгып китә ул. Кызганычка димичә булмый, тиздән кафелар, төрле хәмер кибетләре булган зур төбәк урамында язмыш тагын очраштыра аларны. Саф һавада бергәләп эчә, исерә торгач яңа уй-фикерләр дә туа һәм Артур кем икәнлекләрен юньләп белмәгән ирләргә, чынлыкта, язмышын хәл иткән тәкъдимне ясый, ягъни: «Сездән – аракы, миннән – мәткәләр», - дип Туймазы каласына сәфәр кыларга чакыра. Канатланган Н.Кузьмин йоклап яткан әтисенең ачкычларын чәлдереп, машинасын алып килә, башкалар аракы, сыра сатып ала.

Шикләнердәй кешеләр ачыкланса да, хәвефле төндә булган хәлләрне тәгаенләү шактый вакыт һәм тырышлык таләп итә. Бу, иң беренче чиратта, өч кешенең күрсәтмәләре чагышмау, бигрәк тә, арада иң яше Н.Кузьминның судан коры чыгарга азаплануы белән бәйле. Аның күрсәтмәләренә кыскача гына тукталсак, Ирек белән Артур Туймазыга барганда, машинада ук әрләшә, сугыша башлыйлар, әлеге калада юлның уңмавы ачыкланып, Татарстанга таба борылгач та бәргәләшә алар, бер туктагач, көчлерәк Ирек Артурның кроссовкаларындагы шнурларны салдырып алып кул-аякларын бәйләп машинага утырта, безгә мәгълүм күпер төбендә аны елгага ташлый, су буендагы ташларны атып, тынсыз калдыргач югары күтәрелә.

Вакыйгалар агышын шактый эзлекле сурәтли ул. Сөйләп кенә дә калмый, тикшерү чаралары вакытында И.Бутаковның рәвешле кыланганнарын күрсәтеп тә бирә. Хикмәт шунда ки, ошбу вәхшилекләрне ул үзе эшләгән була. Икесен кара-каршы утыртып сорау алганда, Ирек дустын хәйран калып тыңлый һәм Кузьмин үзе турында сөйли дип белдерә, аны фаш итә, ялган детекторы дип йөртелгән «Полиграф» тикшерүне узарга ризалык бирә. Чынлыкта, Артур Вәлиевне суга ыргытканда, И.Бутаков Бөгелмә автовокзалында черем иткән, исерек булган өчен тоткарланып штрафка да тартылган әле. Ә Кузьмин явызлыклар кылганда, аның янында абзасы Н.Крючков булган.

Җинаять эшендә шактый вакыт шикләнелүче булып йөргән Н.Крючков белән И.Бутаков бөтенләй үк гаепсез дә түгел кебек. Әйтик, Николайның явыз энесенә ярдәм итүе сизелә, үтерелгән Артурның 500 тәңкәлек кул сәгатен Ирек салдырып алган була. Күрәсең, Н.Кузьмин кылган ерткычлыклар янында ошбу хилафлыклар вак-төяк булып күренә һәм алар шаһит итеп калдырыла.

Дәлилләр, фашиткеч күрсәтмәләр Н.Кузьминга да боргаланырга урын калдырмый. Алга таба ул чынлыкта, гаебен танып сөйли башлый. Э.Кузьмин малае чит кеше гаебен үз өстенә ала дип саный, Н.Крючков Артурны елгага ташлавын үзе сөйләде дип гаепне кайнесенә сылтарга да тырыша. Ата-ананың үз баласы ерткычлыгына ышанмавын гадәти хәл дияргә була. Шул ук вакытта Эдуард улының кимсетүле сүзләрне күтәрә алмаучы һәм үз-үзен якларга – сәләтле нык егет булуына ишарәли. Менә шул мин-минлеге этәргән дә инде фаҗигагә.

Тикшерү эшләре барышында ачыкланганча, 27 июльдә Туймазыга таба кузгалгач та Артур ниндидер хатын-кызлар белән телефоннан сөйләшә, аларны күндерә алмавы башкаларга да аңлашылмый калмый. Николай шәһәр янәшәсендә машинаны туктата, сораулар яудыра башлый. Белмәгән кешеләр белән сәфәр чыгу Артурның беренче ялгышы булса, икенчесендә тупаслана, аларны Туймазы «братва»сы һәм «гаишниклар»га тапшыру белән өркетә башлый. Нәтиҗәдә, «текә» егет аның чыраена китереп тондыра, ике шаһитның әйтүенчә, арт утыргычтагы Артур шактый вакыт аңсыз була. Шофер аның телефонын алып каршысындагы панельгә куя.

Бу инде Н.Кузьминның шул арада талау һәм әтисенең машинасын куу (угон) дигән ике җинаять кылып өлгерүен күрсәтә. Күп тә үтми Туймазыда эш пешмәячәген аңлап Лениногорск ягына барганда юлдан читкә борыла, өенә килгән «алдакчының» шнурларын алып аяк-кулларын бәйли дә аны агачлык буенда калдырып китә. Бусы да дөмбәсләүләрсез генә узмый. Аның әлеге гамәле исә РФ Җинаять кодексында кешене законсыз рәвештә ирегеннән мәхрүм итү дип атала. Димәк ки, өченче җинаять эшләнә.

Егетләр кире Башкортстан ягына юнәлә, юл уңаенда агачлыкта йоклап яткан Артурны уятып машинага утырталар. Әлбәттә, тынычлык урнашты дигәнне белдерми бу. Аңкы-миңке хәлдәге сәрхүш тагын теләнә, братва белән куркыта, кыскасы, низаг куба, әтисе әйткәнчә, кимсетүле сүзләргә түзеп тора алмый торган егет иярчен юлга борыла, аннан шул тирәдәге күпергә таба китә. Н.Кузьмин үз явызлыкларының барысын да Артурның начар сүзләр кычкыруы белән аклагандай итә. Аяк-кулларындагы бауларны кистем, Собханголга җәяү кайтсын өчен трассада калдырып китәргә уйлаган идем мыскыллы сүзләренә түзә алмадым, елгага төшергәч тә акыруын дәвам итте, ди. Кыскасы, яртылаш суда торган кешене, әйтүенчә, кирпечтән зуррак ташлар тондырып «тынычландыра»ул. Аңлы рәвештә кеше үтерү, дигән дүртенче җинаяте була бу...

2021 елның июлендә булган хәлләр буенча кузгатылган шаукымлы җинаять эше Бөгелмә шәһәр судына быел март аенда гына тапшырылды. Һичшиксез кырыс булачак хөкем карары чыгарылмаган әле.

Наил ВАХИТОВ.

Татар мәдәниятен үз итүче

Ижауда яшәп иҗат итүче рәссам-модельер Наталья Ермолинаның татар калфаклары бөтенләй үзгә!

«Мин аларны сәхнә өчен түгел, ә көндәлек тормышта киеп йөрү өчен тегәм, – дип аңлатты оста. – Сәхнә дигәннән, бу өлкә миңа бик таныш. Мин ун ел Ижаудагы «Асылъяр» татар җыр һәм бию ансамбленә йөрүче балалар өчен сәхнә костюмнарын иҗат итүдә актив катнаштым. Гомумән, гомерем буе милли костюмнар тектем. Ә татар мәдәниятен аеруча үз итәм. Әлеге ансамбльнең җитәкчесе Лариса Гайнетдинова ансамбльнең барлык костюмнарын үзенчә күзаллый. Мин дә уртак иҗатта катнашып, сәхнә костюмнарының бөтенесен дә үзем тектем, моннан кала костюмнарны трансформерларга әйләндерү белән дә шөгыльләндем. Чөнки ансамбльгә йөрүче балалар тиз үсә, костюмнардагы кайбер детальләрне, аксессуарларны тагын ничек кулланып булуы хакында уйлану да мөһим иде... Татар мәдәниятенә карата ихлас мәхәббәтем Ларисаның тырыш эшчәнлегенә, ул җитәкләгән ансамбльгә йөрүче балаларның тәрбияле, сәләтле булып үсүләренә гаҗәпләнүдән дә туды. Татар җырлары да – күңелем түрендә».

Наталья Петр кызы инде бернičә ел рәттән татар телен өйрәнә. Татарчага башта Ижауның Халыклар дуслыгы йортындагы курста төшенгән, ә хәзер исә каладагы җәмигъ мәчетендә оештырылган татар теле дәресләренә бик теләп йөри. Татарча яхшы белә һәм татарча текстлар укый.

«Әти-әнием белән Ижаудан Казахстанга күченгәндә миңа биш яшь иде. Анда миңа казах мәдәнияте белән якыннан танышырга туры килде һәм аларның үз тарихларын, милли сәнгатьләрен, гореф-гадәтләрен нык саклауларына игътибар иттем. Казах дусларым белән әле дә аралашам. Ә казах телен аңларга миңа татар теле ярдәм итә.

Мин Ижау дәүләт университетын тәмамладым. Белгечлегем буенча – педагог. Кием конструкциясен төзү һәм модель ясау осталыгына төшендерүче укытучы булдым. Аннары театр костюмы буенча рәссам-модельер булып хезмәт куйдым. Хәзер инде менә ике ел лаекль ялда. Әмма «Асылъяр» ансамбле белән иҗади хезмәттәшлегем бер көн дә исемнән чыкмый. Ансамбльгә талантлы балалар йөри. Алар татарча җырлый, бии, төрле музыка коралларында да уйный. Татар телен өйрәнүем миңа шушы ансамбльдә эшләүчеләр һәм балалары шушы ансамбльгә йөрүче ата-аналар белән бергәләп Т.Миңуллинның «Әниләр һәм бәбиләр» спектаклендә роль уйнарга да булышты.

Бүген мин татар калфаклары тегәм. Казанга махсус барып, чигү остасы Нурислам Сиражидан дәресләр алдым, чөнки ул теккәндә, чиккәндә борынгы гасырлар технологиясен кулланып иҗат итә. Н.Сиражиның татар мәдәниятенә керткән өлешен күпләр күреп бетерми. Аның иҗатына багышланган шәхси күргәзмә ачарга кирәк».

Наталья ханым – Удмуртиядә һәр ел саен үткәрелеп килгән «Татар кызы» бәйгесе спонсоры да. Бу күңелле бәйгедә җиңгән кызларга ул үзе тегеп-бизәгән хәситәләрен, калфакларын бүләк итә. Бәйгенең кул эшләнмәләре конкурс этабында үз бәяләмәләре белән жюрига да булыша.

Заманча калфакларның тегелеп бетүләрен көтеп кенә торалар. Мәсәлән, беренче хәситәләрен һәм калфакларын ул Женевага ук юллаган. Аннары мондый милли кием аксессуарларын, гаҗәеп үзенчәлекле баш киемнәрен Финляндия, Германия, Төркия, Швейцария татарлары теләп алган. «Туганымның кызлары Вәсилә белән Әдилә дә татар киемнәрен аеруча ошатып кия», – ди алтын куллы оста.

Чит дәүләт иҗатчылары да аның белән дус. Әйтик, аның эшләрен үз итүчеләрнең берсе – Германиянең Швебиш-Халль шәһәрендәге балет академиясе җитәкчесе Хелена Шнайдер. Шушы балет академиясенә йөрүче балалар «Шүрәле»дән бер өзек биергә өйрәнгәч, аларга кирәкле сәхнә киемнәрен дә нәкъ менә Наталья Ермолина иҗат иткән.

«Татар чигү үрнәкләре, татар декоратив-гамәли сәнгате буенча күп китаплар җыйдым. Аларны еш кулга алырга туры килә. Әле генә Саратовта гомер итүче бер кызга мишәрләргә хас үзенчәлекләре булган милли костюм тектем. Татар дусларым – гаҗәеп шәхесләр. Мәсәлән, Удмурт Республикасының төньяк районнары имам-мөхтәсибе Илмир хәзрәт Касимов үтенече буенча борынгы гасырларда киелгән фасондагы татар хатын-кыз камзулын тектем», – ди Наталья Петровна. Илмир хәзрәт әйтүенчә, 2020 елда Балезино районы Паюра авылы мәдәният йортында янгын чыккач, бар костюмнар да янып беткән икән. «Наталья ханым әлеге мәдәният йортыбыз өчен бик сыйфатлы киемнәр тегә башлады, без әле эш башында гына, әмма хезмәттәшлегебез дәвамлы булыр, иншаллаh!» – ди туган як тарихын өйрәнүче Илмир хәзрәт.

Бу көннәрдә ул төн утырып Германиядә яшәүче татарлар өчен калфаклар тегә. Тиздән аларны алман җирендәге татар бәйрәмнәрендә дә күреп сокланырлар.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА.

Мәдәни җомга

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ – «ТАТМЕДИА» АКЦИОНЕРЛЫК ҖӘМГЫЯТЕ

«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы директоры – баш мөхәррир

Вахит Шәих улы ИМАМОВ

Җаваплы сәркатип
Илгизәр ЗӘКИЕВ

Шылтыратыгыз:

222-09-83 (1562) – кабул итү бүлмәсе;

222-05-47 (1560) – җаваплы сәркатип, компьютер үзәге;

222-05-47 (1561) – иҗтимагый-сәяси тормыш, мәгариф һәм фән, сәнгать бүлекләре; хатлар һәм социаль көнкүреш, тәрҗемә бүлекләре;

222-09-84 (1266) – бухгалтерия.

Реклама хезмәте телефоны:
(843)222-05-47 (1560)

Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм гаммәви коммуникацияләр өлкәсенә күзәтчелек итү федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2019 елның 9 октябрендә ПИ №ФС 77–76961 нче санлы теркәү таныклыгы алды

Индекс П2355

Авторлар фикере редакция фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин

Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк

Хатлар, кульязмалар, фотографияләр, рәсемнәргә бәяләмә бирелми һәм алар кире кайтарылмый

© Газетада чыккан материалларны күчереп бастырганда редакциядән язмача рөхсәт алу мәҗбүри

Реклама һәм белдерүләрнең төгәллеге өчен реклама бирүчеләр үзләре җаваплы

Безгә иганәләк ярдәме күрсәтергә теләүчеләр өчен редакциянең исәп-хисап счеты:
ИНН 1655144950 КПП 165802012
ПАО «АК БАРС» банк, г. Казань
р/с 40702810600020010312
к/с 30101810000000000805
БИК 049205805 ОГРН 1021600000124

НӘШЕР ИТҮЧЕ – «ТАТМЕДИА» АҖ
420097, Казан, Академия урамы, 2

Редакция, гамәлгә куючы һәм басмаханәнең адресы:
420066, Казан, Декабристлар урамы, 2
E-mail: m-jomga@mail.ru

«Мәдәни җомга» газетасы Интернетта:
www.madanizhomga.ru

Басмаханә гаебе белән җибәрелгән сыйфат җитешсезлекләре хакында 562-10-61 номерлы телефон буенча шылтыратырга

Газета һәр атнаның җомга көнендә чыга.
Бу санның чыгу көне 3.06.2022

График буенча бу санга 15 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 14 сәгать 30 минутта.

«Татмедиа» АҖ филиалы – «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды

Газетаның сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 2730 данә

Заказ 2755

16+